PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА **АЗАТ ХАТЫН**



2016 **ИЮЛЬ № 7**

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

АСРАУ ИРЛӘР

хатын-кызлар нигә беркатлы

АТНАБАЙ

яратып туймыйча китәбез

ГӨЛСИРИН АБДУЛЛИНА СЫЙЛЫЙ:

тавык итеннән кебаб



Елена СӘЕТБАГИНА:

– КАЗАН БЕЗГӘ ИЛҺАМ БИРӘ...

PRESSA.RU



БЕРГӘ ЧАКТА... Бу мизгелләр күп тә түгелдер, бәлки — атналарны тыгызлаган бетмәс-төкәнмәс эш, мәшәкать ыгы-зыгысында гаилә белән үткәргән бәхетле минутлар һаман сирәгәя, кыскара барадыр. Әмма аларның һәрберсе кадерле, һәркайсы безгә тормышның ямен-тәмен тоеп яшәрлек көч, җан җылысы бирәдер. Бу тансык вакытны һәркем үзенчә үткәрә – алар мәгънәле, күңелле, онытылмас якты булсын өчен әллә ни кирәкми дә кебек...





ҖӘЙ КЫСКА, АШЫГЫЙК!

Сәфәровлар гаиләсе

Казан

Сәфәровлар гаиләсе күпләргә таныш. Данил «Матбугат.ру» сайтын җитәкли, «Татарстан—Яңа гасыр» каналында «Яшьләр онлайн» тапшыруын алып бара. Әдилә исә «Манзара»да әлегә күренми, чөнки өйдә — декрет ялында. Кызлары Нәргизәгә яшь ярым булган. Сеңлесен 5 яшьлек абыйсы Сабир да караша икән. Җәй көне Сабирның балалар бакчасына йөрисе килми, чөнки урамда кояш, йөгереп уйныйсы, велосипедта җилдерәсе килә аның. Велосипед дигәннән, күптән түгел ул ике тәгәрмәчледә йөрергә өйрәнгән. Моның өчен әтисе белән зур парковка тапканнар.
Сабир йөрергә өйрәнгән арада әтисе дә буш тормый — лонгборд дигән роликлы тактада йөри. Күптән түгел әниләрен дә роликлы тактага бастырганнар.
Гомумән, бергә чакларны Сәфәровлар күңелле үткәрә. Аеруча су буендагы ялны бик яраталар. Данил җилкәнле виндсерфингта чыгып китә, катерга ияреп су чаңгысында йөри. Әдилә исә яр буенда суга карап утырырга ярата. Сабир белән Нәргизә өчен иң рәхәте — су буендагы комлык. Алардан соң комда төрледән-төрле уенчык машина эзләре кала. «Җәй безнең якларда бигрәк кыска шул — аның һәр мизгелен тоеп калырга тырышабыз», — ди Сәфәровлар.













Ә сез БЕРГӘ ЧАКТА ниләр эшлисез, сезнең гаиләнe нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.


Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



7'2016

Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Елена Сәетбагина

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 6.07.2016 ел.
Заказ М-1616.
Тираж 6738.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU


Мөстәкыйль тормыш корыр яшькә җиткән байтак егет әнә шулай икеләнеп кала булыр. XX гасыр башында яшьләрне борчыган бу дилемма әле дә актуаль микән? Төрле илләрдәге вазгыятьне күздән кичереп багыйк. XXI гасыр гаилә кору мәсьәләсенә карашны ни дәрәҗәдә үзгәртте икән?

Җәмгыятьтәге төрле үзгәрешләрне өйрәнү белән мәшгуль институтлар күзлегеннән караганда, имештер, яңа өйләнешүче парлар хәзер өлкәнәя бара. Шул сәбәпле, илдәге демографик вазгыять тә начарлана, гаилә корып яшәүгә карата фикер дә тискәре якка үзгәрә.

өйләнәм, өйләнмим

Социумда яңа карашлар урнашу «гражданлык никахы» дигән төшенчә барлыкка китерде. Элек мәнә ничек иде бит – йә өйләнгән (никахка кергән), йә өйләнмәгән (буйдак). Хәзер белеп бетерә торган түгел, җитмәсә, һәрбер илдә төрлечә.

Никахта торучылар (%, төрле илләрдә, 2015 ел)




Россия АКШ Нигерия Голландия

Өйләнешеп яшәүчеләр
«Гражданлык» никахында торучылар
Никахта тормыйлар (балалар, егетләр, буйдаклар, ялгызаклар)


Шунысы кызык: рәсми никахлар өлеше аеруча аз саналган Голландиядә балалар үзләрен бик бәхетле хис итәләр. Дөньядагы иң талантлы балалар да шул илдә яши икән. Гаилә коруга карата катгый кануннар сакланган илләрдә яшь белгечләр әзерләү мәсьәләсендә кыенлыклар бар икән. Уйланыр нәрсәләр бар монда.

Беренче мәртәбә никахка керүчеләрнең уртача яше һәм Европа илләрендә уртача гомер озынлыгы



Безнең заман кешесе гаиләсенә (балаларына) вакытны күбрәк бүлә (процентларда). Гаилә башлыгы булган ул кеше үзе дә шәхес, беркадәр тормыш тәҗрибәсе, белеме (хәтта ки берничә дипломы) булган гражданин.

Никахка кермәүнең сәбәпләр күрсәткече (%, 2015 ел. Россия, *Татарстан Республикасы)



* Татарстан буенча уртача күрсәткечләр Россиянеке белән тәңгәл килә. Әмма Татарстанда ир-атларның туачак балаларына мөнәсәбәте уңай булу, хатын-кызларның иң башта гаиләнең иминлеген тәэмин итү белән ныграк кызыксынуы күзәтелә.

Баш мөхәррир сүзе



Һәр өлкән буын яшьләрдән гаеп эзләргә ярата. Имеш, киенүләре – кешечә түгел, кыланышлары – кырга сыймый! Безнекеннән үзгә булган фикер сөрешләренә кадәр кабул итүе кыен. Кешелек тарихының буеннан-буена, һәр гасырда кабатлана бу күренеш: өлкәннәр сукрана, яшьләр үзләренчә яши бирә. Шулай инде ул – яңа буын яңача яшәргә дә тиеш!


Олыгаюым җитмиме әле – мин бүгенге яшьләргә сокланып, кызыгып карыйм. Мөмкинлекләре чиксез! Алар акыллы, максатчан, үз сүзләрен әйтә, тормышта үз урыннарын эзли һәм таба беләләр! Чит телләрне су урынына эчә, бүген – Казанда, иртәгә Франциягә, берсекөнгә Исландиягә чыгып китә алар – трай тибеп йөрергә димим, эш белән. Безнең кебек айлап җыенып, бар «ул-бу»ны кузаллаган чемоданга ни саласын атналап уйлап тормыйча гына – кошлар кебек, самолетка сикерәләр дә – иртәгәсен дөньяның икенче почмагында булалар. Чөнки алар инде дөнья кешеләре. Һәм бүгенге дөнья шуның өчен көйләнгән – секундында «ялгый» торган аралашу мөмкинлекләре илләр, кешеләр арасын кыскартты да куйды («Почта-телеграф»ка барып, башка шәһәр белән биш минут сөйләшүгә тилмереп чират көтеп утырган чакларны хәтерлисезме?) Заманча технологияләр дә тормышка күбрәк яшьләргә ияреп керә – безнекенә дә, республикабызныкына да. Кайтсыннар гына алар киткән якларыннан, чит илләрдә калмасыннар иде! Монда инде яшәү, эшләү шартларыннан тыш, тамырлар көче дә кирәк. Аллага шөкер, күбесендә көчле икән әле ул – татарлыкларын онытмыйлар, Татарстан, Казан кадерле аларга!

Әлбәттә, мондый балалар үстерү җиңел түгел. Баланың рухи һәм интеллектуаль үсеше тигез барсын, җаны да тәне дә бердәй сау булсын дисәң, игътибар да, вакыт та, акча да, көч тә кирәк. Шуңа күрә гаилә коруга, бала табуга җаваплы һәм күп таләпләр куя торган гамәлгә караган кебек карыйлар бүген. Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге республиканың ЗАГС идарәсе белән берлектә авылда яшәүче ирләр арасында уздырган сораштырудан күренгәнчә, күбесе ишле гаиләләрдә үскән булсалар да, үзләре күп балалы гаилә булдыру өчен финанс мөмкинлекләре юк дип саныйлар икән. Бала саны теләгәнчә булсын өчен беренче чиратта эш һәм стабиль хезмәт хакы (71%), торыр йортың (43%) булуы кирәк, дип саный алар. Аннары инде балалар бакчасы, мәктәп, поликлиника кебек шартлар зарурияты (35%), ана капиталы (20%) һәм өлкән буын ярдәмен (7%) кирәксенәләр. Бу әле – «баланы үзе тәрбияләп бирә торган» авыл җирендә. Ә шәһәрдә? Әйе, күңелсез мисаллар да күп. Наркобизнес корбанына әйләнүче үсмерләр, көч куймыйча гына акча табу юлын эзләүчеләр... Фахишәлек мисаллары хәзер кызлар арасында гына түгел, егетләр арасында да барлыкка килгән икән – яңа буын альфонслар тартынып, кыенсынып тормый. Калабыз уртасындагы урамда чибәр-таза, чиста-пөхтә (кемнәрнеңдер кадерләп үстергән малайлары!) үсмерләр үзләрен урта яшьтәге ханымнарга тәкъдим итеп йөрсен инде!

Аллага шөкер, күз алдында торган яшьләребез башка! Бергәләп сокланыйк – аларга да, милләтебезгә шундый балалар үстереп биргән әти-әниләргә дә!

Ләйсән ЮНЫСОВА

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





ЯЗ, ЕЛЕНА, КАЗАННЫ!
Л. Әбүдәрова
22

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



АСРАУ ИРЛӘР БАЗАРЫ
М. Авзалова
8



14
RUKAMI.TATAR
Г. Хәсәншина




12
БУЙДАКЛАР ЙӨРИ ТИЛМЕРЕП...
Ф. Мостафина

МӨСЛИМНЕҢ ЭНҖЕ БӨРТЕГЕ
Э. Закирова
18

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





«ЯРАТЫП ТУЙМЫЙЧА КИТӘБЕЗ...»
Г. Сафиуллина
26

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



38 **ТУРГАЙ**
А. Юнысова

ЯШӘЕШ 



46 **БЕЗНЕҢ ҖЫР!**
Г. Әдһәм



48 **БИЩЕНЧЕ КЫЙТГАДА**
Р. Исмәгыйлева

ШУЛАЙ УК: 

34 **ИРЕК**
Х. Ширмән

42 **БӘХТИЯР**
Л. Лерон

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58 **ГӨЛСИРИННӘН ТӘМЛЕ СЫЙ**

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

«ЮК, БАРЫБЕР ОНЫТЫП БУЛМАДЫ!» АТНАБАЙ МӘХӘББӘТЕ

СОҢАРЫП ЧЫККАН КОЯШ. ХИКӘЯ

«ӘТИ, БЕЗ БИТ СИНЕҢ БЕЛӘН ТУГАН...» ЯЗМЫШ

МАСТЕР-КЛАСС. ТАНСЫККА – ТОМАТ АШЫ



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Әнием Яруллина Майсәрвәрнең язмышы – татар хатынының сабырлыгына, тырышлыгына, карусызлыгына, шөкер итә белүенә бер мисал.

Ул 1936 елны Биектау районының Әлдермеш авылында туган. Әтиәниләре гарип булган гаиләдә өч кыз үскән. Бик авыр булган аларның балачагы. Олы апалары Маһиҗиһан хәтта хәер сорашып та йөргән. Әнинең яшь чагыннан калган бер сурәт саклана бездә. Ул анда ниндидер ят кием киеп төшкән. Кигән күлмәге бик фәкыйрь булгач, фотога төшерүче аңа үз костюмын кигереп торган икән.

Туйганчы ашау күрми, юньле кием кими буй җиткергән әниемне әти Олы Кавалга урлап алып кайткан. Әтиләрнең дә тормышы мактанырлык түгел – яши торган йортларында җиһаз түгел, хәтта идән дә булмаган. Чишмәгә суга барганда да көянтә-чиләкне күршеләрдән алып тора торган булганнар. Күрше-күлән әниләргә берәр кашык, берәр тәлинкә керткән. Әти урын-җир урынына бер кочак салам алып кайтып түшәгән. Ярлы булса да, әти үзе тырыш кеше булган. Казанга җәяүләп бәрәңге сатарга йөргән. Әни үзе дә тырыш иде, гомере буена колхозның бозауларын карады. Яшь гаилә бу йортта озак тормаган. Авылның тау башында яңа йорт салып чыкканнар. Әни ике шакмак шикәр хакына кышын кешеләргә кер уа, язын өйләр юып бирә, җәен бәрәңге бакчаларын утый торган иде. Безне – алты баласын шулай үстерде ул. Укый-яза белмәсә дә, Казанга кадәр барып, Соцгородтагы хуҗалык тауарлары кибетендә дә эшләде. Бу кибеттә аның ике апасы да эшли иде. Алар гел безне кайгыртып яшәде.

Безнең әни бик матур итеп җырлый иде. Бригада хатыннары белән эшкә чыккач: «Эшеңне үзебез эшләрбез, син безгә җырла гына», – дип әйтә торган булганнар. Моңлы кеше бәхетсез була, диләр. Бәхетсез үк булмаса да, күпне күрде әни. Беренче улы – Газинур абый сәламәт түгел. Авылда туган булса, сау-сәламәт булыр иде дибез дә, күрәчәктер инде... Әни аны Казанда тапкан. Ул чор машиналар заманы түгел – яшь баласы белән авылга ат арбасында кайткан. Бәбине биләп бирүче шәфкать туташлары дөрес төрмәгәннәрдерме, кайта-кайта, абый юлда биләүсәсенә буылган. Зәңгәрләнеп килгән баланы үлде, дигәннәр. Шулай да абый исән калган. Бүген әни аның белән яши. Абыйның бер кулы юньләп әйбер тотмаса да, керен дә уа, идәнен дә юа белә. Әни өчен үлеп тора.

Мине дә басуда, трактор кабинасында дөньяга китергән әни. 1974 елның 18 октябрендә – көзнең иң пычрак вакытында бәбигә авырый башлагач, аны тракторга утыртып, больницага алып киткәннәр. Мин инде анда кадәр түзмәгәнмен, юлда барганда ук туарга ашыкканмын.

Толлык ачысын да татыды ул. Миңа – өч, энемә бер яшь булганда, ашказаны чиреннән әтиебез үлеп китте. Эшкә елап барган, елап кайткан әнигә: «Үстерә алмассың, акчаң да җитмәс, балаларыңны дәүләткә тапшыр», – диючеләр булган. Берсенекен берсе киеп булса да үсәрләр әле, дип, әни беребезне дә читкә җибәрмәде. Чынлап та, мин апаларымнан калган кызлар киемен киеп үстем. Инде клубка чыгар чаклар җиткәч тә өстемдә изүләре чигүле кызлар пәлтәсе иде. Ярлы тормышта үссәк тә, беребез дә югалып калмады. Габделнур абый бүген полиция капитаны дәрәҗәсендә. Мин үзем дә әллә ничә җирдә укып, бик күп белгечлек алдым. Алты яшемнән гармунда уйнарга өйрәндем. Курай, кубызда да уйный беләм. Әниләргә күрше булып, үз авылыбызда йорт салып кердем. Апаларның исә үз тормышы. Әлфинур апабызга гына язмыш аяусыз булды. Башта дүрт кечкенә баласы белән тол калды. Аннары бер баласы язгы чәчү вакытында сука астында калып гарипләнде. Боларның барысын да үз йөрәге аша кичереп яшәгән әниебезгә быел 80 яшь тула. Олыгаеп килә инде, зиһене дә чуалгалый. Яшьлегендә рәхәт күрмәде, инде әниебезнең картлыгы тынычта, рәхәттә узсын дип тырышабыз.

Илсур ЯРУЛЛИН.
Биектау районы,
Олы Кавал авылы.

Әниемнең әнисе – Саттарова Гөлбаһар Мөхәммәдиша кызы 1903 елда хәзерге Апас районы Иске Әнәле авылында туган.

8 яшендә каты авырып китә ул. Үлде, дип, берничә көн аңсыз яткан баланың битенә ак яулык ябалар. Әбисе генә оныгының үлгәненә ышанмыйча, бертуктаусыз дога кыла, җиде ясин чыга. Күпмедер вакыттан соң дәү әнием күзен ача. Шуннан соң 86 яшенә кадәр яшәде ул. Авылдагы хөрмәтле кешеләрдән булды.

Әбием күз тиюләрдән, төрле авырулардан өшкерә, хәтта тимрәүне дә дәвалый иде. Куркулык кою өчен махсус кургашын тотты. Әллә укыган догалары, әллә тыны шифалы идеме – килгән бер кеше терелеп китә иде бездән. Җәй көннәрендә әбием төрле шифалы үләннәр җыеп киптерә – өйгә үлән исе тарала иде. Безнең өйдән беркайчан да кеше өзелеп тормады. Килгән кешене өшкерә, өшкергәннән соң сөйләндереп утыра иде. Үзенчә шифасын тикшерүе булгандыр инде. Күз тиюдән өшкерә башласа, авызын ачып иснәргә тотына. «Менә, шайтан өшкергәнне яратмый, иснәтә. Ай-яй, яман күзле кешенең күзе тигән», – дия иде. Кечкенә булсам да, бер хатирә истә калган. Биләүсәдәге бер баланы алып килделәр – төне буе йокламаган, безгә кергәндә дә акырып елый иде. Дәү әнием, баланы кулына алып, кычкырып дога укый башлады – ул шундук тынычланды. Күп вакыт үзгач, баланың әтисе улы белән әбиемә күчтәнәчкә лимон алып килгән иде. Соңгы елларда ул начар күрә башлады. Коръәнне матур итеп яттан укыган әбине мәҗлесләргә чакырсалар, мин озатып куям. Балалы өйгә кесәсенә конфет салып бара иде.

Әбиемнең исеме Гөлбаһар – фарсы теленнән «яз гөле» дип тәрҗемә ителә. Авылда аны Гөлбадран тәтә диеп йөртәләр – минем моңа ачуым килә иде. 1989 елда корылык булды, игеннәр көйде. Дәү әнием 1 июльдә бакыйлыкка күчте. Аны җирләп кайткач, коеп яңгыр яуды. Авыл халкы, Гөлбадран тәтә яңгыр яудырды дип сөйләде... Шуннан озак та үтми зиратына барсак – дәү әнинең кабере өстенә гөлбадран үскән, хәтта чәчәк тә аткан иде.

Миңа ул һәрвакыт: «Син җиләкҗимеш бик яратасың, Әстерханга кияүгә чыгарсың. Югары уку йортын тәмамларсың...» – дип әйтә иде. Сүзләре рас килде. Әбием йоклап киткәнче төрле догалар өйрәтә иде. Һәр көн иртән торгач, менә шушы теләк догасын укырга кушты: Ярабббәнә, ярлыка, шөкер кылдым барлыкка, / Ярлык кагучы Җәббар сән, саклагучы Саттар сән. / Саклагыл безне бәла белән казадин, / Ятим калдырмагыз ата белән анадин. / Дәүләт белән дәрман бир, / Хәерле эшкә хәрәкәт бир, / Ашыбызга бәрәкәт бир, / Малыбызга өлеш бир, / Күңелебезгә тынычлык бир, / Өч Колхуалла савабын бир. / Бездән борын үткәннәргә, / Бездән дога өмет иткәннәргә, / И Ходаем, бер Ходай! / Дөнья ахирәт мәхсүзеңне бир, Ходай. / Өч мең еллык сират күперен исән кичер, бер Ходай. / Гайшә белән Фатиманы күрше кылсана, Ходай.

Кызганыч, әбинең һөнәрләрен өйрәнеп кала белмәгәнмен. Шулай да балаларымны аның кебек өшкереп караганым булды. Әллә догаларның шифасы тиде, әллә савыгуы җитте – файдасы тиде. Догаларның шифа бирәчәгенә чын күңелдән ышанырга гына кирәктер ул...

Наилә ӘСӘНБАЕВА.
Әстерхан шәһәре.



6 июльдә Роза апабызның туган көне. 1936 елда, ике абыйсына кадерле сеңел булып дөньяга килә апабыз. Ул вакытта әниебез Мәрзия белән әтиебез Нәҗип Халитовлар Балтач районы, Балтач авылында яши.

Сугыш елларында әтине Саба районындагы Лесхоз урманчылыгына эшкә җибәрәләр. Гаиләбез елданел зурая. Ападан соң бер-бер артлы тагын алты бала туа. 1955 елда мәктәпне тәмамлап, апабыз Казанның 5 нче номерлы техник училищесына укырга керә. Токарь һөнәрен үзләштереп, «Элекон» заводына эшкә урнаша.

Ул еллардагы авырлыкларны аның хәзер дә исенә төшерәсе килми. Өч сменалы эш; өскә, аякка kiяргә җылы кием-салым юк. Апаның тырышлыгын заводта бик тиз күреп алалар. Ике елдан ОТК контролеры итеп күтәрәләр. 38 ел эшләү дәверендә аның хезмәт кенәгәсендә бер генә язу, ә менә мактаулы исемнәре бихисап. 80 нче елларда Мәскәү район советына депутат итеп тә сайлыйлар әле аны.

Еллар уза. Завод каршындагы тулай торакта апага урын бирәләр, һәм нәкъ шул тулай торакта ул үзенә тормыш иптәше булачак Фәрит исемле егет белән таныша. Сәер тормыш башлап җибәрә алар. Фәрит җизни дүртенче каттагы бүлмәдә өч егет белән яши, апабыз икенче катта өч кыз белән. Берберсен кичке аш вакытында гына күрәләр. Боларның шулай яшәвен күргәч, комендант аларга бер «бытовканы» (1,5х2 метрлы бүлмә) бирә. Ә инде уллары Шамил дә тугач, аларга һәм яшь балалы тагын бер гаиләгә уртак бүлмә бирәләр. Бу бүлмәдә ике гаилә, чаршау элеп, байтак еллар гомер итә.

Казанга укырга килгәч, Роза апабыз булмаса, безгә бик авырга туры килер иде. Укыганда бик ярдәм итте ул. Әле дә хәтердә: Фәрит җизни белән апабызны профком театрларга билетлар белән бүләкли. Алар үзләре бармыйча: «Сез студент, сезгә кирәгрәк», – дип, безне җибәрә. Тәнәфестә буфетка кирәрлек акчасын да кыстыралар иде. Икенче уллары Илдус тугач, аларга да аерым фатирда яшәү бәхете елмайды. Короленко урамындагы ике бүлмәле фатирга сөенә-сөенә күченделәр. Уллары икесе дә укыды. Шамил мәктәпне алтын медаль белән тәмамлап, төзелеш институтында кызыл дипломга укып чыкты. Икенче уллары да төзүчелеккә укыды. Инде апаларның өч оныгы, ул онықларның да үз балалары бар.

Без Роза апабызны туган көне белән котлыйбыз, әниебез урынына калган апага рәхмәтебез чиксез.

Барлык туганнары исеменнән –

Лена НӘҖИПОВА.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU




Фото интернеттан алынды

АСРАУ ИРЛӘР БАЗАРЫ



Мәдинә АВЗАЛОВА

АЛЬФОНС ИРЛӘРГӘ ҖИТДИ КАРАГЫЗ! БҮГЕН АЛАР ҮЗЕНӘ БЕР СОЦИАЛЬ КҮРЕНЕШКӘ ӘВЕРЕЛДЕ. ХАТЫН-КЫЗ ИСӘБЕНӘ ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕҢ – ҮЗ БИЗНЕСЫ, ҮЗ ИМИДЖЫ, ХӘТТА ҮЗЛӘРЕНЕҢ БЕРЛЕГЕ ДӘ БАР.

Булачак язма өчен материал туплый башлаганчы ук теманың гаять четерекле булуына төшенгән идем инде. Бердән, альфонс ирдән зыян күреп суд, прокуратура юлын таптый башлаган хатын-кызның бездә кайгысы юк. Икенчедән, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат үзәге хезмәткәрләре дә: «Альфонслар белән махсус шөгыльләнмибез. Ә аларның корбаннары сезнең халык белән элемтәгә керергә теләми», – дип кенә куйдылар. Шулай да альфонс-кырыкалдар француз Франк Пиксиолиның илнең төрле почмакларына (Тверь, Мәскәү, Владимир, Вологда, Новгород, Мәскәү өлкәсе һәм шул исәптән Казан да) чәчелгән корбаннарын күз алдына китердек тә, мәхәббәт дигәндә җанын кыеп бирергә әзер торган беркатлы, ышанучан хатын-кызларыбызны кисәтергә, берни белән дә аклап-аңлатып булмый торган шикле мөнәсәбәтләргә

кергәнче, муеныңа богау кигерткәнче мең кат уйларга кирәклеген, шундый «егет солтаннары» белән башта оҗмах рәхәте, аннары тәмуг уты күргән хатыннарның гыйбрәтле хикәяте аша күрсәтеп бирергә булдык.

Дөресен әйтик, аларны эзләп табу, сөйләштерү җиңел булмады. Кемнең инде үз маҗарасын дөньяга чәчәсе, белгертәсе килсен?! Шуңа күрә аларның исемнәре дә, кайбер вакыйгалар да үзгәртеп бирелә.

Хатыннарның яраткан уенчыгы

Альфонс ирләрнең көннән-көн үрчи баруына хатын-кыз үзе гаепле. Ул аны үзе эзләп таба. Альфонсның әйткән шартларына, таләпләренә үзе бик теләп риза була. Гадәттә, моны акчасын кая куярга белмәүче бай хатыннар эшли. Кесә тулы акча, ә сөю-ярату дигән нәрсә юк. Күзе төшкән ирне үз башына маҗара эзләгән хатын яраткан уенчыгы итә. Тик уеннар гына озакка бармый. Альфонс сөяркә ролендә озак булырга яратмый. Ул, гомумән, беркемне яратмый. Ул акча ярата. Хатын-кыз аның өчен – акча капчыгы. Кырыкалдар-альфонс һәрчак эзләнүдә. Кайда нинди бай хатын – ул шунда! Аннан мөнәсәбәтләрне ачыклауны, ялгышын төзәтүне, хатынны ни өчен ташлавын аңлатуын көтмәгез! Ул аны эшләмәячәк. Ул мине генә ярата, дип хыялланмагыз! Әйткәнемчә, ул андый хисләрне белми, ул андый хисләрдән мәхрүм. Кыскасы, циник. Моның ишеләрнең тугрылыгын бернинди алтын-көмешкә дә сатып ала алмыйсың. Әлбәттә, хатын-кыз башын югалтмаса, үзе теләп барган адымның кайсы мәлдә кая китерәчәген яхшы күзалласа, ике кеше катнашындагы бу «спектакль» фаҗигасез, тыныч кына үтеп китәргә дә мөмкин. Мәхәббәткә «бизнес» кебегрәк караган хатын-кызлар аз түгел бит. Янәсе, акчага барын да сатып алырга була.

«Сиңа кем карасын?»

– Мәхәббәтне сатып алып булмый икән, – дип башлый ул сүзен. Күреп-сизеп торам: баштан кичкәннәрне сөйләве түгел, искә төшерүе дә авыр аңа. – Без аның белән фитнес-клубта таныштык. Атнага ике мәртәбә мин шунда йөрим. Кыяфәтен күрсәгез: озын буйлы, төз гәүдәле, төскә-биткә чибәр... Ә сөйләшүе... тыңласаң, җаныңны эретә. Аңа бер күрүдә гашыйк булдым. Ирем белән аерылышкан чак. Балаларым юк, акча проблемасы юк. Минем – үз бизнесым. Үзем аны тыңлыйм, ә үзем эчтән генә уйлыйм: ияреп кайтса, алып кайтам. Сизендем сизенүен, тикмәгә генә болай матур «сайрамый». Комплиментлар әйтергә, хатын-кызны үзенә каратырга махсус өйрәнгән бит бу. Ләкин озак сайрап тормады, шундук әйтеп салды: «Бүген соңгы көнем, акча яклары такырайды». Һәм туп-туры күземә карады. Нидер көтә иде сыман ул. Ә мин уйлап та тормыйча: «Әйдә, үзем түлим, мин бай», – дигән булдым. Ул шундук мине битемнән үбеп, кочып алды.

Әйе, уйлавымча, егетем артымнан ияреп кайтты. Минем «апартаментларны» күрүгә, нишләргә белмәде. Чүт артына егылып китмәде дисәм дә, арттыру булмас. Шул вакыт: «Үзе нинди шартларда яши икән?» – дип уйлап куйдым. Беләсе килә иде. Кайдан ул, кем ул, гаиләсе булганмы, балалары бармы? Китәргә җыенмавын аңладым. Миңа аның белән рәхәт иде: ишетәсе килгән матур сүзләрне ишетәм, теләгемә ирештем – сөеләм, кочагында кинәнәм. Төштәге сыман гына булып бер ай үтеп тә китте. Ә егетем эшләргә уйламый да. Баксаң, ул эшсез, һөнәрсез һәм шыр ялангач икән... Кыяфәте генә бар инде.

> *Аның белән беренче көннәрдә генә, мөнәсәбәтләр әле башланып килгәндә генә күңелле. Башта хатын-кызга сөеклесе белән уздырган һәр мизгел бәйрәм кебек тоела. Мәхшәр бер-ике айдан башлана...*

«Бәлкем эшкә керерсең, телисең икән, үзем урнаштырам», – дигәч, бала-чага кебек йөзен чытты, үпкәләде. «Эшне аны мин үзем дә табам, – диде дә, – канәгать түгел икәнсең, китәм», – дип җыена ук башлады. Мин курка калдым. Ул да китсә, нишләрмен, дим. Эшләмәве белән килештем. Акчасыз түгел лә мин. Аны гына ничек тә тотармын... Бер көнне ул миңа: «Мин синең соңгы шансың. Миннән башка син беркемгә дә кирәк түгел. Әзрәк көзгегә күз төшергәлә», – дип, җир белән тигезләп куйды. Туктаусыз кабатлый торгач, ышандым: чыннан да, иллегә таба барган хатын-кыз кемгә кирәк. Гомергә ялгыз калсаң нишләрсең?

Ике-өч ай үттеме икән, акча сорый бу миннән. «Кредитымны капларга акча бир», – ди. Оялмый да, бернинди уңайсызлану да кичерми. Бирмичә дә булдыра алмадым. Ияләшкән идем инде мин аңа. Яратам да шикелле. Кулына 450 мең сум акча тоттырып чыгарып җибәрдем.

Кичен кайтты да диванга ауды. Чырае киткән, йөзе караңгы. «Ни булды? Акчаң җитмәдеме әллә?» – дим. «Бөтен кеше – руль артында, гарьләнәм...» – дип мескенләнә бу. Ишетмәмешкә салыштым. Әмма икенче көнне тагын шул ук сүзне кабатлады. «Синең дә, әнә, машинаң бар...» – ди. Әйтеп булмый ич аңа, эшлә дә ал, зинһар, дип. Үземнең дөрес эшләмәгәнемне аңлыйм, йөрәгем бертөрле киңәш бирә, ләкин үзем икенчесен эшлим. Без хатын-кызлар җүләр бит... Атна-ун көн уйланып йөрдем-йөрдем дә, кассадан тагын акча алдым. «Мә, – мин әйтәм, – алган-алган, ошаганын ал!» – дидем. Ул сөенеченнән сикереп үк куйды. Кыланмышлары бер дә ир уртасы кешенекенә охшамаган, нәкъ бала-чаганыкы төсле.

PRESSA.RU

Чирканып киткәндәй булдым. Ходаем, кем белән яшим мин?..

Ул шул китүеннән өйгә әйләнеп кайтмады. Машинасы да юк, үзе дә... Эзлим дисәң – адресын, өй телефоныннан гына аралашкач, кесә телефонының номерын да белмим. Полициягә мөрәҗәгать итә алмыйм, чөнки ирем түгел. Аннан соң, бәлкем, әле ул исем-фамилиясен дә миңа алдап әйткәндер. Чынында ул Сергей түгелдер, ә бәлкем Александр исемледер. Кем белә?! Альфонс кармагына килеп эләккәнемне шунда тәмам аңладым. Күзләрем ачылып китте. Үземне сүгәм, ир күрмәгәндәй, дим. Ничекләр итеп бер күргән кешегә шулкадәр акча чыгарып салырга була? Тир түгеп, тынгысыз хезмәттә, җунле-башлы йокы күрмичә эшләп тапкан акча бит... Күктән яуган акча түгел. Интернетка кердем. Анда альфонслар турында күп язалар, хәтта фотоларын куялар. Шулай утыра торгач, ни күрим, минем «сөеклем»нең фотосы... Хәзер исемен дә хәтерләмим, бер хатын-кыз: «Сак булыгыз! Альфонс!» дип, минем ише җүләрләрне кисәтеп, чаң сугып ята. Их-х, мин әйтәм, ник алданрак ачып карамадым. Миллионлап акчамны суга салмый идем. Җаным да кыйналмый иде. Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас, акыллы гына хатын үзем югыйсә.

Хатын полициягә хәбәр иткән. «Белмим, ни белән бетәр, акчамны кайтара алырмынмы-юкмы? Үзем биргән акча бит, талап алмады», – ди альфонс корбаны, көрсенеп.

Алдана икән (ә бу, альфонс белән араны өзмәгәндә, һичшиксез, шулай булачак), хатын-кыз үзенә үпкәләсен. Барысын да мәхәббәт белән акларга ярамый бит...

«Этең булырга да риза...»

«Миңа инде 45 яшь дисә дә», ул бик яшь күренә. Гомеренең яртысыннан күбрәге узылса да, үзен Эльвира дип таныштырган ханым бер генә мәртәбә дә кияүгә чыгып карамаган. «Ә нәрсәгә? – ди ул мине гаҗәпкә калдырып. – Ир кирәк булса, интернетны ач та кара, кирәген сайлыйсың да аласың».

Ул чираттагы «сөеклесе» белән әнә шулай җиңел генә интернет аша танышкан. Иң элек ир кеше аңа үзенең таләпләрен куйган: «Янында өй хайваны булып яшәргә дә риза мин, син миңа нык ошыйсың», – дигән сүзләр дә ычкындыргалаган.

– Читтән килгән кеше булып чыкты ул, – дип сөйли үзенең тарихын ханым. – Әллә Украинадан, әллә Белоруссиядән шунда... Кызыксынмадым да, нәрсәгә анысы миңа. Ни пропискасы, пропискасы булмагач, ни эше юк. Күренеп, күзгә ташланып тора: үзе укыган кеше, белмәгән нәрсәсе юк. «Мин төзүче-архитектор», – диде. Ышандым. «Мин – ирекле рәссам», – дигәч тә гаҗәпләнмәдем. Ул, чыннан да, иҗат кешесенә охшаган иде. Хәер, миңа аның кем булуы мөһим түгел иде. Ул баштан ук «өй сакчысы» булырга риза булды ич. Өй эшләрен карап торучы димим, өй сакчысы. Өй эшләрен карап торучы әле ул син эштән кайтуга өеңне җыештырып, ашарга пешереп бөтен эшеңне җайга салып карап куя. Ә бу кайтканыңны көтеп – өйдә ята. Юк-юк, зарланып әйтмим, үзем шуны теләдем, үзем шуңа риза булдым. Миңа, дөресен әйткәндә, ир кирәк иде. Ирләрнең төрлесен күрдем, әмма монысы... Акылдан язгандай булдым. Минем әле мондый кичерешләрдә булганым юк иде. Мин аны шашып яраттым. Яраттым дию генә дә аз, шул хәлгә барып җиттем ки, аз гына күрешми тору да минем өчен чын газапка әверелә башлады. Шушы яшеңә җитеп, бу ни эшләвең, дим. Инде бар курыкканым: китә генә күрмәсен, ялгыз гына итә күрмәсен.

Өч-дүрт ай тирәсе әкияттәгечә яшәдем. Көн саен өстәлемдә чәчәк бәйләмнәре, йөрәккә үтәрдәй җылы сөю сүзләре... Беркемнең дә моңарчы миңа шундый сүзләр әйткәне булмады бит әле. Ул мине ярата, дидем. «Мин дә сине яратам», – дидем. Ул шул сүзләрне генә көтеп торгандай: «Әнием авырып киткән, янына барып кайтмыйча булмый. Кыйммәтле дарулар алырга кушкан. Акчаң бардыр бит», – ди. Шундук акча янчыгымда күпме акчам бар, барын да чыгарып салдым. «Әйдә, бергәләшеп барып кайтабыз, бәлкем тагын нинди дә булса ярдәм кирәк булыр», – дим. Теләмәде. Бәлкем үзеннән күпкә өлкәнрәк булуымнан яхшысынмагандыр. Ул озак кына юкка чыгып торды. Хет хәбәр итсәң иде, хәлеңне әйтеп тә шалтыратмадың, дип ризасызлык белдерә башлаган идем, шып туктатты: «Мин сиңа берни дә вәгъдә итмәдем. Кайчан телим, шунда чыгып китәм, кайчан телим шунда кайтып керәм. Без бит синең белән шулай сөйләштек», – ди. Ирекле мәхәббәт... Шулай сөйләшкән идек шул. Бу юлы эшне зурга җибәрмәскә булдым. Әнисе җибәрмәгәндер, дидем.

...Ә бервакыт ул минем эшләгән җиремә килде. «Үз эшемне ачып җибәрергә форсат чыгып тора. Бер миллион акча кирәк. Каян алабыз?» – ди бу миңа. Каян булсын, миннән инде. Бирдем кирәкле сумманы. Кичен эштән кайтсам, ул өйдә юк. Шкаф ишеген ачып киемнәрен карыйм, алардан да җилләр искән. Менә шулай, ул альфонс кына булып чыкмады, карак – кырыкалдар булып та чыкты. Асрау ир алганчы, асрау бозау ал икән ул.

Альфонс Пиксиоли корбаннары

Сүзебезне кыланмышлары белән Остап Бендерны да бер якка салып куйган француз кешесе Франк Пиксиолидан башлаган идек. Хатын-кызларның йөрәген яндыручы да (ил буйлап сәяхәт итү барышында 50 хатын-кызны алдарга өлгергән), спортның үзе уйлап чыгарган, моңарчы берәүгә дә билгеле

булмаган кенджи-до төре буенча белгеч тә, ефәк туку остасы да, җырчы да, саксофонист та, барабанчы да – барысы да ул – 49 яшьлек француз.

Пиксиолиның Казандагы маҗаралары буенча да бер китап язарлык. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хәбәр иткәнчә, ул 2012 елның февралендә калабызда урнашкан спорт комплексы җитәкчеләренең берсен алдап, аннан 92 мең сум акча ала. Шул ук елның март аенда полициягә күренекле француз документалисты Рашид Ферраш мөрәҗәгать итә. Пиксиоли аның 6 мең евро торган видеоаппаратурасын урлый. Күп тә үтми, хокук саклау органнарына тагын бер күңелсез хәбәр килеп ирешә: бер ханым французны 770 мең сум акча урлап качуда гаепли. Ханымның аңа барысы миллион ярым акча бирүе ачыклана. Альфонс аз гына вакыт эчендә дә сөеклесен тәмам бөлгенлеккә төшерә. Ярый ла, аны хәзер кулга алып, тиешле хөкем карары чыгарылган. Кулга алынмаганы, җәзага тартылмыйча, тыныч кына үз этлеген эшләп йөргәне күпме тагын? Алар бит, кызганычка каршы, кимеми, ә бәлки арта гына бара. Хатын-кыз исәбенә яшәп туйганнан, тагын да баерагын тапканнан соң, талап чыгып китү – аларның кәсебе ул. Ә бизнес икән, аның үз базары, һәр базарның үз бәясе.

«Ирем – минем җилкәдә»

Кайбер хатыннарның шулай дип зарланганын ишеткәнегез бардыр. Була бит дөньяда эше бармый, эше гел уң килми торган бәндәләр. Әйтик, хатыны ике-өч эштә бөкресен чыгара, өстәвенә, бала һәм дә ир карый. Ә ир көннәр буе, эш эзләгәнгә салынып, диванда арка кыздыра. Эзләми ул эш, ниемә ул аңа. Күрәсезме, аңа болай да бик рәхәт. Тамак тук, өс бөтен, өй чиста, җылы, бала-чага каралган. Әкрен генә сыра чөмереп, футбол карый-карый газетадан игъланнар караштырып утырган була. Еллар буена шулай дәвам итә. Ә безнең хатын-кыз сабыр-түзем ул, барына түзә. Эшләмисең икән, чыгып кит, дип кенә әйтәсе бит югыйсә. Ни өчендер, хатын-кыз үз җилкәсендә яткан сорыкорт ирләрен беркайчан да альфонс дип атамый. Ә бит алар чын мәгънәсендә альфонс, бер уйласаң!

> *Альфонслар кырыкалдарларның җәзага тартуы бик катлаулы булган бер төре ул. Быелның биш аенда гына да республикада 2513 алдау очраклары теркәлгән.*

Шушы темага сүз чыккач, бер ханымның көлеп тә, ачынып та сөйләгәне хәтергә килә: «Танышым белән ресторанга бардык, – дигән иде ул, – акча түләр вакыт җиткәч, егетем миннән акча сорый. «Биреп тор, аннан кайтарырмын», – ди. Әйттем шул чагында: «Мин үземә акча табармын, син үзеңне үзең кара инде», – дидем дә чыгып киттем. Ирләр өчен акча түләргә гадәтләнмәгәнмен. Көчле, максатчан, ихтирамга лаек булган ирләрне ятатам. Чын ирләрне яратам!»

...Шөкер, үз гомеремдә миңа андый күңелсез хәлләр белән очрашырга туры килмәде. Ходай саклады димме. Әйе, ир кеше – ул акыллы, көчле, ышанычлы, һәрвакыт синә терәк булырга тиеш. Ул дөньяга шуның өчен яратылган да. Асрамага алган ирнең кайсы хатын-кызга кирәге бар?! Бер көнлек мәхәббәт өчен дисәләр генә инде бай хатыннар...

ИГЪТИБАР.

Альфонс кармагына нинди хатыннар эләгә?

Үз гомерләрендә күп нәрсәгә ирешкән, карьера ясаган – акчалы, бай хатыннарның шәхси тормышлары күп вакыт барып чыкмый. Алар – бай, хан сарае шикелле йортларда яши. Андый хатыннар ирләр ярдәменә мохтаҗ түгел. Ә менә яннарында бертуктаусыз комплиментлар әйтеп, үсендереп торучы шәп кыяфәтле яшь ирләр булуын телиләр. Акчасыз ирләр куркытмый аларны. Тик менә «шәп» ирләрнең проблемалары гына муеннан ашкан икән: кайсыныңдыр әбисе каты авырып, кыйммәтле даруларга мохтаҗ икән; кайсыныңдыр сеңлесе бәлагә тарыган... Шулай итеп, бичара хатын-кыз, альфонс ирнең кармагына кабып, аның мәшәкатьләренә чума.

Ничек танып белергә?

Беренчедән, альфонсның тышкы кыяфәте үк үзенә тартып тора. Ул зәвык белән киенә, тренажер залларына, матурлык салоннарына йөри. Еш кына авыр язмышын сөйләп үзен кызгандыра. Ул – чын тел бистәсе. Хатын-кызны мактарга дигәндә, аңа гына куш..

Ничек сакланырга?

Гашыйк булсагыз булырсыз, әмма акча янчыгын эчкәрәк яшерегез. Беркайчан да, бернинди очракта да үз исемегезгә кредит алмагыз. Әле әҗәткә биреп торган акчагызны да бүтән күрмәссез. Альфонсның кире кайтара торган гадәте юк аның. Ә иң мөһиме: кыйммәтле әйберләрегезне, малмөлкәт документларын ят күзләрдәнерактарак тотыгыз. Ышанып, яңа танышыгызны пропискага кертмәгез, кыйммәтле бүләкләр бирмәгез. Ашау өчен ресторанда түләмәгез, бу – ирләр эше. Саран булып күренүдән уңайсызланмагыз.

Ир-егетләр акчагызны түгел, үзегезне яратсын. Һәрхәлдә, бу шулай булырга тиеш.

PRESSA.RU



Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе


Фото А... Сабирова

АВЫЛЛАРДА ЙӨРГӘНДӘ, ӨЙЛӘНМӘГӘН УЛЛАРЫ БУЛГАН АПАЛАР: «БЕЗГӘ КАЗАННАН КЫЗЛАР ҖИБӘРЕГЕЗ ӘЛЕ», – ДИП ШАЯРТМЫЙ КАЛМЫЙ. ҺӘМ ҖИТДИ ИТЕП ӨСТӘП КУЯЛАР: «МЕНӘ ДИГӘН ЕГЕТЛӘРЕБЕЗ БАР, ӨЙЛӘНМИЧӘ ӘРӘМ БУЛЫП ЯТАЛАР...»



Фәнзилә МОСТАФИНА

БУЙДАКЛАР ЙӨРИ ТИЛМЕРЕП...

Шәһәрдә буйдаклар проблемасы күзгә бәрелеп тормый, күп катлы таш йортлар арасында эреп югала кебек, ә менә авылда... XXI гасыр авылында буйдаклар проблемасы килеп чыкты бит әле. Һәм киләчәктә дә авылда яшәүче бөтен ир затын өйләндереп бетереп булмастыр. Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге, республиканың ЗАГС идарәсе белән берлектә, авылда яшәүче ирләрнең көнкүрешен ачыкларга алынмаса, әлеге мәсьәләнең ни дәрәҗәдә җитдилеген күз алдына да китермәс идек әле. Бармы – бар, дип йөрер, сүз уңаеннан гына буйдаклардан: «Кайчан өйләнәсең инде?» – дип сорап куйган булыр идек. Демография үзәге җәмәгатьчелекнең игътибарын авылда яшәүче ялгыз ир-атларга юнәлтте.

Өйләнмәгән, димәк, буйдакмы?

Тикшерүнең нәтиҗәләрен гади халык кына түгел, җитәкчелек тә дүрт күз белән көтте. Соңгы елларда республикада авылларны саклап калу өчен күп эш эшләнә: мәдәният йортлары, балалар бакчалары төзелә, юллар салына, үз эшен булдырырга теләүчеләргә финанс ярдәме күрсәтелә. Гаилә һәм демография үзәге

үткәргән социологик тикшерү дә беренче чиратта «Авылның киләчәге бармы?» дигән сорауга җавап эзләүне максат итеп куйган булган. Авылның хәл-халәтен аңлау өчен ир-атларның тормыш рәвешен өйрәнергә кирәк. Менә шундый изге нияттән башланып киткән дә инде бу эш.

14 район – Азнакай, Актаныш, Алексеевский, Әлки, Баулы, Кайбыч, Кама Тамагы, Лаеш, Лениногорск, Мөслим, Спас һәм Тукай районнарыннан 1300 ир-ат сораштырылган. Шулар ярдәмендә авылда яшәүче ир-атның гомуми портретын булдырганнар. «Гаилә хәле» дигән сорауга ирләрнең 19,2 проценты «Бер тапкыр да өйләнгәнем юк» дип җавап биргән. Беренче карашка, шактый зур сан кебек. Тик үзәк җитәкчесе Флера Илдарханова тынычландырырга ашыга: сораштыруда 16-45 яшьлекләр катнашкан. Әле мәктәпне дә тәмамламаган егетләр: «Бер тапкыр да өйләнгәнем юк», – дип җавап бирсә, аларга кичекмәстән «буйдак» дигән ярлык тагарга кирәк, дигән сүз түгел бит әле! Гомумән, социологиядә «буйдак» дигән төшенчә юк, шуңа күрә алар бу сүзне «өйләнмәгән ир» дип төзәтә. Бөтен өйләнмәгән ир-атны буйдак категориясенә кертү дөрес түгел», – ди үзәкнең баш фәнни хезмәткәре Чулпан Илдарханова.

Социологиядә булмаса да, халыкта «буйдак» дигән сүз киң таралган. Бу темага багышланган җырлары да җитәрлек, мәкаль-әйтемнәре дә. Әнә берсе: «Буйдак, утызга хәтле үзе өйләнмәсә, утыздан соң куркып өйләнмәс», – ди. Тикшерү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, авылда өйләнү яшен кичектерү күренеше киң таралмаган икән. Алайса шәһәрдә яшәүче ирләрдән еш кына, Европадан үрнәк алып: «Башта укып бетерәм, аннары эшкә урнашам, аннары фатир алам, аннары гына гаилә корам», – дигән фикер ишетергә туры килә бит. Бу чылбырны төзеп бетергәнче, өйләнү яше үтеп киткән, гаилә кору теләге дә сүрелгән булуы ихтимал.

Түшәмгә төкереп ятмыйлар

Авылда яшәүче ирләрнең көнкүрешен тикшергәндә, миграция мәсьәләсенә дә зур урын бирелгән. Ә ул, үз чиратында, һаман да шул гаилә кору проблемасына барып ялгана. Күпчелек авылларда, колхозлар таркалу сәбәпле, эш калмаган. Шуңа күрә ирләр вахта ысулы белән башка авылларга, район үзәгенә яки шәһәргә йөреп эшли. Моңа бәйле рәвештә: «Шул шәһәрдә торып та кала инде алар, кире авылга кайтмый», – дигән фикер калыплаша башлаган иде дә инде. Тик Гаилә һәм демография үзәге башка нәтиҗә чыгарган: ирләрнең күпчелеге – 69, 4 проценты авылыннан күченеп китәргә җыенмый. Барган җирендә өйләнеп, хатынын авылына алып кайтучылар да күп икән. Ире вахта ысулы белән йөреп эшләгән гаиләдә аерылышулар еш була, дигән фикер белән дә килешми үзәк белгечләре. Тикшерү андый очракларны күрсәтмәгән. Ир бит эшли, акчасын да алып кайта, тормышларын яхшырту өчен тырыша – акыллы хатын шуны аңламасмыни?!

Авылда яшәүче ир-атлар ни өчен өйләнми, дигән темага фикер алышканда иң еш яңгырый торган җавапны беләсезме? «Алар барысы да эчәләр бит, ә эчкечегә кемнең кияүгә барасы килсен?!» – дигәне. Саллы сәбәп бит, ышандыра торган! Тик бүгенге заманга туры килеп кенә бетми. Гаилә һәм демография үзәге белгечләре әйтүенчә, бүген эчкечелек, авылга караганда, шәһәрдә киңрәк таралган.

Авылда хуҗалык тотмый, анда эшләми мөмкин түгел, бу исә үзеннән-үзе сәламәт яшәү рәвеше алып баруны таләп итә.

Гаилә һәм демография үзәге тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләгән докладта бер җөмлә бар. «Татарстан авылларында яшәүче ир-ат – мич башында түшәмгә төкереп ята торган юләр түгел ул», – диелгән анда. Белем дәрәҗәсе югары, сораштырылганнарның 82,1 проценты җиңел машинам бар, дип җавап биргән, башка төр транспорт чараларын атаучылар да күп. Алар сәламәтлекләрен даими рәвештә тикшертеп торалар икән (74 процент). Авылда каласылары, гаиләне дә шунда корасылары килә аларның. Гаилә һәм демография үзәге үткәргән сораштыру нәтиҗәләрен ЗАГС идарәсенә тапшырган инде. Тик аның буенча нинди дә булса үтемле чаралар кабул итү өчен берникадәр вакыт кирәк, бүген-иртәгә генә авылдагы ялгыз ир-атлар проблемасын хәл итеп булмый, ди алар. Авыл халкы үзе берәр әмәлен уйлап тапса гына инде. Әлмәт Татар дәүләт драма театры Наил Гаетбай әсәре буенча сәхнәләштергән «Кызлар килде авылга» музыкаль комедиясендәге кебек, мәсәлән. Спектакльдә Мәстүрә апа туган авылы Ерыклыны коткару өчен Казаннан кызлар алып кайтып, буйдак егетләргә димли бит. Чибәрләрне күргәч, егетләрнең күңелендә мәхәббәт һәм ышаныч уяна. Туган авылларының якты киләчәгенә ышаныч. Татарстан авылларында да шундый Мәстүрә апалар барлыкка килсә, бер дә зыянга булмас иде.

КАЙДА НИЧЕК?

■ Лениногорск ЗАГС идарәсеннән хәбәр итүләренчә, районга 96 анкета таратылган булган. Аның нәтиҗәләре күрсәткәнчә, район авылларында 30-40 яшьлек 293 буйдак яши. Берочтан ялгыз хатын-кызларны да барлаганнар, аларның саны – 167. Ә Лениногорск шәһәрендә шул яшькәчә өйләнмәгән 1381 ир-ат һәм кияүгә чыкмаган 844 хатын-кыз бар.

■ Кайбыч районы авылларында 30-40 яшьлек өйләнмәгән 264 ир-егет санаганнар. Буйдакларның күбесе Олы Кайбычта яши. Аннан соң өйләнмәгән ирләр саны буенча Хуҗа Хәсән, Колаңгы һәм Олы Подберезье авыллары бара. Район ЗАГС бүлегеннән алган мәгълүматларга караганда, Кайбычта 30-40 яшьтәге кияүгә чыкмаган 92 хатын-кыз яши.

PRESSA.RU

RUKAMI.TATAR

Радмила ХАКОВА – Чаллы кызы. Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлаган. Аны гади генә итеп «журналист» дип тәкъдим итәргә дә мөмкиндер, бәлки? «Челнинские известия» газетасында эшләгән, шәһәр мэрының «Яшь белгечләргә ярдәм итү» программасы стипендиаты булырга өлгергән. Аннан – Санкт-Петербург, «Деловой Петербург» газетасы. Тагын ике елдан – Мәскәү. Бу юлы – «Сноб» журналының интернет-порталы продюсеры...

Ул кая барып чыкса – шул җирдә кинәт хәрәкәт башлана кебек тоела миңа: ниндидер бер вакыйга була, тормыш кайный, уй-фикерләр агыла, яңа идеяләр туа... Әллә киресенчә – Радмила үзе шул вакыйгаларның эченә килеп керә дә, һәрвакыт уртасында, үзәгендә каламы? Хәер, икесе дә дөрестер. Кайсы гына очракта да читтән күзәтүче ролендә түгел ул. Була да алмый!
...Башкала – башкала инде: Мәскәүдә мөмкинлекләр зуррак, офыклар киңрәк. Радмила «Домашний очаг» журналы сайты эшен җайга салуда катнаша, «Microsoft+Cosmo» проектында блог, Cosmo.ruда рубрика алып бара...
«Мин мәдәни проектларны социаль челтәрләрдә тарату, таныту белән шөгыльләнәм, – ди Радмила. – Facebook, Instagram һәм башка социаль челтәрләр – болар бүгенге журналистиканың яңа тармагы. Виртуаль дөнья дисәк тә, кайдан, ничек аралашканыңны, үзең сөйләгәннәргә үзең ышанасыңмы-юкмы икәнеңне халык барыбер сизә. Шуңа күрә, ниндидер оешма булып сөйләшмичә, алар белән чын, ихлас, гади мөнәсәбәтләр урнаштыру кирәк».
Мең хыял, мең идея белән яшәгән Радмиланың күңел түрендә яшеренгән иң зур хыялын Мәскәү дуслары белдеме икән? Татарстан бөтен дөньяга танылып килә. Бу тарихи вакыйгаларда аның да катнашасы, Казандагы үзгәрешләргә үзенең өлешен кертәсе килүе гаҗәпмени?!
Хыял белән чынбарлык арасы кайчакта без уйлаганнан күпкә якынрак бит... Бер ел элек Радмила Инстаграмда: «Парк һәм скверлар белән бәйле проектлар республикада – 140, ә Казанда – 30. Алар турында сөйләү хәзер минем эшем булачак», – дип язган иде.
Мәскәүнең мәдәният департаментындагы эшен калдырып, ул Казанга, Татарстан Президентының ярдәмчесе Наталия Фишман командасына кайтты. Озак та үтми аның турында «Rukami.tatar» проектына нигез салучы дип тә сөйли башладылар.
«Минем иң беренче SMM-проектым – мин үзем», – дияргә ярата Радмила. Аның Фейсбуктагы постлары бик күпләргә ошый! Көтелмәгән фикерләре, яңалыгы, юморы, туры сүзлелеге белән. Үзе, гаиләсе турында гына сөйли кебек, ә чынлыкта – Татарстанны, Казанны, татарны дөньяга таныта.
Сүз – әңгәмәдәшемнең үзенә.

Парклар турында. Казанда миңа «Никола-Ленивец»тагы кебек үк бурыч куелды: интернет ярдәмендә кешеләрне интернеттан аерып, табигатькә алып чыгу. Барлый башласаң, һәркемнең күңелендә парклар белән бәйле нинди дә булса бер истәлек саклана. Шуларны тупларга керештем. Дамир Фәттахов, Эдуард Хәйруллин, Тәбрис Яруллин, Петр Сафиуллин, Арина Судакова... Җылы, матур, якты истәлекләрен уртаклаштылар.

Үземдә дә бар андый тарих. Аны минем Казанга кайту тарихы диярге дә мөмкин. Татарстан белән бәйле нинди проект эшли алам дип озак уйладым. Аннан татар фастфудына тукталдым. Өчпочмакны Америка бургеры, шәрыкның шаурмасы кебек популяр итсәң иде! Ә ул бит чыннан да шундый була ала! Аш-су остасы таптым, бизнес-план төзедек, исемен уйлап чыгардык, ничек тарату юлларын барладык... Бу идеям турында дусларыма сөйләргә өлгердем! Ә бер көнне Фейсбуктагы дус кызларымның берсе: «Радмила, кара әле, син эшләргә теләгән идең, ә Казанда инде татар фастфудын ачып та куйганнар!» – дип язды. Хатына, Черек күлдә ачылыш була, дигән игъланны да «ияртеп» җибәргән. «Түбәтәй»нең ачылышына Казанга махсус кайттым. Өчпочмакларын авыз итеп карыйсы, алар өчен сөенәсе, котлыйсы килде. Черек күлдә татар фастфудын тәкъдим итү вакытында Наталия Фишман белән очрашып танышлык та инде. Барысы да бик тиз булды: ул миңа эш тәкъдим итте, ризалаштым. Ике атна дигәндә Казанда идем инде...

Rukami.tatar турында. Казанга кайтуга мин үземнең мөстәкыйль проектым турында да уйлана башладым. Open Space Marketта булганда игътибар иттем: татар темасы, татар стиле булган әйберләр шактый. Шул ук вакытта анда татарда моңарчы булмаган кием-салым да очрый. Мәсәлән, чалма. (Аларны Әлфия Галина (Пермь) бәйли булып чыкты.) Татар кызлары аны бит элек кимәгән. Минем шушы яңа юнәлешләрне, стиль, моданы – татар милли темасы белән шөгыльләнүче дизайнерларны барысын бергә берләштерәсем килде. Әчке конкуренция дә булсын анда, ярыш та, дуслык та... Теләгем – татар дизайнына моданы җәелдерү. Чөнки үземә бик ошый ул минем! Rukami.tatar шулай туды.

Татар темасы белән эшләүче талантлы кешеләр бик күп. Ярдәмчем Ләйлә белән без аларны барларга керештек, үзләре, продукцияләре белән якыннан танышып чыктык. Без бүген үзебезнең сайтта 18 дизайнерның эшен сатабыз. Аларның үсүен, тагын да киңрәк аудиториягә чыгуын телибез. Татар орнаментын, татар стилен бөтен дөньяга танытасым килә минем. Күз салуга: «Әйе, беләм, бу – татар бизәге», – дип әйтсеннәр иде. (Радмиланың үз дуслары (ә алар аз түгел!) татар бизәген таный инде. Таный һәм ярата! Мәскәүдән кунакка килгән дусты Володя Шадрин өстенә Mardesignның «Камуфляж» футболкасын кигән, ә затлы пиджагы якасына «татар кызы» значогын кадаган иде.)



Уңышлы проектларының берсе дип «Никола-Ленивец»ны халыкка танытуны саный ул. Мәскәүдән 200 чакрым ераклыкта, Калуга өлкәсендә урнашкан иҗади мәйдан ул. 650 гектарда 33 сәнгать корылмасы – күбесе агачтан ясалган. Җәй буе рәссамнар, архитекторлар, фотографлар, музыкантларның иҗади остаханәләре эшли анда, «Архстояние» дигән фестивале уза... Иҗат белән җенләнгән кешеләр анда кемпингта, агач йортларда яки хостелда яшиләр. Кыскасы, табигать белән бербөтен булып иҗат итү урыны ул. «Язын безне: «Никола-Ленивец? Әйе, ишеткән бар шикелле», – дип, теләр-теләмәс сөйләшеп, күп вакыт кире борган спонсорлар, көзгә: Әйе, беләм! Анда аяк басмаган кеше калмады түгелме соң инде?!» – дип каршы алды», – дип сөйли якташыбыз белән бер командада эшләгән Володя Шадрин. Проект турында халыкка сөйләү өчен Радмила Инстаграмны куллана. Дөресрәге: «Паркның матурлыгын сездән – килгән кунаклардан да әйбәтрәк күрүче юк!» – дип, алар җибәргән фотосурәтләрне урнаштыра. Танылган фоторәссамнарның эшенә караганда, бу гади сурәтләр паркка килүчеләрнең санын күпкә ишәйткән. (Шушы паркка нигез салган рәссам, архитектор Николай Полисскийның бер эше төшкән фотоны «Глобал» үзенә урнаштыргач, аларның аудиториясе бер көн эчендә 10 тапкырга үсә. Ул фото 330 мең «лайк» җыя!)

Rukami.tatarга дизайнерларның төрлесе тупланды. Мәсәлән, Mardesign (Ләйсән һәм Айдар Мәрданшиннар, Мәскәү) күптән инде үз брендын булдырган, аларны татар орнаменты буенча экспертлар диярге дә мөмкин. Кемдер өчен бу хобби гына: аларның әле даими партнерлары да юк, производстволары да җайга салынып кына килә. Резеда Әһлиуллова – шундыйлардан. Агач брошкалар ясый ул, яңа гына аларны эмаль белән каплый башлады. Күпләр кебек, бу шөгылен үзенә һәм дусларына ошаган мавыгу дип кенә санаган, аңа ихтыяҗ булырга мөмкин дип күз алдына да китермәгән. Интернет-кибет ачуның беренче көнендә үк: «Сатып бетердек, тагын 20 брошка кирәк», – дигән хәбәр Резеда өчен көтелмәгән яңалык булды.

Дәүләт проектлары белән эшләү катлаулы, әмма – кирәк!

Моңарчы милли темага эшләмәгән дизайнерлар да безгә тартыла хәзер. Кайчак мин моны аларга үзем дә тәкъдим итәм. Ижевск дизайнерлары кулдан кечкенә генә значоклар ясый: көймә, машина, манара, чәчәк, гейшалар... «Ә татар кызы ясап карасагыз?» – дидем аларга. «Алырлармы соң?» – диләр. «Мин алам», – дим. Бер-берсен кабатламаган ул кечкенә «татар кызлары» Казанга кайтты инде.

Безнең өчен иң мөһиме: сайтта тәкъдим ителгән әйберләрдә татар темасы (орнаментлар, символлар) заманча интерпретациядә күрсәтелсен, сыйфатлы булсын, ә дизайнерлар башка иҗатчылар белән

PRESSA.RU

хезмәттәшлек итәргә әзер торсын. Без аларның үзара аралашуын, тәҗрибә уртаклашуын, үз осталыкларын башкаларга өйрәтүләрен телибез. Бер үк мәдәни символларның күңелләренә хуш килүе дизайнерларны чыннан да берләштерә. Алар кайда яши – Татарстандамы, әллә дөньяның бөтенләй башка почмагындамы – бу мөһим дә түгел. Казан кызы Элина Гордеева, мәсәлән, көмеш бизәнү әйберләре ясый. Бүгенге көндә ул Балида яши. Мария Гыйльманова – Мәскәүдән, ул керамика белән шөгыльләнә.

Кием-салымда, аксессуарларда милли тема чагылуы күпләр өчен бүген бик актуаль. Rukami.tatarның эшли башлавы моңа тагын бер дәлил булды. Һәм дизайнерларны ул шактый рухландырды.

Яныңда китапханәдән алган китап йөртү, укуны модага кертү турында хыялланам.

Тамырлар турында. Әнием, әбием, әбиемнең әнисе, аның әнисе – барысы да укытучылар. Мин дә укытучы булырга тиеш идем... Ерак әбиләрем татар теле укыткан, әнием һәм Разия әбием – рус теле һәм әдәбиятын. Әбием мәктәп директорына кияүгә чыга һәм гомер буе авылда яши. Күп гаиләләрдәге кебек, буыннан-буынга күчеп килгән тарихи ядкарьләр бездә дә бар. Аның беренчесе – миләүшә төсендәге бәрхет тукымага алтын җеп белән бизәкләр чигеп эшләнгән калфак. Матурлыгын, затлылыгын күрсәгез! Әбидән калган борынгы каптырмам да бар. Милли әйберләр белән кызыксынуым шушы брошкадан башланды шикелле... Яңа фатирымда әбинең сандыгына да, һичшиксез, урын табылачак! Тимер бизәкле агач сандык әлегә авылда саклана. Ерак әбиемнең исеме һәм фамилиясе язылган визиткалар бар әле тагын бездә. Менә боларының тарихын белмибез... Ул сер кайчан да булса ачылырмы-юкмы?.. Шушы кадәр байлыкның барысын да әни миңа биреп куйды инде. Вакыты җиткәч, мин аларны үземнең кызыма яки улыма тапшырырмын...

Иске әйберләр җыю турында. Мавыгуларымның берсе бугай бу... Тинчурин урамында урнашкан «барахолка»га атна саен диярлек йөрим. Кызык анда! Мине инде ул иске-москы базарында таныйлар. Андагы халык сатып алучыга бик игътибарлы: нинди тема кызыксындырганын шунда ук чамалый, икенче юлы синең өчен дип махсус нидер алып чыгарга мөмкиннәр. Сатулашырга яратасыңмы, юкмы икәнен дә белеп торалар. Иң зур табышым? Нәрсәне әйтим икән?.. Казанга күчкән мәлдә өйдә бер җиһазым юк иде. Колхоз базарында бер әбидә венский урындык күрдем. «Сатыгыз әле», – дим. «Ә мин кая утырырмын соң?» – ди. Иске кием-салым сата иде ул. «Син минем өйгә кил, тагын бар әле алар», – ди. Барып алып кайттым урындыкларны.

Базарга чыккан саен һәр атнаны нидер табам аны-сы. (Тик бу базарга бик иртә торып чыгарга кирәк, төш вакытында алар инде кайтырга да җыена башлыйлар.) Борынгы чулпыга тап булдым берсендә. Икенче юлы агачтан эшләнгән ипи савыты алдым. Аңа татар орнаменты төшерелгән. Рәсемен Фейсбукка куйгач, әллә ничә кеше: «Минем әбием дә ипине шундый савытта саклый иде», – дип язды. Заманча интерьерда да бик матур күренә ул.

Татар милли бизәкле әйберләрне мин бөтен җирдән эзлим. Ә эзләсәң тапмый калмыйсың! Табам да, шунда ук интернетка куям: иске әйберне кабат модалы итеп ясау – бу да бит үткәнне саклау. Интернетта аны дизайнерлар күрә, куллана ала. Икеләнеп калган чаклар да бар: татар орнаментына бик ошаган бизәкләр очрый. «Безнекеме-юкмы?» – дип фотога төшереп танышларга җибәрәм – бергәләп ачыклыйбыз.

Милли кием турында. Өстемдәге киемем аркасында гына үземне бөтенләй башкача хис иткән мизгелләр кичергәнем бар. Моны аңлату да кыен... Узган ел Чаллыда энемнең никахы булды. Элек мулла килгәндә башка яулык бәйли иделәр дә шуның белән вәссәлам иде – никахка махсус киенү гадәте юк иде бит. Ә хәзер ул туй кебек үк мөһим. Никах модасы да бар. Чакырганда ук кисәтәләр: озын күлмәк кияргә, бөтен нәрсә ябык булырга тиеш, диләр. Мин дә махсус күлмәк сатып алдым, башыма яулык бәйләдем. Миңа бу киемнән шундый рәхәт булды! Шул ук кичне Казанга китәргә тиеш идем. Өстемне алыштырырга өлгермәдем. Шәһәргә җиткәч, «Совет мәйданы» тукталышында төшеп калдым һәм үземне каршы алучылар килеп җиткәнче, кибеткә кердем. Кешеләрнең үземә аерым мөнәсәбәтен тойдым мин шул чакта. Бигрәк тә ир-атларның. Ишекне ачып керттеләр, ачып чыгардылар... Ихтирам, хөрмәт диимме моны? Димәк, безнең Татарстанда мөселманнарны зурлыйлар.

Икенче юлы тирә-юньдәгеләрнең үземә шундый аерым игътибарын дизайнер Mira Rakhmatның пончосын киеп чыккач тойдым. Матур татарча орнамент белән эшләнгән ул. Кешеләргә бик ошый! Урамда килеп тотып караучылар, кайдан алдыгыз, дип сораучылар бар. Милли бизәкле әйберләр шактый миндә хәзер. Rukami.tatarга дизайнерлар сайлаганда, ярдәмчем Ләйлә белән алар тәкъдим иткән һәрнәрсәне без башта үзебезгә сатып алдык: киеп, тагып йөреп карадык. Проектны башлап җибәргәннән бирле өйдән берәр милли бизәксез чыкканым юк. Брошка булса да кадыйм: алар миндә әллә ничә төсле. «Бүген урамга кайсы дизайнерның нинди әйбере белән чыгам?» – дип сайлау соңгы вакытта һәр иртәнә кызыклы бер шөгыльгә әйләнде. Чаманы гына югалтмаска кирәк!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

ҖӘМГЫЯТЬ



Петербург халыкара икътисадый форум мәйданчыгында Россия инновацион регионнары ассоциациясе әгъзаларының еллык гомуми җыелышы узды. Россия инновацион төбәкләр ассоциациясе рәисе итеп янә бертавыштан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сайланды.

Әйдәүче телевизион каналлар җитәкчеләре белән Кремльдә узган очрашуда VII чакырылыш Дәүләт Думасына узачак сайлауларны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов «Татарстан командасын Дәүләт Думасына делегацияләү» дип атады. «Дәүләт Думасында Татарстан командасы булырга тиеш, бу команданың максаты – Татарстан мәнфәгатьләрен яклау», – диде ул.

Татарстан Дәүләт Советы депутатлары Дәүләт Думасына сугыш чоры балалары турында бердәм федераль закон кабул итү турында закон чыгару инициативасы белән мөрәҗәгать итмәкчеләр. Соңгы мәгълүматларга караганда, бүген Россиядә сугыш чоры балалары статусына ия булырга мөмкин 12 миллион кеше яши.

Быелның 1 июленнән Россиядә «Авыл хуҗалыгын исәпкә алу» кампаниясе башланды. Исәпкә алу барышында авыл хуҗалыгындагы терлек саны белән бергә, бакчадагы агач-куаклар, умарта ояларын да теркиселәр. Кампания 15 августка кадәр дәвам итәчәк.

КОТЛЫЙБЫЗ

Шагыйрә, С. Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты Илсөяр Иксановага Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исем бирелде. Аңа бу дәүләт бүләген ТР Премьер-министры Илдар Халиков тапшырды. «Сөембикә» журналында әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкләгән Илсөяр бүген «Түгәрәк уен» журналының баш мөхәррире.



МӘДӘНИЯТ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов «Казан» гаилә үзәге янында «Ир-ат һәм хатын-кыз» скульптура инсталляциясен ачты. «Яңа скульптуралар Казан бизәге булыр», – дигән өмет белдерде ул. Канатлы еланнар (Казан символы) һәм барслар (Татарстан символы) заманча скульптура сәнгате объектлары проектларының авторы – скульптор-архитектор Даши Намдаков.



«Казан Кремле» музей тыюлыгында «Минем гаиләмнең шәмаиле» II Бөтенроссия сәнгать конкурсының күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәгә килгән эшләрне өч мәйданда – Ислам мәдәнияте музеенда, Татар шәмаиле галереясында һәм «Эрмитаж-Казан» үзәгендә карарга мөмкин.

Татарстан язучылары үзләренең XVIII корылтаен уздырды. Корылтай халыкара төсмер алды: анда Мәскәүдә, Кырымда, Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар язучылары да катнашты. Татарстан Язучылар берлеге рәисе итеп драматург Данил Салихов сайланды. Яңа рәисне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кабул итте. Очрашу вакытында алар Татарстан Язучылар берлеге эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр һәм татар язучылары алдында торган бурычлар хакында сөйләштеләр.

ДИН

Казан-Арена стадионында зур табыннар белән ифтарлар узды. Ислам динен олылап килүчеләр арасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Республиканың Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгат Сафаров, Казан мэры Илсур Метшин да бар иде. Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллинга ияреп, 10 мең кеше яшел чирәмдә намаз укыды.



СӘЛАМӘТЛЕК

Казанда журналистларның Төбәк һәм милли мәгълүмат чаралары форумы узды. Милли һәм төбәк матбугат чараларын үстерү, камилләштерү, дин һәм милләтара дуслыкны ныгыту юлларын эзләү һәм үзара тәҗрибә уртаклашу өчен быелгы форумга Россиянең 25 төбәгеннән 250 делегат килгән. Форумның пленар утырышында Татарстанның Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, «ТАТМЕДИА» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Республиканың журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык вәкиле Рамазан Альпаутовлар катнашты.

PRESSA.RU



Фото: Алмаз Закиров

КАЗАННАН МӨСЛИМГӘ ҖЫЕНГАНДА УК ИНДЕ, «БИЮЧЕ», «АКТРИСА», «РЕЖИССЕР», «БАЙКЕР»... ДИП ТЕЗЕП КИТЕП, АНЫ ӘЛЛӘ НИНДИ КӨТЕЛМӘГӘН СЫЙФАТЛАРГА ТӨРӘ БАШЛАДЫЛАР.



Эльмира ЗАКИРОВА

МӨСЛИМНЕҢ ЭНҖЕ БӨРТЕГЕ

«Ел хатын-кызы-2016» Республика конкурсының Мамадышта узган зона турында ул ялтырап, балкып кабына! Сәхнәгә экстремаль кыяфәттә квадроциклда чыгып, чынчынлап фурор ясый! Сыгылмалы хәрәкәтләр, нәфис гәүдә, зифа буй, позитив караш, уңай энергетика – җыенысы бергә кушылып, укучылары белән ясаган дебютында башкалардан шундук аерып куя аны! Менә ни өчен байкер, менә ни өчен актриса!.. Ул алкышлар, ул ни җитди жюриның да, соклануын яшерә алмыйча, иң югары баллар тезүе... Мөслим лицее директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары, югары категорияле җитәкче Лилия Ягды кызы Хәбибуллина «Хатын-кыз – лидер» номинациясендә әнә шулай таң калдыра ул чакта. Укучылары исә: «Иң шәп укытучыбыз!», «Ыспай һәм сылу!», «Таләпчән!», «Гадел!», «Ул безнең «железная леди»! – диләр аның хакында. «Лилия Ягдиевна үткәргән һәр чараның үз төсе, үз почеркы бар. Шуңа күрә аларның һәркайсы күңелләргә барып җитә, – ди Мөслим районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни эшләр буенча урынбасары Рушат Җәүдәт улы Солтанов. – Һәр бала, һәр әти-әни аның бәйрәм-кичәләреннән моңарчы күрелмәгән яңалык, бөтәннәрнекенә охшамаган кабатланмас күңелле тамаша көтә. Без шуңа күнеккән».

Йә, нинди син, «железная леди»?

...Мөслим. Тирә-юньгә җиләк исе, печән исе, чәчәк исе таралган. Ык буеннан, таулар тезмәсеннән җылы җил исә. Лицейга барыргамы, район хакимиятенә сугылыргамы дип торганда, Лилия үзе шалтырата: «Хәзер төшеп алам!» Ул да булмый, сөйкемле яшь ханым машинадан чыгып кулын суза: «Лилия булам!» Ә мин аны «Кавказская пленница»дагы Нинага охшатам. Тезләрен каплаган джинсы шортысы, яшькелт футболкасы, кискән чәчләре – бар да килешә! Үзе шук-шаян, уенчак, җитез, тапкыр сүзле. Бүгенге маршрутыбызны билгеләп тә куйды. «Башта безгә кереп җимеш бәлеше белән чәй эчәбез. Аннары Мәдәният йортында чыгарылыш кичәсенең репетициясен карарбыз, лицейга барып килербез, укучыларым белән таныштырырмын...»

Ихтыярсыз, лицей директоры Зөлфия Зәки кызы Хәкимованың Лилия турында әйткәннәре искә төште: «Беренче күрүебездә үк матур киенүләренә, төз итеп атлап йөрүләренә игътибар иттек. Районга биюне ул алып килде. Бөтен бала «Энҗе бөртекләре»нә эләгергә тырыша иде. Директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары буларак, төгәл, бүгенге эшне иртәгәгә калдырмый, таләпчән, яратып эшли...»

Менә син нинди икән, Лилия.

Руль артында барган көйгә генә, дустанә елмаеп, кемнәрнеңдер сәламен ала. Каршыга килүче машинадагылар, үз күреп, сигнал бирә. Күз карашларыннан ук белеп була: яраталар аны. «Укучыларым! – ди Лилия. – Узган ел тәмамладылар». Рульне виртуозларча оста боргалый-боргалый, зәңгәр, кызыл, яшел, фирүзә түбәле йортларны, яшел урам-тыкрыкларны калдырып, Чаллы юлындагы яңа микрорайонга алып китә. Мәчет, кибетләр күзгә чалынып ала. Урамнан узучы апалар, аны ничектер бик якын итеп, «үзебезнең Лилия» дип, ягымлы карашлары белән озатып кала.

– Яратам Мөслимне! Мөслим дип үлеп китәм инде! Әле әни исән вакытта да, Җәлилгә кайтсам, көчкә бер кич куна идем дә, кире Мөслимгә ашыга идем. Кунакка йөрергә яратмыйм. Үз өем, үз почмагым, үз мендәрем кирәк! Ярар, энекәшләрем Радист белән Рамил Җәлилдә яшәп ята бит инде. Күрешеп, йөрешеп торабыз...

Менә сиңа мә! Лилия Мөслим килене икән бит! 1990 елдан бирле инде ул Мөслимнеке. Балачагы Сарман районындагы Иске Минзәләбашта – әнисе авылында үткән. «Мине балалар бакчасында да биеткәннәр. Шундый фотоларым да күп. Мәктәптә укыганда бик талантлы, бик чибәр пионервожатый Ирина апабыз бар иде. Шул сәнгать дөньясына тартты бугай. Матур хыяллар, романтика белән яши идек. Мин, хәрби кеше булырга хыялланып: «Кызлар армиядә хезмәт итә аламы?» – дип сорап, телевидениегә, «Служу Советскому Союзу» тапшыруына хат та юлладым әле хәтта». Лилия көлә-көлә сөйли. «Бу кыз тумыштан лидер. Анда оештыру сәләте көчле», – ди торган була класс җитәкчесе. Тикмәгә генә фотосы бүген дә Иске Минзәләбаш мәктәбенең Мактау китабын бизәмидер шул!.. Аннары әнисенә Җәлилдә фатир биргәннәр. Җәлилнең 1 нче мәктәбендә укыганда ук биюе белән башкаларны әсир иткән бу чая кыз сигезенчедән соң Алабуга мәдәниагарту училищесының хореография бүлегенә укырга кергән. «16 яшемдә чыгып киткән идем әни яныннан, бүгенге көнгә кадәр читтә. Кыз баланың язмышы шул», – ди ул үзе. Ә туган җире менә – әллә кайдагы Мары шәһәре икән! Лилия өчен ул Каракум каналы, Туран түбәнлеге, Әфганстан тауларыннан башланып киткән Мургаб елгасы һәм Төрекмәнстанның Ашхабадтан кала өченче зур шәһәре. Шул гына. Тик шул гынамы соң?! «Миндә шәрык каны уйный: кызу канлымын, – дияргә ярата Лилия. – Гадел булмаган әйбергә чәчрәп чыгарга миңа куш инде. Укучыларымны яклап, директорга да керәм, әти-әниләре белән дә сөйләшәм». «Төрекмән кызлары бик чибәр, биючеләрнеке кебек матур буй-сынлы була!» Монысын башкалар әйтә. Әтисе Ягды Бяшимов – төрекмән кешесе. Хәер, ана белән кызның Татарстанга кайтып урнашканнарына да байтак еллар узган инде. Баштарак әтисеннән хатлар да килештергән. Бераздан инде аралар өзелгән. «Төрекмән туганнарымны эзләп, «Жди меня»га да язып караган идем, очына чыгып булмады», – дип көрсенеп ала.

1994 елда оешкан «Энҗе бөртекләре» төркеменә балалар бөтен районнан җыела.

1990 елдан Лилия – Мөслимдә. Мәдәният йортына хореограф булып урнаша. Талантларга бай Мөслим. Шәп җырлыйлар. Сыздырып гармунда уйныйлар. Курайчылары бөтен Татарстанга танылган. Ә менә биюгә никтер игътибар җитмәгән. Күршеләр – Актанышлар, күр, ничек бии! Мөслимнәрне дә баскан җирдә ут чыгарырлык итеп биетәсе иде! Димәк, Лилия өлешенә тигән көмеш бу, югарыдан тапшырылган олы вәкаләт, җаваплы миссия. Мөслимдә генә түгел, тирә-юньдә даны таралган «Яшьлек» бию ансамбле әнә шулай туа. Аннары – малайлар-кызларның «Энҗе бөртекләре» бию ансамбле «Сандугач сайрар илем», «Ватан» республика конкурсларында лауреат була, дипломнар алып кайта. Исеме дә, үзләре дә матур шул – «Энҗе бөртекләре»! Анысын да Лилия апалары уйлап таба. Сәхнәдә энҗе-мәрҗәннәр кебек чәчелеп биюче 12 кыз, 12 малайга карап, яратып, «Энҗе бөртекләре» дип дәшә башлый ул. Олы улы Рамис та биюче әнисенең шәп шәкерте – бии! «Аңа инде 27 яшь. Армиядә хезмәт итеп кайтты. Энергетика университетын тәмамлады. Хәзер Чаллыда эшли. Кече улым Исламга 6 яшь. Ул икенче елга мәктәпкә бара».

Биюче Лилия ничек мәктәп дөньясына килеп эләккән соң? Соравымны биргәнче үк үзе тормышының шул этабына күчте.

– Мәдәният йортында хореограф булып эшләп йөрим. Баламның мәктәпкә барыр вакыты җитте, гел биеп йөреп булмас, дим. Үзе шагыйрь, үзе курайчы

PRESSA.RU



Мөҗәһит абый Әхмәтҗанов 1 нче мәктәпнең директоры иде. Ул эшкә алды мине. Бүгенге көнгәчә рәхмәтле мин аңа. Тора салып бию дигән фән укыту юк бит инде. Ә минем укытучы белемем дә юк иде әле. Бардым. «Мөҗәһит абый, баламны укырга бирәм, клубтан китәм, мине мәктәпкә эшкә алыгыз әле», – дидем. Берсүзсез алды. Бию түгәрәкләре алып бара башладым. Аннан соң физкультураның бер сәгатен алып, спорт-сәламәтләндерү дигән дәресләрне миңа тапшырдылар. Укучылар йорты директоры Наилә апа җәйге каникул көннәрендә мине лагерьга өлкән пионервожатый итеп куйды да: «Лилия, җитте, укырга кер», – диде. Тәрбия завучы Әлфия Зәйнулловна да шуны ук кабатлады. Әнә шулай Чаллы growинститутына барып кердем мин. Башлангыч сыйныфлар укытучысы дипломын алдым. Биюне барыбер ташлатмадылар: музыка мәктәбендә сәгатьләр алып бардым.

Алдына әллә нинди максатлар куеп, шуңа ирешми һич туктамый!

«Үз өем, үз почмагым»

Мөслим зур түгел: ун-унбиш минуттан инде без өр-яңа йорт каршына килеп туктыйбыз. Әле күптән түгел генә күченгәннәр. Яңа өйдә генә була торган тавышлар яңгырап ишетелерлек рәхәт иркенлек. Зур тәрәзәләрдән бәрәңге бакчалары, түтәлләр күренә. Еракта-еракта Ык тугайлары җәйрәп ята. Җәй чәчәкләре – ромашкалар, кыңгыраулар кухняга үзенчә ямь биреп утыра. «Аш пеште!» – дип елмаеп каршылый ире Илшат. «Ял көнне урманга, алма бакчасына бардык. Мин машина йөрттем!» – дип яңалыкны җитке-рәсе, мактанып аласы килә бәләкәй Исламның. Компьютер, телефон, интернет, флешка, квадроцикл, велосипед – бөтенесенең «тел»ен белә беренчегә генә җыенучы бала. Ялт кына әнисенә флешканы китереп тоттыра, компьютерны көйли.

– Икебез дә мәктәптә, мәгариф өлкәсендә эшләгәч, бер-беребезнең хәлен күз карашыннан ук аңларга өйрәндек. Илшат – мәктәп директоры. Сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен Тойгелде интернат-мәктәбенә көн саен йөреп эшли. Проблемалар килеп чыкса, гаиләдә уртага салып сөйләшәбез, киңәшләшәбез, – ди Лилия, уллары Ислам белән мәш килгән Илшатка яратып карап. – Кайчак ул әйтә, син дөрес эшләмәгәнсең, дип. Мин дә үз фикеремне белдерми калмыйм. Синең урында булсам, мин менә болайрак эшләр идем, дим. Гаиләдә дә бар да ал да гөл генә булып бетми. Кайчагында ул җайлый, кайчагында – мин. Вакытында дәшми кала да белергә кирәк икәнен бик яхшы төшендем инде. Кайчак шундый уйлар да килә башка: әгәр тормышымны өр-яңадан башларга туры килсә... туры сүзле булмас идем, кешеләргә каты итеп әйтмәс идем, кайбер ялгышларны кабатламас идем, дим... Үз-үзеңнән качып буламы соң?! Ярый әле мине аңлый торган Илшат бар. Ипле, җайлы, күп укый, күп белә ул минем. Акыллы гаиләдә үскән. Кайнатам Рафис – районда билгеле табиб, СССР сәламәтлек саклау отличнигы, кайнанам Фәнисә – мөгаллимә, Татарстанның атказанган укытучысы. Әти-әни безнең өчен куанып яшиләр. Гел уллар гына үстерсәк тә, киленнәребез үз кызларыбыз кебек, дип, гел әйтеп торалар. Килен – кайнана туфрагыннан диләр бит, хактыр: безне туры сүзлелек берләштерә. Кайчагында берәр эш эшләп куясың да, үкенеп йөрисең. Аның да, минем дә шул гадәт бар. Кибеттән берәр әйбер алып кайтам да, ошатмыйча кире илтеп бирәм. «Бу кадәр әнигә охшасаң да охшарсың икән!» – дип куя Илшат та. Без өч килен-килендәш Хәбибуллиннарда. Ничек кенә серләшәбез әле!

Лилия телефоннан укучылары белән сөйләшкән арада, Илшат: «Гел безнең әни сыман инде бу Лилия! – дип, яратып кына шелтәләгәндәй итә. – Һаман мәктәп эше, мәктәп эше, мәктәп эше!.. Дүшәмбе директорда киңәшмәдә, сишәмбе – класс сәгате көне, чәршәмбе – класс җитәкчеләре семинары, пәнҗешәмбе – укучылар үзидарәсе... Безнең әни дә кайтып керми иде шул мәктәптән».

Илшатның: «Аллаһы Тәгалә тарафыннан хатын-кызга бирелгән бөтен сыйфат та аңарда бар», – дигән сүзләре исә иң-иң зур мактау түгелмени?!

Хатыны турында ул купшы сүзләр дә әйтмәде югыйсә, ә күңелгә аермачык булып уелып калды менә: «Ихлас. Кешелекле. Гадел. Үземнән дә ныграк ышанам аңа!»

...Моннан шактый еллар элек туйда танышa Илшат белән Лилия. Күрешеп, очрашып йөрүләр... Бер-берсен сынар өчен шактый вакыт та кирәк була әле. Менә шуңа күз карашыннан ук аңлыйдыр, берсенең ни уйлаганын, икенчесенең нәрсә әйтәчәген алдан ук белеп торадыр алар.

Саубуллашу вальсы

– Үземне балалар белән тиң күреп сөйләшәм мин. Артык якын да китермим, әллә кем булып та йөрмим. Фамилия белән түгел, исемнәре белән эндәшергә тырышам. Шулай якынрак. Кирәк икән, кушаматлары белән үз итеп аралашам. Мин аларга «свой парень». Кызлар белән аулакта сөйләшергә яратабыз. Сер сыя миңа. Үземә дә киңәшләр бирәләр! Әнә берсе WhatsAppта язган, сез – супер, яшел күлмәгегез бик тә килешә, дигән. Күпләр чәчемне үстерергә куша... Убырлы карчык та, клоун да булып уйнап күрсәттем инде аларга...

Лилия, дөньяларын онытып, һаман шул укучыларын сөйли. Без район мәдәният йортына ашыгабыз. Репетициягә. Бу юлы да сценарийны Лилия Ягды кызы язган. Йокларга яткач та мәктәп эшенә чума: төнлә бию уйлап ята дисәләр, шул – Лилия Хәбибуллина турында булыр ул сүзләр. Быелгы чыгарылыш кичәсе менә шундый әкият белән башланып китәсе икән.

...Борын-борын заманда, агачлар бик зур, мәктәп ишегалдындагы сукмаклар бик озын, мәктәп баскычлары бик текә һәм биек булганда, кечкенә малайларны-кызларны әти-әниләре мәктәпкә алып килгәннәр. Менә шулай «Балачак» исемле якты матур әкият башланып киткән. Әмма бүген бу әкият безнең өчен тәмамланачак. Без зурлар дөньясына аяк басачакбыз...

Ул әлеге әкиятнең бүгенге геройлары – укучылар үзидарәсе премьер-министры Ралина, клипмейкерлар Алсу белән Карлен Григорян, разрядлы шахматчы Нияз, «рок-гитара-прическа» кушаматлы Нәфис, өч Алинә, табиб булып Канадага китәргә җыенучы Ләйсәния... Данияр, Луиза, Рәмилә, Айсылулар, унберенчеләрнең тагын әллә кемнәре турында яратып сөйләп бара. Алтын өмет, көмеш яңгыр, алтынлы-көмешле салават күпере дип, көтелмәгән чагыштырулары белән шаккаттыра. Берничә көннән быелгы унберләр белән дә саубуллашыр. Сагындырырлар инде. Күр, ничек уратып алдылар үзен! Лилия Ягды кызы турында үз фикерләре, үз сүзләре бар. Унберләрнең сыйныф җитәкчеләре Гүзәл Рәхимҗановна белән Алсу Галиевнаның да...

– Лилия Ягдиевна – көчле хатын-кыз! Үзе шундый ягымлы. Теләсә ниди ситуациядән елмаеп чыга белә. Якты күңелле чын кеше! Холкы менә дигән!

– Мөслимебезнең энҗе бөртеге!

– Безне үз артыннан ияртеп бара торган җитәкче ул!

– Талантлы! Чын лидер! Безнең хыялларны чынга әйләндерүче тылсымчы!

– Берчак бөтенесен шаккаттырырлык, күкнең җиденче катына күтәрерлек бәйрәм ясыйсыбыз килде. Ни теләгәнебезне Лилия апа шундук аңлап алды. Төн утырып сценарий язды. У-у-у! Әллә ни булды ул!

– Ул безне ничек итеп күрәсе килде, шундый итеп «әвәләде». Без чиксез рәхмәтле аңа! Яратабыз!

– Ул шундый олы йөрәкле! Укучысы Садриева Ләйсәнгә РКБда авыр операция ясагач, Лилия апа Казанга барып, аңа кан биреп кайтты.

– Лилия Ягдиевна – оста дипломат: хакимият, партнерлар белән элемтәләр урнаштыра белә. Безне бер команда булып эшләргә өйрәтте.

– «Бердәмлек» Лицей Демократик Республикасы укучылар үзидарәсен Лилия апа уйлап тапты! Безне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына парламент дәресенә чакырдылар.

– Безнең административ-уен формасындагы «Дублер көне» моделе II Бөтенроссия укучылар үзидарәсе модельләре конкурсында беренчелекне яулады!

Ул да булмый, таләпчән режиссер Лилия апаларының командасы ишетелә:

– Йә, тагын бер кабатлыйбыз!

– Сандугач, тик кенә тор әле...

– Тормозить итмибез!

– Елмаеп, елмаеп биегез!

Егетләр-кызлар вальска бөтерелә. Лилия апалары һаман өйрәтә, кат-кат кабатлата, шомарта. Рәхәт ыгы-зыгы. Күңелләрнең иләс бер мәле. Ә җанда бер көчәеп, бер ераклашып «Саубуллашу» аккордлары яңгырый.

Директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары булып 13 ел эшләп, бер сценарийны да кабатлаганы юк әле, диләр.

Җыры да җыры! Елыйсыны китереп, җаннарны актара. Ә мәктәптә – балачак, дәресләр, хыяллар, укытучылар кала.

Хуш, дускай, таң ата,
Офыклар алсу.
Бу – саубуллашу вальсы!
Бу – саубуллашу...
– Булдырасыз!

Лилия үзе дә – вальс ритмында. Менә-менә очып китәр сыман. Сагышы, сөенече – бөтенесе бергә буталган. Күзләрендә – әллә яшь, әллә чык тамчысы...



PRESSA.RU



ЯЗ, ЕЛЕНА, КАЗАННЫ!



Ландыш
ӘБҮДӘРОВА


КҮПТӘН ТҮГЕЛ «КАЗАН» МИЛЛИ МӘДӘНИЯТ ҮЗӘГЕНДӘ САНКТ-ПЕТЕРБУРГТА ЯШӘҮЧЕ ТАТАР РӘССАМНАРЫНЫҢ «ПИТЕР РӘССАМНАРЫ КАЗАННЫ ЯСЫЙ» ДИГӘН КҮРГӘЗМӘСЕ АЧЫЛДЫ. КҮРГӘЗМӘГӘ ЭШЛӘРЕ КУЕЛГАН АВТОРЛАРНЫҢ ИҢ ЯШЕ БУЛГАН ЕЛЕНА СӘЕТБАГИНА – ЖУРНАЛЫБЫЗ КУНАГЫ.


– Казан – илһам ул! – дип бер сүз белән бәяләде кыз безнең шәһәрне. – Мин биргә тагын киләм әле. – Елена Әнвәр кызының Казаныбыз турында әйткән сүзләре күңелләргә сары май булып ягылып торса да, мондагы архитектурага (борынгылык белән заманчалыкның, Шәрык белән Гареб стильләренең синтезына), табигатькә (бигрәк тә алсу шәфәкъларга), исләргә (коньяк җилләренә), төсләргә (бигрәк тә ачык, яктыларына) һәм, ниһаять, кешеләргә (иң кадерле хатирәләр – Казан кешеләре белән бәйле) соклануы турында хисләнеп сөйләвен тыңлау никадәр генә рәхәт булса да, аны бүлдереп үзе турында сөйләтә башлыйм. Хикмәт бит: картиналарында татар кешеләрен, намаздагы мөслимәне сурәтләгән рәссамның Казанга беренче килүе. Кайтуы дип тә булмый – тамырлары себер татарларыннан. Әмма күңел күзе Казанга төбәлгән. Балачактан ук...

Кайсы ташка килеп сөялмә – тарих исе аңкый. Менә шундый мохиттә үскән Елена.


Елена Сәетбагина туып-үскән Пушкин шәһәре үзе сәнгать әсәре бит әле ул. Әйе-әйе, без алтынчы-җиденче сыйныфтан бирле укып белгән Царское Село инде. Күз алдына гына китерегез: биредә Пушкин лицейда укыган; өйләнгәч, хатыны Наталья Гончарова белән җәйләрен үткәргән... Биредә ул







PRESSA.RU



сирень, шомырт, юкә чәчәкләре исенә коенып «Солтан патша турында әкият»ен язган, биредә Онегинның Татьянага хаты иҗат ителгән. Пушкинның Жуковский һәм күршедәге бистәдә яшәгән Гоголь белән аллеялар буйлап кызу-кызу сөйләшеп йөргәннәрен еш күрә торган булганнар... Хәзерге Пушкин шәһәренең Елизавета Петровнадан башлап рус патшаларының җәйге резиденциясе булуын да искә төшерик. Биредәге Екатерина сараен кем генә хәтерләми?!

– Пушкин музей кебек ул. ЮНЕСКО мирасы объектлары исемлегендә. Искиткеч матур шәһәр. Андагы йортлар, андагы бизәкләр... – Елена туган шәһәре турында да илһамланып сөйли. Илһамланмый соң, мондый шәһәрдә туып, иҗат итми мөмкин түгелдер ул?

– Әйе, – дип килешә аннары. – Үз-үземнән көнләшерлек.

Һәртөрле иҗат кешеләре өчен Санкт-Петербург (Пушкин шәһәрендә аның административ берәмлеге) үзенә бер Эльдорадо кебек. Мондагы бихисап музейлар, театрлар, иҗат студияләре һәм тарихи һәйкәлләрнең, минор һәм мажор сыннарның күплеген хәтердән генә санап бетерерлек түгел.

Башта Пушкин шәһәренең Сәнгать мәктәбе. Аннан соң Санкт-Петербургның Н. К. Рерих исемендәге сәнгать училищесы. МУХАның коммуникатив дизайн кафедрасына (ягъни хәзерге А. Л. Штиглиц исемендәге СПбДСГА, ул вакытта В. И. Мухина исемендәге сәнгать училищесы). Академиягә укырга юлда көн саен сәгать ярым бара, сәгать ярым кайта. Маршрут автобусының тәрәзәсе аша Питерның ак томаннары артындагы күпме бизәк, каршына очраган күпме кеше йөзләре аның хәтеренә сеңеп калгандыр?

Аның рәсемгә хирыслыгын белеп, таныш-белешләре, туган-тумачалары: «Лена, мине дә төшер



әле», – диләр дә, ул кулына кәгазь-каләм яки буяулар алганчы ук, урындык тотып, каршысына килеп утыралар. Һәм, шулай тиештер дигәндәй, тын алырга да куркып тораташ кебек утыралар. Аеруча кеше йөзләре – портретлар кечкенәдән кызыксындыра аны. Каршы килми Елена, берәүнең дә үтенечен кире какмый – барысын да төшерә. Тик аның портретларында хис-кичерешләр дә, хәрәкәт тә, хәтта уйлар тизлеге дә сизелә кебек. Карикатуралар белән дә мавыга. МУХАда укыганда рәсем сәнгатенең төрле техникасын өйрәнә, үзен төрледән-төрле юнәлештә сынап карый. Остазы Швалов (хәзер мәрхүм инде) аңа классик сәнгать серләрен төшендерә. Кулына кызыл диплом алганда, Сәетбагина үзе өчен шуны хәл итә: ул сәнгатьнең академик юнәлешен сайлар. Киндер, майлы буяу, классик рәссамнар кулланган техника. Янә бер техниканы үз итә: бөгәрләнгән кәгазьгә гуашь белән сурәт төшерүне Питер рәссамнары уйлап чыгара.

Укуны тәмамлагач, кияүгә чыгып, өч ел декрет ялында утырганда, академик юнәлештә эшләячәгенә тагын да ныграк инана Лена. Ни өчен декрет ялында утыргандамы? Сере гади аның: тормыш ыгы-зыгысыннан читтә үз дөньяңда яшәп ятканда, акыл тыныбрак кала, күбрәк йөрәк тавышын тыңлыйсың. Ә йөрәк ялгышмый.


Кызлары Иринага өч яшь тулгач, ул М. Горький исемендәге мәдәният сараена дизайнер булып эшкә чыга. Ирекле иҗатчыларның хезмәт хакы да «ирекле» шул, ә Еленаның гаиләсе зур. Өстәвенә, заман шаукымына бирелеп, эштер-өштер генә картина язып, акча эшлисе килми аның. Әйтте бит: академик юнәлештә эшләячәк, ә бу вакыт һәм бик зур осталык, тырышлык, җиренә җиткереп эшләгәнне таләп итә.

Казанны моңарчы күргәне булмаса да, илһамчысы Казан аның.

Ишле гаилә дигәннән, алар ире, кызы, әти-әнисе, апасы, апасының кызы – бер тату гаилә булып яшиләр. Ире – инженер-төзүче, апасы – табибә. Әнисе Инна Федоровна – хуҗабикә. Ә әтисе Әнвәр Ризван улының Санкт-Петербургның «Чишмә» дигән татар-башкорт милли-иҗтимагый оешмасын 15 ел дәвамында җитәкләвен беләбез. Әтисе «Чишмә»гә кызларын да җәлеп итә. Рәссам кызының ярдәме дә тиеп куя: Елена алар оештыра торган чараларны бизәү, полиграфия-нәшрият эшләрендә катнаша торган була. Кыз шунда татар мохите белән таныша. Гомумән, алар гаиләсендә татарлык мөселманлык белән бердәй үрелеп бара. Чыгышлары белән Себер татарлары Сәетбагиннар нәселендә муллалар да булгангамы, бу ике төшенчә кагылгысыз һәм җуелмаслык булып канга сеңгән. Әнвәр Ризван улы ике тапкыр хаҗи буларак, бу мәсьәләләргә бик сак мөнәсәбәттә. Елена Сәетбагина дигән рәссамның иҗатында бу тема каян килә, дигән сорауга җавап, шулай итеп, үзеннән-үзе табыла.

Еленаның Казанны килеп күрү хыялы да күптәнге икән инде. Рус мәдәнияте уртасында үскән кыз бала татар милләтенең рухи мәркәзендә үзен чит итеп тоймаган. Тагын очрашканга кадәр, дип саубуллашты. Төкле аягың белән, диләр бездә андый вакытта.





PRESSA.RU



Бу хатлар турында Казан педагогика көллиятенең элеккеге укытучысы, филология фәннәре кандидаты Гөлчәчәк апа Әдһәмованы гүргә иңдергән көнне ишеттем... Үкенеч үзәгемне өзде – аз гына алдарак белсәм, очрашырга, танышырга өлгерсәк, мәхәббәт тарихларын ул бит миңа үзе сөйләр иде! (Гомумән, Гөлчәчәк апаның бөтен тормышы тоташ үкенечтән торган бугай. Язмышын күбрәк белгән саен, бу фикерем ныгыды гына. Ни аяныч... Бердәнбер гомер бит ул!)

...Гөлчәчәк белән Әнгам арасында мәхәббәт уты 1948 елның көзендә кабына. Бик күп кызлар гыйшык тоткан яшь шагыйрьнең көтмәгәндә үзенә игътибар итүе әтисез үскән Гөлчәчәккә башта могҗиза булып тоела. Бу хәлгә ул бик озак ышана алмый йөри... Бу икәүнең таңга кадәр сөйләшкән сүзләре, уй-хыялларына Казан урамнары, Черек күл, Кабан күле, Лядской, Ленин бакчасында үскән сәрви куаклары шаһит. Ә аннан... аннан барысы да кинәт өзелә. Әнгам Атнабайны – яшь шагыйрьне, уку алдынгысын, бюро членын институттан куалар. Урта белемгә ия булуы турындагы документы булмаган икән. Югары белем алырга хыялланган егеткә мәктәп директоры аны яхшылык эшләп биргән була да бит... Әнгам туган авылына – Күрдемгә кайтып китә. Башкортстаннан килгән иң беренче хат сакланмаган, әмма андагы шигырь юллары кызның күңеленә гомерлеккә язылa:

Мин берүзем,
ләкин йөрәгемдә
Аерылуның мең-мең газабы.
Тик төш кенә булып калдымыни
Мәхәббәтнең гүзәл авазы?!

«ЯРАТЫП ТУЙМЫЙЧА КИТӘБЕЗ...»



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

Жәйге ялын әнисе янында үткәрергә дип авылга кайткан Гөлчәчәк Әнгамга хатларны Казанга, почтага язарга куша. (И-и, ул чакның тәрбиясе?!) Аннан үзе түзми, каникулы беткәнен дә көтмичә, юлга кузгала. Пароходтан төшүгә, чәй дә эчеп тормыйча, почтага ашыга ул. Алты хат көтә аны. Алтысы да Әнгамнан! Әмма конвертларны бер-бер артлы ача башлауга кызның сөенечен кара болыт каплый: ни бу, хатларның һәммәсен дә ул язганмы соң? Берсендә «син бер генә, син гөл генә, сине берәү дә алыштыра алмый» ди, икенчесендә «мине монда кочакларын җәеп, иркәли, назлый белә торган кызлар көтеп торган, миңа рәхәт» ди. Өченчесендә «фотоңа карап синең белән сөйләшәм, алдагы хатым өчен үкенәм, үземне тиргим» дигән юллар, аннан кабат үпкәләүләр, хурлаулар... (Соңыннан күп еллар дәвамында Әнгам кабатлаган «үзем гаепле», «синең алдагы җинаятем» дигән сүзләр – шушы хатлар турында. Аның тәкъдимнәренә Гөлчәчәкнең һәрвакыт шикләнеп караулары да – әлеге хатлар шаукымы. Институттан куылгач, киләчәккә корган планнары кинәт юкка чыккан, юллар чатында нишләргә белмичә калган егетнең бәргәләнүе, бөтен дөньяга үпкәләве булдымы икән бу, белмим. Гөлчәчәк аларны почтадан чыгуга мең кисәккә ертып җилгә очырса да, юшкыны барыбер кала шул, онытылмый.)

Ул чакта акыл белән көрәштә йөрәк җиңә: салкын гына булса да җавап хаты яза кыз. Аралар өзелми кала. Берсен-берсе әле табып, әле югалтып еллар уза. Кыз күңелендә өмет уты сүнде дигәндә, хатлары, «киләм» дигән сүзләре белән Әнгам учакка утын өсти дә, очкыннар кабат ялкын булып үрли... Аерылышканнарына җиде ел да 46 көн дигәндә, ул, чыннан да, һич көтмәгәндә-уйламаганда Гөлчәчәк Әдһәмова укыткан Мүлмә авылы мәктәбенә килеп керә. Бу юлы инде барысы да башкача булыр кебек тоела. Әмма барысы да өр-яңадан кабатлана. Ул: «Киләм», – дип китә һәм... тагын килми. Нигә? Сорауга җавап юк...

Күп еллар узгач, бер очрашканда ул Гөлчәчәк апага: «Бернсны яратканымны беләсең. Аның белән язмышым охшаш бугай. Син дә минем Клариндам...» – ди. Роберт Бернс – шотланд шагыйре. Без аны «Любовь и бедность» («Здравствуйте, я ваша тетя!» кинофильмы), «Моей душе покоя нет» («Служебный роман») кебек җырлары аша беләбез. Агнес Крэг исемле ханым белән Бернс озак вакытлар хат алыша, ул аңа һәрвакыт: «Кларинда», – дип дәшә. Аның белән рухланып, шагыйрьнең шактый шигырьләр иҗат иткәнлеге мәгълүм. Әйе, кайсы чорда яшәсә дә, шагыйрьгә рухландыручы кирәк. Кавышкан очракта, көнкүреш мәшәкатьләре, бала чүпрәкләре арасында рухны сүндерми саклау, ай-һай, мөмкин эшме?!

Аннан, киткән очракта, Уфада уллары кала – Азамат белән Салават. Тәгәрәп үсеп килүче малайларның әнисе – Сәвия... Гөлчәчәккә юллаган соңгы хатыннан соң ике-өч ел гына узар да, шагыйрь түбәндәге юлларны язар:

Ә мин сиңа җыр да язмаганмын,
Эзләгәнмен аны ерактан.
Күрмәгәнмен – ничә еллар буе
Үз янымда нинди җыр яткан!

Юк, Гөлчәчәк апа белән аларның язмышлары кушылмауга арада яткан еллар һәм юллар гына гаепле түгелдер, юктыр... Җаваплылыктан да китә алмау бардыр, язмыштан да узып булмагандыр. Гөлчәчәкнең барлыгын Сәвиясе гел белеп яши. (Шагыйрь хатынныры күтәргән йөкне теләсә кем иңнәренә сала алмый!) Төрле еллар, төрле вакытлар булгандыр. Гөлчәчәк апага иң соңгы шалтыратуында Әнгам ага: «Мин сиңа һәрвакыт хәлем хөрти чакта шалтыратам. Синең белән сөйләшкәч, ничектер җиңел булып китә. Бисә әйтә, синең эшең рәхәт, Гөлчәчәк белән сөйләшәсең дә кеше буласың, минем андый кешем юк», – ди».

Мин хәзер синең алдыңда эшләгән җинаятем өчен иң авыр җәза алырга – гомер буе газапланырга тиеш.

Тик бу язма: «Алар нигә бергә булмаган?» – дигән сорауга җавап эзләү түгел. «Бәхет», «Җиз кыңгырау моңнары» кебек үлемсез җырлар авторы, Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабайны, аның шигырьләрен кабат күңелдә яңарту бу. Аннан – бу икәүнең рухына бер дога. Бигрәк тә – шушы мәхәббәт аркасында гаиләсез дә, баласыз да калган Гөлчәчәк апа рухына. Әнгам Атнабайның «Аэропортта» (1972) дигән шигыренең шушы юлларына Гөлчәчәк апа Әдһәмованың бөтен язмышы сыйган кебек тоела миңа:

...Киләбез, көтәбез, китәбез...
Шул килү һәм китү – гомер бит!
Гомерне нәкъ шулай үтәбез:
Яшәүне яратып киләбез,
Яшәүдән ярату көтәбез,
Яратып туймыйча китәбез...

Ә хәзер, әйдәгез, хатлар, дөресрәге, алардан өзекләр укыйк.

«**22.07.49.** Гөлчәчәк! Син миннән хат көтәсең, ә мин синнән, чөнки мин беренче булып хат язган идем инде.

«Сагынам» дип әйтсәм ялгыш булыр, ләкин Казанда Казаныннан да, институтыннан да тыш, бер бик якын нәрсәм торып калган шикелле һәм аның белән бергә буласы килгән кебек.»

«**26 апрель, 50.** Аксәет. Гөлчәчәк! Гафу ит, минем ачыктан-ачык (откровенно) буласым килә һәм берниндi әдәби буяусыз, менә нәрсәләр беләсем килә (тик син дә миңа дөрес, чын йөрәктән җавап бирсәң иде):

1. Син мине яраттың. Ул яратуны кайтарырга мөмкин түгел, шулаймы?

2. Ә синеңчә ничек, дуслыктан ярату үсәме?

PRESSA.RU

3. Әгәр мин синең алда хәзер гафу үтенсәм, син мине гафу итмәс, биткә төкерер идең, дөресме?

4. Танышың кем? Мине дә таныштыра аласыңмы аның белән?

Бу сорауларга аптырама да, ачуланма да, көлмә дә, алар миндә кинәт кенә туган, очраклы сораулар түгел, ә озак эволюциядән соң революция!

Аксәет. Төн. Тышта яз. Әри елгасының шаулап агуы ишетелә. Алда унлы лампа яна. Өстәл өстендә китаплар крепосте. Мин сиңа хат язам һәм күз алдыма сине китерәм: акыллы һәм белергә тырышып карый торган зәңгәр күзләр, сизелер-сизелмәс кенә җыерылган кашлар, ихтыяр көчен тышка сиздереп торган иреннәр...»

Үләсемне белдем, ләкин синең белән аерылырбыз дип күз алдына да китерә алмадым.

«**31.07.50.** Гөлчәчәк! Мин синең соңгы хатыңны бүген укыдым, һәм ул хат барлык әгъзаларымны тетрәтте. Юк, юк, кирәкми, Гөлчәчәк, юк, кирәкми, урынсыз мине гаепләвең. Әгәр барысы да син язганча булса – минем соңгы өметем дә, тормышка булган соңгы ышанычым да өзелә, ахры, бөтенләйгә югала...

Мин 1 июльдә Кәрдәгуш авылында оештырылган пионерлар лагерена бардым. Лагерьда барлыгы 60 пионер ял итте. Мин өлкән пионервожатый булып эшләдем һәм балалар белән походларга, экскурсияләргә йөрдем. Бүген авылга ат белән китереп куйдылар. Өйгә кердем һәм әнигә беренче соравым шул булды:

– Хатлар бармы? Газеталарның һәммәсен дә җыйнап бардыгызмы?

Әни миңа хатлар китереп бирде, һәм мин алар арасыннан беренче булып синең хатны сайлап алдым. Күз алдыңа китер: ачык тәрәзә, кояш яктысы уйный, тышта моңсу гына тополь шаулый, авыл эштә. Терсәге белән тәрәз төбенә таянып, озын чәчле, юка гына мыеклы, кашлары җыерылган, аскы иренен тешләгән берәү хат укый. Ул кинәт кискен хәрәкәт белән урыныннан калкына һәм папирос кабызып, ачу белән тарта. Аннан соң китаплар стенасы белән уратылган өстәлгә утырып, ашыга-ашыга хат яза башлый...

Гөлчәчәк! Гаепне үзең сизеп гафу үтенү, минемчә, яхшы гадәт. Ләкин мин үз гаебемне белсәм дә, гафу үтенмим, чөнки үтенсәм дә, син бервакытта да мине гафу итмәссең. Ә шулай да бүген хисләремне сиңа язасым килә. Минем хәзер башка беркемем дә юк, бары тик син, һәм мин сиңа үземә ышанган кебек ышана идем. Минем теләгем шундый иде: син укып чыгасың, өйләнешәбез, мин укыйм, матур киләчәк... Ләкин хәзер бу теләк зур куркыныч астында, чөнки синең хат бөтенләй киресен сөйли, минем яратуга, сиңа булган карашка матәм маршы җырлый. Киләсе хатың нәрсә сөйләр? Сау бул. Үбеп: Әнгам.»

«**21 февраль, 51.** Күрдем. Гөлчәчәк! Син әйтмешли, горурлыгымны җимерәм һәм сиңа карата барлык карашларымны язам. Син мине үзеңнән суынган, алдаган һәм синең исемеңне йөрәктән алып ташлаган дип күз алдыңа китерәсең. Гөлчәчәк, уйла, үлчә акыл белән, кемем бар минем синең шикелле мине аңлый алган? Кемнең рәсеме минем күкрәк кесәсендәге блокнотта йөри? Синеке бит, Гөлчәчәк. Кем, мондагы бер укытучының кызы тугач, аңа Гөлчәчәк исеме куштырды? Мин дурак ич, Гөлчәчәк. Кем соң авыр вакытларда, Казанны сагынганда, шигырьләр язганда сүзләр табалмаса, сине уйлый һәм эше җиңеләеп китә? Мин бит ул, Гөлчәчәк!

Син Уфага бармаган, ягъни билгеләнмәгән очракта да безнең мәхәббәт дәвам итә ала. Мәхәббәт өчен нинди киртә бар соң? Минемчә, үлем генә аны өзәргә мөмкин. Син Уфага килә алмыйсың икән, мин җәйге каникуллар башлану белән сине күрәм бит әле, барысын да шунда сөйләшербез. Әгәр дә син һаман да элеккеге карашларыңда булсаң, иртә димәсәң, риза булсаң, минем белән бергә атларга теләсәң... берәр ЗАГС өстәле табарбыз әле. Казандамы, кайда.

Минем сиңа булган мәхәббәтем вакыт үтү белән сүрелмәде, ә ул, киресенчә, тирәнәйде, һәм мин синнән башка яхшы, лаеклы тормыш иптәше таба алмавыма инандым. Кемнәрне күрмәдем, кемнәр белән сөйләшмәдем, ләкин барысы да минем изге хисләремә сукыр булдылар, аңламадылар. Әдәбият! Бу турыда синнән башка кем сораша, кем үз күреп киңәш бирә? Беркем дә! Ә миңа хатын, бала анасы, казан янында маташучы гына кирәкми, ә тормыш иптәше, киңәшче, дус, булышчы кирәк!

Мин югалтсам сине,/ мин югалтам/ Яшьлегемнең матур бизәген,/ Гомеремнең дустын,/ бөек илһам / Бирүчесе – иҗат үзәген.»

«**9 март, 51.** Күрдем. Гөлчәчәк! Хатыңны кичә алдым, ләкин җавап яза алмадым, чөнки РОНОдан вәкилләр килделәр дә, мәктәптә кара төнгәчә утырдык. Ә бүген менә әле генә мәктәптән кайттым һәм түземсезлек белән сиңа хат язарга утырдым. Кичә төнлә кайтканда әни йокламаган иде, һәм ана белән ул озак кына сөйләшеп яттык. Бәлки кайберәүләр яшерен сер итеп сакларга яратадыр, ә мин сиңа булган мәхәббәтемне аңардан яшерергә теләмим. Ул барысын да диярлек белә һәм һәрвакыт синең сәламнәреңне кабул итә. Соңгы хатта язылганнарны да мин аңа сөйлим. «Минем янда тормасагыз да, җәйге каникулны монда үткәрерсез әле», – ди. Ана бит, ул гел генә үз янында тоту, якын-тирәдә икебезне бер җирдә эшләтү ягында, «укуың да җиткән инде», диясе дә килеп куя.

Син назначениене Башкириягә ал. Әгәр Уфа, Бирск ошамый икән, бездә татар урта мәктәпләре дә җитәрлек. Тирә-якны рәтләргә кирәк дип, борчылма, Гөлчәчәк. Әгәр кирәк икән, мин тагын бер ел укымыйча эшләргә дә риза; әниең турында да кайгырма, үзебезнең янга алырбыз. Мин барысына да риза, тик миңа синең белән бергә булу гына кирәк. Кешегә һава никадәрле кадерле булса, син дә минем өчен шулай.

Югалтырмын дип куркам мин сине. Синең минем янда булуың иҗатымда да зур роль уйнаячак. Шушы турыда тирәнтен чын кешеләрчә уйла әле, Гөлчәчәк!

Озын сүзнең кыскасы, әле без тормыш тарафыннан бозылмаган, яшьләр, характерлар килешә шикелле, әйдә канатсыз тормышны тәмамлап, гомернең калган өлешен бергә алга барыйк!

Уку тәмамлану белән мин Казанга барам, сине үзем белән алып кайтам, аннан калганын шунда сөйләшербез. Шулай бит, Гөлчәчәк? Кире какмассың дип уйлыйм. Укуыңда һәм тормышыңда зур уңышлар теләп: Әнгам.»

«**30 март, 51.** Күрдем. Гөлчәчәк! Имеш, «Синең «Казанга киләсе» һ. б. шикелле буш хыяллар белән баш ватасың килми». Минемчә, мондый каршы алуга бармасаң да ярый торгандыр?! (Ләкин бер ялгышуны икенче бер ялгышмау белән төзәтергә дә мөмкин иде.)»

«**8 май, 51**. Гөлчәчәк! Минем соңгы экзамен – 3 июньдә, ә отпуск кайчан бирерләр – белмим. Отпуск алу белән «лечу, лечу к тебе!» Искесе бетмәде, инде яңа уку елына да назначение башланды. Мине үзебезнең мәктәпкә ана теленнән һәм географиядән билгеләделәр.

Госэкзамен беткәч тә син кайтып китмисеңдер бит? Каршы алырсың дип ышанам. О, күз алдына китерәм, ул минутлар ничек булачак: куркыныч та, күңелле дә. Шунда күрербез инде: без аерылышу сынавын ничек үттек икән? Карашлар үзгәрмәгәнме, беренче очрашу нинди хис калдырыр, беренче елмаю чынмы, ялганмы, ясалмамы булыр һәм киләчәк ничек хәл ителер? Сораулар күп, ләкин барысына да Казан перронындагы очрашу җавап бирәчәк. Дөрес! Бу очрашу күңелле дә, куркыныч та. Белгәннәргә сәлам. Экзаменнарда уңышлар теләп һәм, рөхсәт итсәң, үбеп: Әнгам.»

«**10 январь, 52.** Уфа. Гөлчәчәк! Мин бүгенгә кадәр синең (Сезнең дип язарга теләмим) адресыңны белмәдем, шуңа күрә хат яза алмадым.

* * *

Шушы өч йолдызны куйгач, ничектер синнән гафу үтенәсе килгән иде, ләкин нигә? Юк, Гөлчәчәк, гафу үтенүнең кирәге дә шуның кадәр генә булса кирәк!

Синең янга бармадым һәм юлга дип хәзерләгән акчаны (әйдә, дөресен әйтеп сөйләшәбез!) ресторанннарда бетердем, янәсе, егет кайгыдан эчә, сөйгәне аның теләгенә риза булмаган! Экзаменнар беткәч, Уфага бардым. Матросов исемендәге кинотеатрның фойесында, мич артында, карарга дип кергән киномны карарга да онытып, менә бу – сиңа җибәргән поэманы яздым һәм шул килеш дип әйтерлек машинкада яздырып сиңа җибәрәм – тәнкыйтьлә.

Уку башланганчы тагын Уфага барырга булдым. Киттем. Юлда (случайно) Бирскига тукталдым... һәм калдым. Берничә сәгать эчендә бөтен дөньяга төкереп карадым һәм тагын бер ялгыш адым: өйләндем.

Уфага килдем һәм «Кызыл таң» газетасына литсотрудник булып эшкә кердем. Хәзер шунда эшлим. Шигырьләр бастырам. Төрле кичәләрдә булам, студентлар белән очрашам. Укыйм. Язам. Иртәнге сәгать 9 да китәм, төнге сәгать 3 тә, 4 тә кайтам...

Кайбер очракларда минем үчкә-үч (назло) эшли торган гадәтне син беләсең. Әле күптән түгел шундый вакыйга булды. Төнлә кайттым. Бераз язып утырдым. Яттым. Йоклыйм. Иртән уянып киттем, күзне ярым ачып кына карыйм: Сәвия кесәдәге блокнотны актара. Синең фотоны алып карап торды-торды да, яңадан салып куйды. Мин «күрмәдем». Тордым, ул сорый:

– Блокнотыңда кемнең фотосы бар?
– Гөлчәчәкнең.
– Нигә?
– Ә анысы белән кызыксынма.
– Бәлки син аңа хат та язасыңдыр?
– Анысы хәзергә юк.
– Алдыйсың?

Ләкин син шуның өчен генә хат язган дип уйлама, бу бары тик бик кечкенә, диңгездәге тамчы шикелле генә сәбәп.»

Кешегә һава никадәрле кадерле булса, син дә минем өчен шулай.

«**13 гыйнвар, 1952.** Якшәмбе. Әйе, әйе, мин сиңа әдәбиятны аңлаганга күрә, һәм кеше буларак тормышың белән кызыксынып язам. Мин бит синең нинди авылга, нинди коллективка эләгүең турында да, ничек укыта башлавың турында да белмим. Бәлки инде син минем исемне дә оныткансыңдыр, ә мин, дурак, шундый ышаныч белән хат язган булам. Бәлки инде...»

«**26.04.52.** Уфа. Барсы төгәл, / мәңге кебек иде, / Юкка чыкты кинәт барсы да; / Шуңа йөрәк / ярсып-ярсып тибә, / Уфа урамнарын тарсына. / Мин берүзем, / ләкин йөрәгемдә / Аерылуның миллион газабы, / Гомергәме шулай дәвам итәр, / Бер булырмы әллә азагы?!


Бүген баткан кояшның иртәгә чыгачагы турында уйламасаң, димәк, киләчәккә өметең өзелгән дигән сүз. Тормышта шуңардан да начары булырга мөмкинме?!

Сәвия дә хәзер бергә торырга мөмкин түгеллеген аңлый булса кирәк. Тик ул бер яклы гына аңлый, мин әйткән нәрсәләрне беренче аргумент итеп алмый, ә «сине котырталар, шуның өчен миннән безден...»

Мин өйләнү белән үземнең мәхәббәтемне югалтмадым, ә аның никадәр көчле булуын һәм моңа кадәр тиешенчә бәяләп бетермәвемне, аңардан һичничек тә котылырга мөмкин булмавын аңладым. Гөлчәчәк! Минем хәлләр сине кызыксындырмас инде, дисең. Дөрес түгел! Әгәр бүгенге Әнгамгә язарга теләмисең икән, кичәге Әнгамгә яз. Бүгенгесенә караганда кичәгесе көчлерәк аның. Бүгенгесе – бары тик тере мәет кенә. Гөлчәчәк! Кем ул «ул»? Хәер, әйтмәсәң дә ярый, чөнки барыбер бәхетле ул «ул»...»

(Дәвамы киләсе санда.)

PRESSA.RU



Татарстан кинематографы дөньясында яңа исемнәр елдан-ел күбрәк күренә. Сары күзлекле яшь режиссер Илшат Рәхимбайны да күпләр белә булыр. Аның эшләре белән танышкач, егет Татарстан киносы кысаларына гына сыймый, дигән фикер туа. Фильмнарында бөтен дөньяны борчый торган мәсьәләләр хакында сүз кузгата бит. Диплом эше итеп төшергән «Гастарбайтер» картинасы Казан халыкара мөселман кинофестивалендә күрсәтелде, хәзер дә 15 илдә төрле бәйгеләрдә катнашуын дәвам итә. Илшат Рәхимбай клиплар төшерүче буларак та танылган. Аның «Син кирәк» дип аталган эше – «Клюф-2011» фестивалендә «Иң яхшы музыкаль яки шигъри фильм» номинациясендә, ә «Хәзер яз» дип аталган тасвирнамәсе «Иң яхшы сценарий» номинациясендә премиягә лаек булды. «Кайда» клибы Бөтенроссия «Селигер фильмы-2011» кинофестивалендә «Иң яхшы оператор», ә һәвәскәрләрнең Казан кинофестивалендә «Иң яхшы клип» номинациясендә җиңү яулады. «Harmony» клибы халыкара «Алтын бишлек» кинофестивалендә иң яхшысы булып танылды.



ИЛШАТ РӘХИМБАЙ




ТОРМЫШ ЮЛЫ

1988 елда Балтачта туган. Мәктәпне тәмамлагач, ТДГПУның музыкаль уен кораллары бүлегенә укырга керә. Тик анда өч ел укыгач, бу юлның үзе өчен бик тар булуын аңлап ала. Кинорежиссер һөнәре, чиксез мөмкинлекләр вәгъдә итеп, кызыктырып тора аны. Шулай итеп, язмыш юлы Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетына китерә. Хәзерге вакытта ул «Күз алдына китер» дигән кыска метражлы нәфис фильм төшерү белән мәшгуль. Ул иҗаты турында яратып сөйләсә, иҗаты исә аның үзе хакында сөйли, аның дөньяны күзаллавын ача. Үзен тәннең тар һәм көчсез кысаларына бикләнгән җан итеп кабул иткән иҗатчының инструменты ул. Шундый бәхетле мәхәббәт кенә чын сәнгать тудыра ала.



«КҮЗ АЛДЫНА КИТЕР»

VII Казан халыкара мөселман кинофестиваленә хәзрәт, гадәттәгечә, православ рухание белән түгел, үзе генә килә. Ул кап-карадан киенгән, тар ак якасы гына күренеп тора. Аны күргәч, Илшатның башында мулла-рухани образы гәүдәләнә. Нәкъ менә шул вакытта режиссерның күңелендә фильм төшерү идеясе дә бөреләнә, тора-бара ул җитди кино буларак үсеп җитә.



НӘРСӘ ТУРЫНДА?

Фильмдагы вакыйгалар ике авылда – татар һәм рус авылларында бара. Шунысы кызык: татар авылындагы вакыйгаларны – татарча, рус авылындагыларын русча төшергәннәр. Рухани атакай – поп кисәк кенә вафат булганнан соң, ике авылга бер дин әһеле – мулла кала. Мулла тәмам аптыраган: үз диненә генә хезмәт итәргәме, әллә күрше рус авылы халкына да ярдәм итәргәме? Алай итсә, авылдашлары нәрсә дияр? Мулла белән попны дин генә түгел, туганлык җепләре дә бәйләп торган икән бит. Шулай булгач, әлеге фильм дин турында гынамы соң?



ТАМАШАЧЫ БЕЛӘН ДИАЛОГ

Режиссер әйтүенчә, ике авыл, ике дин күпкә зуррак проблемаларны күрсәтү өчен фон гына. Бүгенге җәмгыятьтә глобаль проблемалар болай да җитәрлек бит: дөнья бутала, кешеләр бер-берсен аңламый, бер дәүләт икенчесе белән сугыша. Ни өчен болай соң бу? Нәрсәгә без яшәр өчен бирелгән вакытны нәфрәт һәм җәнҗалга сарыф итәбез? Без кем? Бу дөньяга ни өчен килгәнбез? Безне бу җиргә кем җибәргән? Яшәүнең мәгънәсе нидә? Бу сораулар һәрберебезнең күңелендә бар, тик аларны бик сирәк кузгатабыз. «Күз алдына китер» фильмы шушы сорауларны игътибар үзәгенә куеп, тамашачыны уйланырга мәҗбүр итә.



ИШАРӘЛӘР

Илшат Рәхимбай әйтүенчә, фильмны төшерү барышында зур проблемалар тумаган. Ә менә ишарәтләр бөтен җирдә булган. КҮЗ АЛДЫНА КИТЕРЕГЕЗ: төп геройларны уйнаучы актерлар Раушан Шәриф белән Марсель Тимофеев беренче очрашуга бертөрле киемнән килгәннәр. Алдан сөйләшмичә! Төшерү өчен ике кечкенә малай кирәк булгач, Раушан белән Марсель икесе ике малай табып алып килгән, ә алар абыйлы-энеле булып чыккан. Режиссер бу ишарәтләрне: «Димәк, мин дөрес юлдан барам», – дип аңлаган.



ФИЛЬМНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ

«Күз алдына китер»нең сценарие Россия күләмендәге берничә дәрәҗәле конкурсның шорт-листына эләккән. Танылган продюсер Александр Шульгин фильмның сопродюсеры булырга ризалашкан. Ул фильмны халыкара Канн кинофестивале кысаларында тәкъдим итәргә ниятли.

Фильм төшерелеп беткән, монтажлыйсы гына калган. Тик монысы иң катлаулы эш – финанс ягын да карарга кирәк. Шуңа күрә хәзер теләктәш кешеләрдән матди ярдәм җыю бара. Максат – чит илгә дә алып чыгарга мөмкин булган сыйфатлы фильм ясау.

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

Күптән түгел Италиядән кайтты. Ул хәзер Белла Әхмәдуллина исемендәге Россия — Италия әдәби премиясе лауреаты!
Аның шигырьләре – үзе бер дөнья! «Мин — асфальт баласы!», «Шигырь ул — төнәтмә. Ниндидер тойгылар, мизгелләр...» — дигән сүзләре инде күптән афоризмга әйләнде. «Эчке халәтең тышкы дөнья белән бер ешлыкта тибрәнергә һәм... кисәк сикереш ясарга тиеш. Шул мизгелдә шигырь туа... Галәм белән бергә бер каласың», – дип аңлата шагыйрә үзе. Һәр юлына тирән фәлсәфә салынган шигырьләрен исә һәркем үзенчә аңлый, үзенчә кабул итә.
Мең кояшы белән / күтәрелә / офык боҗрасы... яки: Төнгә пәрдәләнгән / кыршау-кала... менә тагын: фонарь белән кояш — / Сак белән Сок...
Аны беркем белән бутау мөмкин түгел. Ул, әлбәттә, Йолдыз Миңнуллина. Яшьлек, романтика, рок, гитара... Монысы да — Йолдыз.

Йолдыз
МИҢНУЛЛИНА

МИН СИНЕ КИЧЕРДЕМ

Биләр

Сөләйманга

Таң алды. Без алган аланның
ярлары шәмәхә-шәмәхә...
Дым тарткан җилләргә ялганып,
атамча кайгыртып эндәшә
тавышың: «Борылып кара да,
бу җирнең үткәнен чамала...»
Җидегә теленеп тамалар
кыяклы үләндә яралган
тамчылар. Бу җиргә вакыт та
вәхшиләрчә бага, күрәсең –
кыздыра, кояштан талкыта
хәтернең азаккы төрбәсен.
Мондагы кояшның кызуы
тагын бер галәмгә җитәрлек,
бу минем чикләрне бозуым –
тәкърлек, мәҗүси тәкърлек,
бу минем дүртенче күчәрдән
ычкынган халәтем, тарттырып
элпәсен чорларның, күчәргә
кыюым. Ак күлмәк аркылы
кагыла аркага салкыны
әле ут күрмәгән ташларның,
бу бөек каланың калкынып
килүе, яңа көн башлавы.
Бу әле ат менәр кызларның
тын гына чишмәгә йөрүе,
кояшның кич саен кызарып,
чүлмәкче миченда эрүе.
Бу минем тамгачы кулыннан
тамуым, нигезне тамгалап,
эндәшсәң дип бер көн: «Борыл да,
бу җирнең үткәнен чамала...»

* * *

әйдә, качыйк? әле ачык
бар ишекләр,
ишекләрдән кар ишелә, кар ишелә,
машиналар туктап тора,
очрап тора
чакрым саен дус ишеләр,
яр ишеләр.
юллар чиксез: сайла диңгезләрнең
берсен,
өлгермәгән йөзем кебек
бөрештерсен
иреннәрне иртәләгән «яратам»нар,
яңа таңнар җуя торсын алсу төсен.
әйдә, кабат яулап кайтыйк
ак тауларны –
ияләрме анда, камнар,
сак-бауларны –
берләштерсен безне,
көчне тигезләсен
үр алганда. син беләсең, үзбәясе –
җаннан ары – ә шулай да,
кылганнарның
тын алганын тыңлар өчен
җиргә ятып.
әйдә, качыйк. бездән гарык
берләнберләр
кичергәнче ул безләрне
берәр вакыт.

* * *

Мин сине кичердем. Тулаем.
Бөтенләй.
Дәвасы юк чирдәй кичердем.
Һәм төнлә,
Иң соңгы бизгәктә – исемдә,
борчылма –
Бизәкле җөйләрен калдырып
учымда,
Ул зәхмәт чигенде.
Күрешкән вакытта
Кулларны кесәдән чыгару ялкыта
Хәзергә. Һәм шулай
дөресрәктер сыман:
Хәтерлә, ул да бит кочарга җансыган
Һәр адәм баласын,
тик гауга кубарып,
Кадаклап куйганнар
җәелгән кулларын.

Ә безнең заманга ни кала
үткәннән? –
Мондагы диварлар
һәр сүзне үткәрә.
Һәм тула ялгызак куышың эченә
(Син дә шул көч белән
булышсын өченгә)
Битараф сулышым –
тәрәзә ачканда,
Лаләләр юлласам, елыша таҗларга
Кулларым салкыны.
Мин йөрим үтәли
Төшләрең аркылы. Буылып ютәлли
Ул кемнең шәүләсе?
Кичердем ләбаса...
Дәвасы юк чирдәй килә дә төн баса.

* * *

эңгер. инде тын алу да,
эндәшмәү кебек, җиңел.
бу сүзсезлек – югалудан,
һич тә үпкәдән түгел.
ябалак карлар очына,
күңел иңкүлегенә
(күрешкәндә, бит очыңнан
үпкән шикелле генә)
кагылалар. инде алар
син теләгән кимәлдә –
тынды дуамал бураннар.
үз-үзеннән имәнгән
бөтен гавам. тыштанмы соң –
өйгә көйгән ис керә.
син сүзләргә ышанмыйсың,
ышаныч җитенкерәп
бетми күз карашына да.
шуңа хатларым – артык,
яраксыз, һәм без шуңа да
аларны тотып яктык
бу эңгердә. тын алуы,
дәшмәү кебек, читен.
суламасаң – әкрен яна,
януымны киметтем.

* * *

кышкы төшләр авырая бара
язга таба –
мышнап эштән кайткан
ир хатынымыни,
тәрәзәгә каплана да, кабат-кабат
үз барлыгын, үз берлеген
исбатларга тели.
тоныклана бара күз карашы, кибә
шул төшләрдән. читлектәге
киек түгел
йөрәгең дә. Санап тибә, сынап тибә
тәртәсенә, сынмасмы дип бүген...
ә офыкта бии пәри шәүләләре,
җиргә койрык бәреп, боз яра,
мәчетләргә, чиркәүләргә бәреп,
чаң сугышлы уйный үзара.
иртәләр дә инде бераз
башка төрле –
тар пәрдә читенә оялап,
айныган очраклы
төндәшләр шикелле,
ялангач сыныннан ояла.
пышылдап эндәшә
кемнеңдер тавышы,
эндәшә әлегә буш шәһәр аркылы:
бу дөнья бер көнгә
мең төргә авышыр,
ышанма, акыллым!

* * *

әйлән, әйлән, бәлки, вакыт туктар,
һәм бу төнне ул да кадерләр. тик
бер йотымнан йөнтәсләнә утлар,
ван гог йолдызларын хәтерләтеп.
онытыла күпләр. бие, бие,
сүзләр ыргыт күпер бөкресеннән,
урам тулы яраланган киек –
янәшәңә килеп үкерсеннәр.
син алардан узып тузын, тузын,
яңагыңны җилләр сыдырсын;
иртән, бәлки, тынычлыгың бозып,
тамагыңда нидер кыбырсыр.
тик шул гына. тагын авыз ерган
итегеңне сөйрәп җилдер, җилдер.
салкыннан да дертләп кабынырга
без өйрәндек инде.

* * *

Иреккә

инде ныклы бер карарга килеп,
таш илләрне, шәһәрләрне кичте,
яңгырлардан узып,
кануннарны бозып,
кар иште дә иште.
елларыңның кайтавазы булып,
җырларыңның кайтавазы булып,
иште, иште, иште,
җиргә төште,
шул арада өши язганнарны
эреп юатырга җитеште,
күргәннәргә күрәзәләр ачты –
ерак калаларны күрсәтте,
син шул якка чабасыңдыр сыман,
көтеп бетермичә рөхсәтен
монда калганнарның, элеккечә,
тәрәзәдән качып чыккансың,
элеккечә кайтмый көтәсеңдер:
башта үләннәрдән чык тамсын,
ә ул таммый, һәм син шуңа гына
кире борылырга кыймыйсың,
мондагылар хат алыша һаман:
«ничек инде алай?
чынмы соң?»
ничек инде алай карлар ишә ала,
ничек көртли хәтер түремне?
күздәгечә ишә.
син югалган
ялган кала гына
күренми.

* * *

башта гел-гел кояш иде,
аннан кинәт эңгер иңде,
шәһәрдә төн, табигый ки,
син йоклыйсыңдыр инде.
син йоклыйсың, төшләреңә
карак кебек шымып киләм,
миндә сүзләр ике күләм,
миндә хисләр ике күләм.
мин аларны, табигый ки,
икебезгә тигез бүләм.
бер сөюлек хисең булсын,
миңа артык, ал, тарсынма,
кышлар озын – җылы тулсын
туң көннәрең арасына.
ә иртәгә син үзең дә
карый алмассың туры.
берәрсенә. шәһәреңдә
гел-гел кояш булып торыр.

* * *

эрегән шәһәргә яңадан туң бәреп,
фонарьлар кабынган чагында,
кытыршы кулларым
бу кичтән элгәре
кагылган сызыклар
тынлыгын сагына.
һәм йөзә кыйшайган
түбәләр өстеннән
әллә ай, әллә ят галәмнәр корабы,
аннан күк йөзенә битараф төс иңә.
син, шуңамы,
тагын ятсынып карадың.
мин, шуңамы,
бүген балконым тарлыгын
сулап булмас
куе төтенгә тутырдым.
галәмнәр сугышын
кешелек иң элек
бу кичтә үзенә оттырды.

Автор пунктуациясе саклана

PRESSA.RU

Исеме – Халисә, Ширмән – кыз чактагы фамилиясенең кыскартылган шәкеле. Лениногорск районы Зәй-Каратай авылында шактый зур, тармаклы Ширмән карт нәселе дәвамчысы булып дөньяга аваз салган ул. Иҗаты – аның күңел таләбе. Язучы, киносценарийлар авторы, галим-педагог. Казан федераль университетының татар теле тарихы һәм төрки тел белеме кафедрасында доцент. Ул гел студентлар, яшьләр арасында. Укучыларыбыз яратып кабул иткән «Язмышлардан узмышлар юк», «Яланаяклы кыз», «Кайтаваз», «Ерактагы йолдызым», «Бәхетлеме син?» телевизион фильмнар аның әсәрләре буенча төшерелгән. Бүген Халисә Ширмән «Сөембикә» укучыларына үзенең яңа хикәясен тәкъдим итә.


Халисә ШИРМӘН

ИРЕК

(Хикәя)

Мин ирекле! Ниһаять, мин – ирекле! И-рек-ле-е-е!!!

...Күз алдымда ачылган кичке гаҗәеп гүзәл манзарага сокланудан тыным кысыла, күңелемне үрле-кырлы сикерткән шатлык хисе, күкрәк читлегенә сыеша алмыйча, аһылдау булып, дөньяга аваз сала. Ә дөнья шулкадәр матур! Казансу ярында йөрүчеләр миңа сәерсенеп карыйлар.

– Эһе-һе-һә-ә-әй! Ишетәсезме-е-е?! Мин ире-ек-ле-е-еү-ү!

Ничек көтеп алдым мин бу көнне! Ходайга күпме ялвардым! Ничә төннәр теләк теләдем! Һәм, ниһаять, мин – ирекле... Әлеге хистән, шайтаннар кытыклап торган кебек, бөтен барлыгым белән чытлыкланып, рәхәтләнеп көләм, кулларымны югарыга сузып, әйләнә-әйләнә бер урында сикергәлим.

Башсыз да көлә. Исеме Айдар аның, тик минем өчен ул – «Башсыз», чөнки аннан теләсә нинди башбаштаклык көтәргә була. Авантюрист. Минем кебек. Әллә шулай бер-беребезгә охшаганга, әллә кечкенәдән үк каникулларны бергә үткәргәнгә, мин аңа тартылам. Ул – миңа.

– Күрдеңме инде?! – ди ул. – Ә син курыккан буласың...

Курыкмыйм! Бары тик әти-әнине генә кызгандым. Кая киткәнне дә әйтмәдем бит аларга...

– Ничаоуау, Айс. Бераз кадереңне белерләр.

Башсызның менә шушы «ничаоуа»сын яратмыйм. Әйткәндә дә ул аны кешечә итеп түгел, ә иреннәрен җәеп, «а» авазы музыка укытучысыныкы кебек «о»га кадәр түгәрәкләп, аннан инглиз теле укытучысының «уау»ына яңадан җыелып беткәнче сузып әйтә. Шуның белән ул серлелеген югалта. Нәрсә, әллә мин авыл малайларын күрмәгәнме?!

– Әйтмә әле шул сүзеңне.

– Синнән сорап тормам.

Ә аның менә бу ягы миңа ошый. Ул каршы әйтә белә. Ә мин белмим. Шуңа күрә мин ирекнең дә нәрсә икәнен бүген генә аңладым. Мин инде «абитур» гына түгел, мин – студент! Артта – БДИ, артта – әнинең бертуктаусыз мыжгуы, әтинең шелтәсе, абыйның теңкәгә тиюләре... Мәктәп укытучыларының ачудан кыйшайган йөзләре, тилемсә дуслар-сыйныфташлар... Барысы да артта. Ә алда – ирекле тормыш, яңа дуслар, мәгърур шәһәр! Үземә үзем хуҗа!

– Әйдә, утыр, – ди Башсыз. – Әле мин сиңа шәһәр үзеген күрсәтмәдем.

...Казансу елгасы яры артта кала. Без тагы очабыз... Нәкъ шулай – очабыз. Башсызның мотоциклында. Әтисе бүләк иткән. Башсыз әйтүе буенча, алар әтисе белән яшәмиләр, әмма ул аңа акчасын да, бүләген дә кызганмый. Әнисе исә үзенә яңа ир эзли, шуңа еш кына Башсыз өйдә

ялгызы куна. Аның болай дип әйтүе бер дә ошамый миңа, ничектер, әни турында сөйләгәндә хөрмәте юк сыман... Тик бу минем эшем түгел.

– Кара! – дип, артка борылып кычкыра Башсыз. – Хәзер бер күпердән икенчесенә очабыз! Аннан өченчесенә! Казан – күперләр шәһәре!

Ленин дамбасы артта кала, әмма Башсыз шәһәр уртасына борылмый, Киров күпере ягына таба җилдерә. Миңа кызык: тирә-якта җемелдәп утлар сызыла, зур тизлектә барганга, мин аларның нинди утлар икәнен дә аңышмыйча калам; шлем астыннан кереп, колакларда җил сызгыра, мотор тавышы аңны кисә. Ара-тирә Башсыз нидер әйтә, бер кулын рульдән ычкындырып, нәрсәдер күрсәтә. Мин инде аны ишетмим. Башсызның кара күннән тимерчәләр куеп эшләнгән курткасына ябышып бетеп барам, мотоцикл утыргычыннан төшеп калмасам иде дип котым оча. Башсыз бәйләгән бандананың очлары җилдә җилфердәп, битемне кытыклый. Кайчакта Башсыз светофорның кызыл утына да карамый, бетмәс-төкәнмәс урам кисешләрен, кара бөркет һаваны ярган кебек, кисеп уза. Куркыныч та, рәхәт тә. Казан егете шул ул Башсыз. Минем кебек куркак авыл кызые түгел...

Миллениум күпере. Әйтерсең Ай юлыннан очабыз. Тик кинәт кенә нәрсәдер булды, һич көтмәгәндә Башсыз тормозны кысты, тәгәрмәчләр астыннан ут көлтәсе чәчрәде. Мин инерция буенча Башсызга чәпәлдем, ул рульгә килеп сыланды һәм баш аркылы мәтәлчек атарга җыенган кеше халәтендә катып калды. Мотоциклыбыз нәрсәләрнедер кырып-сыдырып, очкыннар чәчрәтеп кисәк туктады. Капланмадык. Шөкер. Күзгә төшкән шлемны күтәреп карагач, исем китте: әби әйтмешли, ничек безне Ходай саклаган! Юлда бәрелешкән ике машина арасына кереп кысылганбыз. Башка машиналар боларны урап уза, Башсыз, күрәсең, тизлеге зур булганга, урап узарга өлгермәгән. Шунда ук безнең янга ачыгавызлар йөгереп килде, нәрсәдер сөйләнә-сөйләнә, мотоциклдан төшәргә ярдәм иттеләр. Башсыз янына авария урынына чакырылган полиция хезмәткәрләре килеп басты. Минем кинәт кенә аяк буыннарым хәлсезләнде, җиргә чүгәләдем. Шунда гына джинсы чалбарымның тез башлары умырылып, канга буялганын сиздем. Котым очты. Аңыма авырту барып җитте. Чарасызлыктан Башсызга борылам. Шул вакыт тагы көтелмәгән хәл булды. Башсыз бер дә юктан полиция хезмәткәрләренең икесен ике якка селтәп җибәрде һәм күпернең икенче башына таба чабып китте. Белмим, нинди көчләр минем белән идарә иткәндер: инстинктив рәвештә сикереп тордым да аның артыннан ыргылдым. Тик мин дә, Башсыз да ерак китә алмадык, шунда ук безне куып тоттылар һәм ГИБДД машинасына кертеп утырттылар, җитмәсә, кулларга богау салдылар. Болар барысы да төштә булган кебек тоелды.

– Нигә качтың? – дим Башсызга, шыңшып.

Башсыз миңа җавап бирми. Ә мин аны танымыйм. Ярты сәгать элек кенә Казансу буенда сөйләшкән Башсыз түгел лә бу! Авыз читенә күбек җыелган, селәгәе ага. Күз карасы киңәйгән, үтә күренмәле ниндидер пәрдә белән капланган. Йә Ходай, шулкадәр курыкты микәнни?!

...Безнең кем булуыбызны ачыкладылар, шаһитлар чакырып, беркетмә тутырдылар, мотоциклны штраф тукталышына алып киттеләр. Исерткеч эчемлекләр һәм наркотиклар куллануны ачыклау процедурасыннан Башсыз баш тартты, ә мин ризалаштым. Тикшерсеннәр, исерек түгел лә мин. Аннан безне полиция участогына алып килделәр, тентеп, әйберләрне алдылар, бармак битендәге сырларны төшерделәр һәм административ тоткарланучылар камерасына икебезне ике якка аерым ябып куйдылар.

Шунда гына минем күңелемне чиксез курку биләп алды. Минем беркайчан да полиция кулына эләккәнем юк! Нишләргә инде? Мине нишләтерләр? Югыйсә бернинди начарлык эшләмәдем. Башсыз мотоциклына утырып йөрү начарлык түгелдер бит?! Әти-әнигә хәбәр итәсе иде. Ничек? Тентегәндә телефонымны алдылар...

Камерада миннән башка тагы өч хатын-кыз бар. Берсе сәкедә гырылдап йоклап ята, мине алып кергәндә дә уянмады. Берсе мәрткә киткәндәй утыра. Өченчесе миңа текәлгән. Тукта, минем бер тапкыр шалтырату хокукым булырга тиеш. Киноларда шулай күрсәтәләр.

– Телефоннан шалтыратырга рөхсәт итәләрме монда?

Миңа текәлгәне мыскыллы елмайды.

– Әйе, итәләр. Башыңа кәкәй итәләр.

Бу сүзләрдән бөрешеп, калтыранып куйдым. Дөнья шулкадәр тар, ямьсез, куркыныч булып калды...

...Бераздан мине полиция майоры янына алып керделәр. Мин аның майор икәнен башкалар дәшүеннән аңладым. Мондый кешеләр белән сөйләшкәнем юк әле минем.

Майорның талканы коры булып чыкты.

– Йә, кызый, сөйлә, – диде ул. – Аңлатма язуы язабыз.

– Нәрсә сөйлим?

– Нух пәйгамбәр көймәсеннән башлама. Конкрет: нәрсә, кайда, кайчан. Ишеткәнең бармы шундый уенны?

– Бар.

– Сөйлә.

– Миллениум күпереннән барганда, юлда бәрелешкән машиналарга без дә килеп бәрелдек. Минем тезләрем сыдырылды.

– Нәрсә кулландыгыз?

– ...Нинди мәгънәдә сорыйсыз?

– Наркотикның кайсы төрен кулландыгыз?

– Наркотик кулланганым юк минем.

– Ә юлдашың?

– Юк... Аның кулланганын да белмим.

– Ялганлыйсың! Кесәсендә колёсиклар да, ЛСД да табылды.

Минем күзләрем шар ачылды һәм тыным кысылды. Болар турында ишеткәнем бар, тик... Башсызмы? Наркотик кулланганмы? Кайчан?

– Кайчан? – Сорауның авызымнан очып чыкканын да сизми калдым.

PRESSA.RU

– Менә мин синнән сорыйм да инде: нәрсә, кайда, кайчан? Тагы бер сорау: кемнән алдыгыз?

– Юк, майор абый, минем беркайчан да наркотик кулланганым юк... Әле шампанскийны да кичә беренче тапкыр авыз итеп карадым... Унсигез яшь тулган көнне.

– Ышанам. Син чиста. Ә юлдашың инде ике ел учетта тора. Белә идеңме?

...Ике ел?!

– Ничек инде? Юк, булмас... Ышанмыйм.

Күз алдыма Башсыз килеп басты. Гитаралы кичләр, аркылыга-буйга бергә иңләгән урман-елгалар... Ничек инде наркоман булсын, ди, ул? Сәерлеге бар, тик нормаль кеше ул! Ел саен җәй көне безнең авылга кайта, сөйләшә, аралаша...

– Юк, юк, абый, сез аны кемдер белән бутыйсыз! Нормаль кеше бит ул, кыяфәте дә нормаль!

Майор абый мыскыллы көлемсерәде.

– Ә наркоман нинди була соң алайса? Яшел-шәмәхә төстәме?

Эндәшмәдем. Ничек инде, әллә наркоманны танымыйммы мин... Әнә, көн саен телевизордан күрсәтәләр: беләкләре зәңгәрләнеп беткән, чырадай нәзек, чәч-башлары тузган, күзләре калайланып акайган, үзләре пычрак була нариклар... Ә Башсыз... Юк, ул андый түгел!

– Наркоманнар синең белән минем кебек кешеләр алар, сеңел. Мәктәптә өйрәтмәделәрме әллә?

Мәктәп.... Искә төшермәсәң иде, майор абый! Яңа гына котылдым әле мин аннан...

– Ярар, яз аңлатма язуыңны. Кайда, кайчан таныштыгыз, ничек бу хәлгә төштегез. Яз. Мә, кәгазь, ручка.

Мин яздым.

«Мин, Гарипова Айсылу Марс кызы, Яшел Үзән районының Каен авылында туып-үстем һәм шунда яшим, туган көнем – 1997 елның 4 августы, Сабиров Айдар Нәгыйм улы белән кечкенә чактан ук таныш. Ул безнең авылга җәйге һәм кышкы каникулларга кайта иде. Аның начар гадәтләрен белмим, ул әйбәт малай. Миннән ике яшькә олы. Бүген, ягъни 2015 елның 5 августы көнне, минем туган көнне билгеләп үтү өчен аның мотоциклында Казан шәһәренә килдек һәм шәһәр буйлап йөргәндә, авариягә очрадык. Безне полиция хезмәткәрләре тоткарлады. Наркотиклар, исерткеч эчемлекләр кулланмадым һәм Айдарның да кулланганын күрмәдем.

Үз кулым белән яздым. Миңа басым булмады.

5 август, 2015 ел. Имза».

Майор абый мин язган кәгазьне укып чыкты.

– Аңлатманы ничек язарга икәнен каян беләсең? Язганың булдымы?

Бу сораудан үзем дә аптырап киттем.

– Юк... Беләм инде. Отличница бит мин. Мәктәпне алтын медальгә тәмамладым.

Майор кычкырып көлде.

– Отличница... Отличницалар алар, үскәнем, наркоманнар белән бәйләнми. Отличницалар алар әйбәт кызлар-малайлар.

Менә, миңа да мөһер сугылды. Дәшмәдем.

Майор кулындагы кәгазьне имзалады да өстәлдәге папкалар арасына тыгып куйды.

– Ярар, отличница. Бар, өеңә кайт.

– Ә Айдар?

– Ә Айдарың монда кала. Көндез суд булачак. Гадәттә, ун-унбиш көнгә административ җәза бирелә, наркотикларга бәйлелектән дәвалану билгеләнә. Ике елга мотоцикл йөртү таныклыгыннан мәхрүм итәләр. Әгәр тагы тотылса, җинаять җәзасы биреләчәк. Ишет һәм башкаларга сөйлә! Наркотик – уен түгел!


– Беләм...

– Беләсең... Үзең наркоманны да аера алмыйсың! Бар! Син иректә.

...Таң атып килә икән инде. Салкын. Калтыравымны басарга тырышып, Япеев урамыннан аякларым тарткан якка атладым. Башымда бер фикер, бер уй юк, тиле кеше кебек барам да барам. Менә берзаман тауга күтәрелеп, Муса Җәлил һәйкәле янына килеп чыктым һәм эскәмиягә барып утырдым. Аста мин белмәгән шәһәр җәйрәп ята. Янымда – шагыйрь. Бөтен ярсуын богаулы кул-аякларына салып, Җәлил иреккә омтыла. Кайдадыр кирмән эчендә Сөембикә манарасы күккә ашкан... Колшәриф горур тынлыкта сакчы булып баскан. Бөтен барлыгы белән Казан кирмәне ирек даулый.

...Ирек. Татлы син! Кеше иректә булырга тиеш. Ә мин әти-әниемне сагындым. Өзелеп сагындым. Теңкәмә тигән абыемны... Иске дусларымны. Хәтта мәктәбемне, андагы укытучыларымны да сагындым... Ничек яшәрмен мин бу шәһәрдә?!

Дөнья шулкадәр зур... Ә мин шундый кечкенә.



Рәсем: Наталья Васильева

КҮКЛӘР КҮКРӘТЕП КИЛГӘН БОЛЫТНЫҢ, ФАЙДАСЫННАН БИТӘР, ЗЫЯНЫ КҮБРӘК. ГӨЛДЕРӘП КИЛӘ ДӘ, ДАВЫЛЛАП ҮТЕПТӘ КИТӘ. КАЙЧАК МӘХӘББӘТ ТӘ ШУШЫ БОЛЫТКА ОХШАШ. ЯРАЛАРЫ ГЫНА ӘРНЕП КАЛА.

Алия ӘХМӘТШИНА

ЮЛӘР МӘХӘББӘТ

Ялгыз гомер итүче әнинең авызында гел бер сүз булды: «Тибешкәндә тиңең булсын!» Мәхәббәт тиңлекне уйлап торса икән... «Тиң түгеллеген дә белдем, өзелеп сөйде яшь күңел», – дип, җырлар чыгармаслар иде. Мин – әнинең, ул – минем бердәнберем. Әти дияр кешемнең үз тормышы – бездә эше юк. Миңа – 18! Яшьлекнең иң матур, садә чагы. Мәктәп елларын бергә кичкән дус егетем дә бар. Динар, мотоциклына атланып, күрше авылдан көн дә килеп җитә. Аның белән рәхәт. Сөйләшеп сүзләр бетми. Гомер буена бер колхоз авылларында яшәгәч, мин аныкыларны, ул минекеләрне яхшы белә, яшерен серләр юк. Бәхетемнән канатланып йөргән шул җәйдә безнең авылга кунак егете кайтты. Моңарчы да кайткалагандыр инде ул, игътибар гына ителмәгән. Ә беркөнне клубтан ул мине озата кайтты. Динарларның көтү чираты иде. Арыгандыр ахрысы, күренмәде.

Шулай итеп ике егетле кызга әйләндем. Динар килмәгән көнне Кунак егете озата кайта. Аның белән күбрәк очрашкан саен, гыйшык тәлинкәсе аның ягына таба авыша бара. Гашыйк булырлык егет иде шул ул. Җитмәсә, нәселләре дә бик абруйлы. Безнең аралар хакында әти-әнисе дә ишеткән, күрәсең. Пар канатлы, җитеш тормышлы гаилә баласына тиң түгеллегемне бик тиз аңлаттылар. «Кая үрелә ул атасыз кыз! Алар кем дә, без кем!» Гарьләндем генә дисәм, аз булыр. Кеше күрмәс хәлләргә җиттем.

Әни дә мине юатудан чарасыз: «Күңелеңне юкка иләсләндермә! Бергә булсагыз да, мәңге сине аңламаячак ул. Безнең тормышны белгән кешемени? Аңласа, сине шул Динар гына аңлый инде, кызым. Икегез бертөсле бәрәңге ашаган, бертөсле тәрбия күргән. Динар белән матур гына йөрегез дә, матур гына яшәрсез аннары. Рәнҗетмә аның мәхәббәтен».



Шул көздә Динар армиягә китте, мин – университетка. Әти-әнисе каршы дип кенә, Кунак егетенең хисләре сүрелмәде. Казанда бик очрашмасак та, каникулларда гел бергә идек. Боларны Динар да белде. Армиядән бер тапкыр да хат язмады ул миңа. Хатлар язмаса да, мине йөрәгеннән алып атмаган икән. Армиядән кайткан көнендә үк мотоциклы безнең капка төбенә туктады. Үзгәргән... Чибәрләнгән... Күз алдымнан бергә үткән мәктәп еллары, бергә узган кичәләр йөгереп узды.

Динар бәдәне белән генә түгел, рухы белән дә ныгып кайткан иде. Үгезне мөгезеннән эләктерергә иде, ахрысы, карары. Көтү кайтып берәр сәгать узуга, матае белән тырылдатып килеп тә җитә. Казанга барсам, минем арттан анда бара. Динар кайтып бер ел тулыр-тулмаста, без өйләнештек. Ә Кунак егете белән туй алдыннан тагын бер тапкыр очраштык әле. Ике минутка гына, саубуллашыр өчен генә. Очрашасы булмаган икән шул. Соңыннан гомер буе төшләремә кереп җәфалар өчен очрашканбыз. Нәрсә бу – хыялымда калган мәхәббәт тынгы бирмиме соң миңа? Гел бер төш – ул чакыра, ә мин аның белән китә алмыйм. Баштагы елларда әни комачаулый иде. Аннары – ирем. Балам тугач – балам. Гел шул бер төш... Нигә кирә ул? Бәхетсез дә түгел бит мин югыйсә.

...Әни иртә китте. Хуҗалык, әнинең авыру энесе – барысы да безнең өскә калды. Әнинең, Динар гына аңлар, дигәне рас килде. Хуҗалыкны туздырмыйча, авыру абыйны (урын өстендәге кешене!) читкә тибәрмичә, минем бар мәшәкатемне үзенеке кебек кабул итте ул. Кайчакларда яшьлек искә төшә дә, уйлап куям: Динар урынында теге егет булса, ул боларга чыдар иде микән?

Ә узган ел без Кунак егете белән тагын очраштык бит. Тамчы да үзгәрмәгән. Озак кына сөйләшеп тордык. Әнә шул көнне килде инде миңа бу чагыштыру. Яшьлектә аңа булган хисләремне давыл болытына охшаттым. Күкрәп килде дә, тузан гына туздырып китеп барды. Ә минем Динарым – утырып яуган җәйге яңгыр кебек. Яшеннәр яшьнәтеп, күкләр күкрәтмәс; яратам, синсез тора алмыйм димәс; иң кирәк вакытта иңен куяр, күкрәге белән каплар, шифалы тамчылар булып тамар.

...Очрашуның файдасы булды бит. Теге төшне башка күргәнем юк инде.

PRESSA.RU



ШУШЫ ЯШЕМӘ ҖИТЕП ТУРГАЙНЫ ЯКЫННАН КҮРГӘНЕМ ЮК ИДЕ.

Чишмә юлында миңа тургай юл күрсәтә барды. Пырхылдап очкан күбәләк кебек. Үзе тиз-тиз кагына, үзе тавышындагы көмешләрен чыңлатып сайрый. Дөньяның бер бәхетлесе инде менә! Аның бу халәте, садә җыры тәмам сихерләде мине. Кайда, кайчан шаһит булган идем соң әле мин шушындый чыңлап торган бәхет өлгесенә? Гүзәл Уразованың рәвеше, Гүзәлнең тавышы, Гүзәлнең бөркелеп торган бәхете, яшьлек тылсымы лабаса бу тургайда!



Асия ЮНЫСОВА

ТУРГАЙ

Татар эстрадасында унөченче сезонын башлап йөргән Гүзәл Уразова сәнгать юлына, шул яз китергән тургай кебек, зәңгәр күккә үрләп, кагынып килеп кергән иде. Биектәге җырчы кош күпләр күзенә күренә бит ул. Гүзәлнең берәүнекен дә кабатламаган тавышына бәя-билге таба алмыйча йөдәдек тә, килештек – бу көмеш катыш ефәктән үрелгән тавыш Гүзәлнеке генә! Дөрес, Бритни Спирс, Селин Дион тавышы аһәңнәрен дә эзләп азапландык әле...

Әмма ничек кенә булмасын, Гүзәл Уразованың беренче дискы (кассетасы) ук, чит илләр манерына әйтсәк, алтын диск булды, ягъни җиде ел дәвамында сатуда булып, миллионлаган тираж җыйды. Чит илдә булса, мега-йолдыз дип йөртерләр иде аны. Казанга, икътисадчы яки журналист булам, дип килгән Гүзәл Уразовадан җырчы ясаган остазлары – дөрес юлны күрсәткән Мәсгут Имашев та, аны күз угыннан яздырмаган Айдар Фәйзрахманов та аның белән бик горурланалар булыр.

Сүзне Гүзәл Уразова дип башласак та, алар менә унике ел инде «Гүзәл–Илдар» җыр театры булып яшиләр. Бу матур пар, икесенең дә беренче һәм бердәнбер мәхәббәтләрен никах белән теркәгән көннән алып, илебезнең Европа-

сын, Азиясен иңләп, җәй эзләп йөриләр. Әйе, әйе, Кыш кызы Гүзәл җәй ярата. Умырзаялардан ромашкаларга таба юл сала-сала, елына 170 шәр концерт бирә-бирә, меридианнар саный алар. Синең концертыңа тамашачы юл югында юл сабып килә икән, ничек санамыйсың, ди.

Тамашачы белән күрешү рәхәтен юл михнәте алыштыра тора. Бервакыт Түбән Варта белән Сургут арасында машиналары ватылып калып, туңганнарын оныта торган түгел. 42 дәрәҗә салкын. Унике кешелек «ГАЗель» эштән чыккан. Ягардай бөтен нәрсә ягылып беткән... «Гүзәл–Илдар» җыр театры өчен тәгәрмәчле өйгә әйләнгән үзләренең автобусларын шуннан соң булдырганнар. Әле, барыбер, тыгыз графикка чыдамаган кайберәүләр театрдан киткәли.

Гүзәл белән Илдар үзләре ничек түзә икән соң? Хикмәт мәхәббәтнең тылсымлы көчендәдер дип уйлыйм. Ә бу икәүнең мәхәббәте сыналган. Хатын-кыз яратмаган кешесеннән өч бала тапмас, ир-ат яратмаган кешесенә бәйрәм түгел көнне дә 150 шәр розадан букет күтәреп кайтмас. Һәркайсы хитка әйләнгән йөз җырның һәрберсендә алар үз мәхәббәтләре хакында сөйлиләр түгелме соң! Әлбәттә, сәхнәгә алып чыгу өчен мәхәббәт иң отышлы тема. Илдарның Гүзәлгә, Гүзәлнең Илдарга җырлаган җырларын Төркиядә, Казакъстанда гына түгел, Италиядә дә тәрҗемә итеп җырлыйлар.

Гүзәл Уразова үзе «халыкчан» дип санаган «тәмле» тавыштан кайвакыт «Китмә, сандугач», «Гөлйөзем ариясе», «Сагыну», «Сусау» кебек чын шагыйрьләр шигырьләренә язылган мәңге искермәс әсәрләр дә яңгырап куя. Сагындырып кына. (Хәер, Гүзәл Уразова сүзсез вокализ гына җырласа да, онытылып тыңлар идек без аны.) Ни хәл итмәк кирәк, моңлы аваз ияләре авызына да үзешчән, фәкать тавыш хисабына гына яши ала торган җырулар да килеп керә. Киштәсенә «Татар җыры» бәйгеләренең унөч «Алтын барс»ын тезеп куйган җырчының бәхет (Ураз – төрки халыкларда Бәхет таңресе), ярату хакындагы һәр җыры, уникаль клиплары булганга күрәдер дә, теле-радио компанияләренең музыкаль тапшыруларын бәхетле итеп тора. Гүзәл Уразова берничә мәртәбә «Елның иң популяр җырчысы» номинациясендә дә бүләкләнде. 2009 елда Татарстанның атказанган артисткасы исеменә лаек дип табылган җырчының үзе өчен иң кадерле җыры – «Нигә болай ашкынасың, йөрәк?» дигәне бугай. 2002 елның 8 гыйнварында – туган көнендә шул җыр белән сәхнәгә чыгып, беренче «Алтын барс»ын алган иде бит ул! Һәр җырның язылу тарихы, ул җырга төшерелгән клиплар турында җәелеп китеп сөйлисем килеп йөдим. 15 секундлык клип төшерү өчен яртышар көн вакыт китә. Ә бит хәзер инде дистәләгән альбомнар иясенең һәр җырына төшерелгән клипларны туплап, бер фильм әзерләп булыр иде. Ул фильм, мөгаен, «Мәхәббәт сәфәре» дип аталыр иде. Чөнки Илһам Шакиров исемендәге җыр конкурсының бердәнбер гран-при иясе Илдар Хәкимов белән Гүзәл Уразованың мәхәббәте дә Салават Фәтхетдиновның унике концерттан торган гастроль сәфәрендә катнашып, Ижаудан Төмәнгә таба барган дәвердә борнаган. Әй ул чагында Илдарга булган алкышлар!!! Менә шул алкышлар иясе, бергә тормыш башлауга, бер адым артка чигенеп, икесе өчен дә ирләрчә хәл итеп куя: «Гүзәл алга чыгар. Минем бурыч – аның да, балаларның да, җыр театрының да иминлеген тәэмин итү!» Гүзәлнең сөйкемле бит уемнарына, теннис уйный-уйный тәмам зифаланган буй-сынына гына гашыйклык түгел инде бу, бәлки хатынының талантын күрү, тану, зурлау!

Кавышкан көннән башлап Гүзәл өчен Илдарның исеме – Җаным! Бу «җаным» пароль сүзгә дә әйләнгән бугай инде. Мисалмы? Ярый алайса, бер мисал. Италия башкаласы Римның үзәк мәйданындагы фонтан янында клип төшерү уе кем башына килгәндер? Фонтан янышнан кеше өзелеп тормый дию генә аз. Туристлар кайнап тора анда. Әмма кирәк булгач, кирәк. Гүзәл, бөтен кыюлыгын җыеп, фонтан якасына басып, татарча җырлап җибәрә. (Гүзәл: «Кытайлар фотога төшереп рәхәтләнде инде».) Мондый экзотика җыелган халыкны гүпчем кыздырып җибәрә. Җырчыны бөтереп алалар. Нәтиҗәдә, Гүзәл Рим урамында адашып кала. Аның шул «Җаны-ы-ым!» авазын ишетеп, Илдар сөйгәнен килеп «коткара».

Гүзәл: «Безнең тормышка кызыккан кешеләрне үзебез белән гастрольгә алып чыгар идем мин».

Клиплар дидек бит әле. Алар бик күп, дидек. Инде аларның Таиланд (имеш, оригиналь рельеф кирәк), Италия, Гарәп Әмирлекләре, Кырым ярымутравы кебек җирләрдә төшерелүен дә искәртик. «Өзмә өметем» җырының клибы, әнә, «Аватар» фильмына кергән кадрлар төшерелгән архипелагта эшләнгән. Бөтенесе дә тамашачыга кызык, матур, кабатланмас булсын өчен бит! Илдар да, Гүзәл дә бу эштә үзешчәнлекне яратмыйлар. Кайвакыт клипларны төшерүгә 15-20 кеше җәлеп ителә. Махсус сценарий языла, махсус режиссер чакырыла. Ә төшүен күп вакыт Гүзәл үзе төшә. Әйтик, «Нигә болай ашкынасың, йөрәк?» җырының клибын төшергәндә арендага самолет алына. Гүзәл, таң чыгында коена-коена, арыш басуы буйлап яланаяк чаба. «И-и, ул таңда туңганнарым!» – дип искә төшерә ул бүген. Ә Кара диңгездә, кыялар ышыгында су кызы рәвешендә йөзеп йөргәндә курыкканнары! Янында акула йөзеп

PRESSA.RU



Караидел районында ике әби белән бер бабай Гүзәл–Илдар концертына елга буйлап салда агып килгәннәр икән.

килсен дә, курыкмассың! Ярый әле «акула» дигәне дельфин булып чыга. Ә кыя читенә басып җырлаганда кинәт искән көчле җил упкынга себереп аткан булса... Андый экстримнар күп инде ул. Мәк басуында яки Каһирә урамында, Венеция каналлары фонында яки Колизей эргәсендә төшерелгән клиплар тагын кайсы җырчыда бар? Аның хәтта Испания ярыннан Африкага карап, Гибралтар бугазында төшкән кадрлары да бар!

Федераль телеканалның «Рублево-Бирюлево» проектында төшү дә Гүзәл Уразова белән Илдар Хәкимов өчен шул клиплар рәтеннән уза торган бер вакыйга булгандыр инде. Гүзәл бу «клип»ны сагынып сөйләми. «Ялгыш булды ла ул. Андагы затлы вилла да безнеке түгел. Тапшыру режиссерлары кушканны үтәп йөреп, дәрәҗәмне генә төшердем», – дип саный. Юк ла инде. Мәскәү бер дә исемсез кешене сайлап та алмас иде. Безнекеләр ясалма рәвештә тудырылган хәлләрдән бер дә сынатмыйча, матур чыктылар. Гүзәл җитеш тормышта яшәү өчен тырыш булырга, ялкауланмаска икәнен кулына көрәк алып та, себерке тотып та исбатлап күрсәтте. Телевизор карап утырган кавемдәшләренә хатын-кызның кибеткә чыкканда да чәче таралган, күлмәге үтүкләнгән булырга тиешлеген үз мисалында дәлилләде. Аның белән «өен, ирен, балаларын алмашкан» хатын, ул булып, матурлык салонына, ресторанга, фитнес-клубка йөргән арада ул аның балаларын тәмле ризыклар белән сыйлады, ирен кулына чүкеч алырга мәҗбүр итте, «уф Аллам»ын әйтә-әйтә, җир казыды, бәрәңге утыртты.

Бу тапшыру вакытында ят хатын белән бергә мин дә Гүзәл Уразованың концерт күлмәкләрен күздән кичердем. Күп икән алар! Һәр сезонга сигезәр кием хәстәрли торгач, йөзләгән күлмәк җыелган. (Концертка барганда шул күлмәкләрең өйдә онытылып калса, ә? Андый хәлләр дә булган.) Арада канатлылары да, кадаклылары да бар. Теге – концерт барганда үткен тимерчыбыгы учын үтәли тишеп чыгарган күлмәген дә саклый икән әле. Югыйсә канап торган кулын аркасына яшереп, «шат күңел» белән сәхнә тотканын һич онытa торган түгел. Татар сәхнәсендә светоидлы (эчтән яктыра торган) күлмәкне дә беренче булып Гүзәл киде.

«Хыялымда чәчәкләрдән үргән күлмәк кию», – ди гүзәл җырчыбыз. Юк, юк, ашыгам. Гүзәл бу җөмләне соңрак әйтер. Әле ул ишектән генә кереп килә. Кызы сәфәрләрдә чагында бөтен җаваплылыкны йөкләп өй тотучы әнисе Фира ханым, әти-әнисен озату һәм каршы алуларга тәмам күнеккән олы кыз Эллари, уртанчы кыз Камилә, бердәнберлек һәм төпчеклек рәхәтенә чумган бәләкәй Самир һәм, әлбәттә, шушы бер атнада да җаныкаен үлеп сагынып өлгергән Илдар – барысы бергә дәррәү кубарылып, Әнкә каршына томырыласылары бар. «И Бәбием, исән-сау төгәлләдеңме авыртмас башка тимер тарак булган бу мәрәкәне? Телевизор буләк итеп китмәкче идең, булдырып булдымы соң?» – бусы Илдар; «Әнием, бүтән китмә инде, яме! Синнән башка өйдә рәхәт түгел», – бусы балалар. «И-и балаларым, тәмлеләрем, җимешләрем! Бүтән беркая да китмим, сезнең янда гына булам», – бусы Гүзәл үзе.

Илдары белән бергә атлап кергән бер бүлмәле фатирларында да бик бәхетле иде Гүзәл. Иркен фатирда яшәү тагын да рәхәтрәк икән. Гүзәл белән Илдар бәхет, муллык ачкычының, Ходай биргән бүләк булудан битәр, иҗтиһад, тырышлык әҗере икәнлеген беләләр инде.

ИРТӘГӘ ТҮГЕЛ, БҮГЕН!..

Ризидә
ГАСЫЙМОВА



блогер: www.syuyumbike.ru

Авылдашым, бергә уйнап үскән дустым Лենаның ире үлеп китте. Көтмәгәндә. Дөрес, берәр ай чамасы элек улым: «Валентин абыйга инфаркт булган икән», – дип кайтып әйткән иде. Мин бу хәбәрне ишеткән минутта Ленага шалтыратып хәлләрен белешергә ниятләп тә куйган идем. Нишләптер өлгереп җитеп булмады менә...

Дөресен әйткәндә, соңгы вакытта бик аралашып яшәмәдек тә шул без. Югыйсә, Казанда укуны тәмамлап, Чаллыга яңа эшкә кайткан чагында, мин иң элек башка беркемдә дә түгел, ә нәкъ менә Леналарда тукталган идем.

Һәм без дистә еллар буе авылдашларча, дусларча дигәндәй, даими бәйләнештә, элемтәдә тордык. Аннары инде әллә гаилә мәшәкатьләре басты, әллә балаларның бик тиз үсеп китеп, аерылмас дусларга әверелүе безне, нишләптер, ерагайтты – кем белсен, аралашулар сирәгәйде. Балалар аша бер-беребездә булган яңалыкларны ишетәбез дә, тынычланабыз – күрешүләр гел киләчәккә күчә.

Әмма мөнәсәбәтләр элеккечә якын булмаса да, Лена белән Валентин – бу гаҗәеп пар, яшьлегемнең Чаллыда узган бер матур чорын, шул чорның эзен, рухын, яктылыгын үзләрендә саклаган булган икән. Валентинның – һәрчак көләч йөзле керәшен егетенең үлеме миңа кинәт кенә шул яшьлекнең бик-бик артта калганын да искәртте кебек.

Хәер, яшьлек ничекләр артта калмасын – инде балалар үсеп җитте бит. Әле кайчан гына Лена, авылга кайткач, кызык ясап (и, бала-чагалар булганбыз инде бөтенебез дә!), кечкенә Владигын безнең янга пакетка утыртып алып килгән иде. Шул Владик инде үсеп җитеп, институт тәмамлады, юрист булып эшли, үзе дә бала үстерә. Минем Алмазыма да – уйласаң исләрең китәр – 22 тулып ята. Алмаз кечкенә вакытта без Леналарга кунакка бик еш бара идек. Яңа теле ачылып килгән сабыем, яңа һөнәренә сөенә-сөенә, «Шалкан» әкиятен сөйли, Лена белән Валентин, аны кат-кат тыңлап, рәхәтләнеп көлешәләр иде. Бүген Алмаз инде әнә Казаннан Валентин абыйсын соңгы юлга озатырга дип кайтты.

...Болыт кебек халык – Валентинның туганнары, хезмәттәшләре, дуслары җыелган подъезд төбендә без Алмаз белән икәү, бу кинәт килгән югалтудан тетрәнеп, әкрен генә сөйләшеп басып торабыз.

– Минем хәзер матди байлыкларга исем китми, улым, – дим мин. – Булганына риза булып, шөкер итеп яшәр өчен дә гомер кирәк.

Ул исә минем фикергә каршы килми генә үзенекен өсти:

– Просто бүген яшәргә кирәк, әни.

– Бүген яшәргә? Ә мин бүген (!) яшәмиммени соң?

– Белмим шул, – ди ул, мине үпкәләтәсе килмәгәндәй, сак кына.

– Ашыйсым килгәнне ашыйм, киясем килгәнне киям. Дөрес, кая телим, шунда барам, дия алмыйм. Чит илләргә йөрергә хирыслыгым да юк, беләсең. Гомумән алганда, үземне бернидән дә чикләмим кебек. Синеңчә мин нәрсәне иртәгәгә калдырам икән соң, улым?

– Бәлки, аралашуныдыр?

Аралашуны?! Алмаз әйткәч, сискәнеп киттем: чыннан да, болай гына – бер йомышсыз кемгә дә булса барганым булды микән минем соңгы елларда? Мөгаен, юктыр... Эшмәкәр хатын-кыз да түгелмен, югыйсә, гаиләгә күпләп акча кертүче дә түгелмен, әмма дә ләкин, ни гаҗәп – минем бүген дус-иш кызларым белән кафеда сөйләшеп утырырга да вакытым юк икән ләбаса! Дистә еллар буе аралашып яшәгән күрше әбинең кереп хәлен белешергә дә вакыт тапмыйм икән бит мин бүген! Хәтта... менә Валентинны да инде 4-5 ел чамасы күргәнем булмаган икән! Мондый очрашу-хәл белешүләрнең кайсыберсен мин йә күнегелгән гадәт буенча иртәгәгә калдырып киләм, йә бөтенләй кирәксез бер эш, хәтта вакытны бушка сарыф итү дип исәплим. Ә үзем шул алтындай кыйммәт дип санаган вакытымны өйдә кат-кат тузан сөртеп, телевизордан тузга язмаган шоу-тапшырулар карап, интернетта социаль челтәрләрдә актарынып... үткәрәм икән. Бер сүз белән әйткәндә – әрәмгә!


Интернет, дигәннән. Бу чир, хәерсез, инде балаларга гына түгел, үзебезгә дә йоктымы әллә соң ул? Алар бит хәзер дуслар белән уйнауны инде компьютер каршында утыру дип кенә күз алдына китерә. Без дә бүген очрашып сөйләшүгә караганда, «Вконтакте»да гәпләшеп алуны кулайрак күрәбез түгелме? Социаль челтәрләрдә дуслашабыз, бәхәсләшәбез, хәтта үпкәләшәбез...

Әгәр алга таба да шулай дәвам итсәк... Үкенечләрнең моннан аянычлары да булырга мөмкин бит әле аның! Без... намазга басуны да, күнегелгән гадәт буенча, һаман иртәгәгә калдырып киләбез түгелме соң? Бүген кылынасы гыйбадәтне дә иртәгәгә күчереп торабыз... Аллаһ янына барырга әзерлекне дә (бик яхшылап, җиренә җиткереп, әмма...) бүгеннән түгел, иртәгәдән башларга ниятләп йөрибез... Эшлисе игелекләребезнең дә кайберләрен иртәгәгә кадәр кичектереп тормыйбыз микән әле гөнаһ шомлыгына каршы?

Югыйсә яшәү бик гади нәрсә икән ләбаса. Бүген яшәргә кирәк диләр әнә бездән акыллы яшьләр. «Просто» бүген яшәргә кирәк, диләр.

Иртәгә түгел, бүген!..

PRESSA.RU



ТУМЫШТАН ЗӘГЫЙФЬ, ФИЗИК КИМЧЕЛЕКЛЕ БАЛАЛАР ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘБЕЗДӘ БИХИСАП. КҮПЛӘРЕ ГАЯТЬ АВЫР ХӘЛДӘ. БУ ЯЗМА ШУНДЫЙ АВЫРУ БАЛАЛАРЫ БУЛГАН ГАИЛӘЛӘРНЕ ДӘ КҮЗДӘ ТОТЫП, АЛАРГА ХӘЛ КАДӘРИ ФАЙДАБЫЗ ТИМӘСМЕ ДИГӘН КИҢӘШ-ТЕЛӘК РӘВЕШЕНДӘ ЯЗЫЛДЫ...



Ләбиб ЛЕРОН

БӘХТИЯР

(Ахыры. Башы журналның 6 нчы санында.)

* * *

Мин үземнең әнигә шалтыратам:

– Әни, – дим, – чиккән кулъяулыкларың бармы?

– Нәмәгә? – ди әни.

– Бәхтиярга повестка килде. Тиздән армиягә озатабыз!

– Булмастайны сүләмәле! – Трубкадан әнинең рәхәтләнеп көлгәне ишетелә. Аңа мин дә кушылам.

Әни, минем шаяртканны аңлап, үзе дә уенга кушыла. Трубкадан аның дога укыганы ишетелә:

– Әл-хәмдү лилләәһи раббил гааләмиин. Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлинәә мүхәммәдин вә галәә әәлиһии вә сахбиһии әҗмәгыйин. Әгуузү билләәһи минәш шәйтаанир раҗиим. Бисмилләәһир рахмәәнир рахиим. Инфиру хыйфәәфәүв вә сикааләүв-вә җәәһидүү би әмвәәликүм вә әнфүсикүм зәәликүм хайрулләкүм иң күнтүм тәгъләмүүн. Вә әгыйддүү ләһүм мәстәтагътүм миң куввәтиүв вә мир рибәәтыйль хайль...

Әни, Пучыдан Әнәк мәчетенә йөреп, гарәпчә укый-язарга

өйрәнде. Хәтере шәп. Хәзер догалар өйрәнгән вакыты. Мин аның нинди дога укыганын аңламыйм. Шуңа күрә сорыйм аннан:

– Нинди дога бу?

– Солдатка озату догасы! – ди әни, исе китмәгән булып.

– Каян бик тиз ятлап өлгердең әле? – дим.

– Җатламадым. Син шалтыратканда «Догалар» китабын актарып утырадырыем...

Догадан соң әни дә, мин дә җитдиләнеп калдык.

Трубканы куюга, үзебезнең яшьлек җыры колагымда кабат яңгырый башлады:

Военкомат ишек алдын
Таптамам, дигән идем...
...Сөйгән ярым, туган ягым
Ташларга туры килде...

Ни аяныч, «никрут» Бәхтиярның туган ягы бар, сөйгән яры юк. Булмас та инде.

* * *

Повесткада Бәхтиярга 2009 елның 13 февралендә килергә, дигәннәр...

13 февральдә Фидания Чуйков урамындагы 7 нче хастаханәгә кереп ятарга тиеш. Кичектергесез операция көтә аны. Хәлнең гаять катлаулы икәнен икебез генә беләбез.

13 февральдә мин Актанышка – Пучыга кайтырга тиеш идем. Хастаханәдә яткан әнинең хәлен белергә...

* * *

Беркөнне олы кызым Айсылу төшендә Бәхтиярны сөйләшкән итеп күргән. Сөенеп уянган да иртә белән безгә шул төшен сөйли:

– Теттереп сөйләшә Бәхтияр. Елмая, шырык-шырык көлә! Әллә Бәхтиярның теле ачылмакчы була микән? – ди.

Андый төшләр үземә дә кергәне бар. Фидания дә, кече кызым Ләйлә дә әллә ничә тапкыр Бәхтиярның сөйләшкәнен төшендә күргән...

Табык төшенә тары керер, диләр...

Бу – шуңа бер мисалдыр инде.

* * *

Күрәзәчеләр турында берничә сүз.

Башыңа төшсә, башмакчы булырсың, дигәндәй, күрәчәгең булса, күрәзәчегә дә барырсың. Ярамый, дисәләр дә, бардык, бик күп йөрдек аларга. Балабызны ничек тә терелтәсе, сәламәт итәсе килә бит! Әйбәт фараз кылсалар – сөенәбез, өметләндермәсәләр – кәеф төшә...

Елгабашта бер бик әйбәт күрәзәче бар икән, дигәч, киттек Мөслим тарафына. Узган гасырның туксанынчы еллары иде бу. Дөресрәге, туксан икенче елның июль ае. Без барасы әлеге авыл мин үскән Олы Имәннән әллә ни ерак түгел. Ике авыл арасы 20-25 чакрым бардыр: Олы Имән–Иске Сәет–Яңа Сәет (шагыйрь Зөлфәтнең туган-үскән авылы)–Елгабаш...

Без, Бәхтиярны күтәреп, ишегалдына килеп кергәндә кечкенә гәүдәле күрәзәче әби (исеме Гөлчирә дип истә калган) тавыкларын, «Ти-ти-ти-ти», дип, үз янына чакырып, агач ялгашка җим сала иде. Ул безнең исәнләшүебезне әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә ишетмәгәнгә сабышты – җавап-сүз кайтарып тормады. Җыерчык баскан чырае да, нигәдер, болытлы көн кебек караңгы иде. Кабул итәргә уйламый, ахры, бу дип уйладык. Инде капка тарафына борылмакчы да булган идек, әмма бәләкәй әбиебезнең өй болдырына таба кыймыл-кыймыл юл алуын күргәч, аңа иярдек. Өйгә кергәч, ул безгә ишарә белән генә урын тәкъдим итте. Ни хикмәт, йөзе ачыла, яктыра төште аның.

Коръән ачып күрәзәлек итә икән, дигәннәр иде, хак, ахрысы. Безнең йомышны тыңлагач, нинди төскә буялганын һич аңлап булмый торган тәрәксез агач урындыкка утырды. Өстәл уртасында яткан калын китапны үзенә таба якыйнайтты да, уң кулының имән бармагы белән шул китапның урта бер җиреннән ачты. Аннары ишетелер-ишетелмәс тавыш белән гарәпчә укырга тотынды. Шулай күпмедер вакыт узгач, укудан туктап, башын күтәрде. Менә хәзер Бәхтияр турында сөйли инде, дип торганда, әби минем тормышымнан фактлар «казып» чыгара башлады:

– Эшең язу-сызуга бәйле икән. Тирә-ягыңда үзең шикелле кешеләр бик күп. Авызыңда сүз тормый. Шуның аркасында күп кыен ашыйсың. Серләреңне бүтәннәр белән уртаклашырга тырышма. Башкалар сөйләшкәндә авызыңны ябып тор... Әтиең сине бик көтә. Борчыла. Ник аның янына кайтмыйсың? Бик көтә ул сине. Алай ярамый. Кайтырга кирәк. Синең ятим үсүеңдә ул гына гаепле түгел...

Күрәзәче әле Фиданиягә, әле мин бахырыгызга карап, сүзен дәвам итте:

– Улыгыздан тыш, тагын ике кызыгыз бар икән. Бер-бер артлы туган бу балакайлар. Бик яратасыз үзләрен. Аларга өмет белән карыйсыз. Үскәч, сезгә зур терәк булачаклар...

* * *



Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе

Айсылу иншасыннан: энемнең теле ачылса, әниемнән дә бәхетле кеше булмас иде!..

Фидания сөйли:

– Әби кулга алуга, Бәхтияр йоклап китте. Аңа Коръән ачты. «Терелә, тик бик озак терелә», – диде. «Ничек соң ул бик озак?» – дип сорасам да, тәгаенләп әйтмәде. «Башкалар шикелле өйләнеп яши алырлык булырмы?» – дим (Бәхтияр әле күкрәк баласы гына иде ул вакытта). «Аңа хәтле бөтен җире дә килешә әле аның», – диде. Бик озак дигәнне мин 4-5 яшькә дип уйладым. Анысы да бик озак төсле иде әле...

* * *

Фидания сөйли:

– Икенче баруыбыз да Мөслимгә булды. Мөслимдәге багучы кыз Эльмира турында күп яздылар.

Эльмира да өметләндереп җибәрде безне. «Сине бозганнар.

PRESSA.RU

Мин кушканнарны эшләсәгез, балагыз терелер», – диде. Бик катлаулы киңәшләр бирде. Бозымны чыгару өчен, 126 чокыр казып, баланың башын гына калдырып күмеп, һәр чокырда кырыгар минут яткырырга кирәк. Чиратлашып, бер чокырга – аркасы белән, икенчесенә эче белән яткырасы. Ятканнан соң, һәр чокырга «икс» рәвешендә энә калдырып барырга кирәк. Һәрберсенә ятып чыкканнан соң, чокыр араларына салам куеп, ут төртәсе. Саламнар барысы бертигез янып бетәргә тиеш. Шуларны эшләгәннән соң, баланың тамак төбенә яшь чебинең беренче күкәен куеп, бер дә кулдан төшермичә, 140 кат әйләндерәсе. Аннары бака кабырчыгы җыеп, аны ваклап, марляга салып, ике сәгатькә баланың колагына бәйләп куясы. Аларны эшләргә мөмкин.

«Юлдан килгәнсез икән, кайтуыгыз да юлдан булыр!» – дип әйткән ди бер «күрәзәче».

Иң катлаулысы чокыр инде. Минем авылга кайтып, башта 78 не казыдык. Бала озак ята алмас, дип курыккан идек, ята икән. Соңга таба көнгә бишәр чокырда ята башладык. Җырчы Асаф Вәлиевкә рәхмәт инде – аның кассетасын алып кайткан идек. Бәхтияр шуны тыңлап, тынычлап ятты. Җир дә тынычландырадыр, мөгаен. Тик җир җылынган, көн коры булырга тиеш. Кызганыч ки, җәй кыска шул. Җилле, яңгырлы көннәре дә күп. Ул чакта Айсылуның имтиханнары булды. Ләйләнең дә укырга керәсе елы иде. Аларның да язмышын кайгыртмый булмый.

Безнең чокыр казып ятканны күреп, кайберәүләр шаккатты. Алтын эзлиләр дип уйлаганнардыр инде. Ә без алтыннан кыйммәт булган сәламәтлек эзләдек.

* * *

Бервакыт башыбызга шундый уй килде: «Бәлки Бәхтиярны чит илдәге табибларга күрсәтеп карарга кирәктер?!» Дөрес, акча юк. Ләкин... Ният иткән – теләгенә ирешкән, диләр бит. Кем белә, безгә дә бәхет елмаеп куюы бар...

Татарстанның ул чактагы Президенты исеменә үтенеч хаты язып, шундук аны тапшыру хәстәрен күрдек. Озакламый сәламәтлек министрлыгыннан җавап килеп төште. Үзләренә килергә кушканнар. Бардык. Канатланып-очып. Тик... канатны бик тиз кистеләр. Казандагы психиатрия клиникасыннан ниндидер белешмә кирәк, диделәр. Бардык. Балалар психиатры кабинетына кердек. Балалар психиатры дигәнебез Зефирова дигән фамилия йөрткән татар апасы булып чыкты. Мөлаем ханым безгә бик тәфсилләп әле урысча, әле татарча аңлатырга тырышты. Чит илгә барып акча туздырып кына кайтачаксыз. Мәскәүгә барсагыз да шул ук хәл көтә диде. Иң яхшы психиатрлар – Казанда ди. Әүвәл бездә дәваланып карагыз, диде. Ышандырды. Без шулай иттек тә.

Бәхтиярны Волков урамындагы хастаханәгә салдык. Иртән китереп, кичке дүрттән соң өйгә алып кайтып китәргә тиеш булдык. Бер көн үтте, ике көн, өч көн... Күрәбез: Бәхтиярны дәваларга җыенган кеше юк. Бер атна чамасы йөрткәч, Бәхтиярны хастаханәгә кабат алып килмәскә булдык. Барыбер тикшермиләр, карамыйлар баланы, дидек. Кайчан килсәк тә, Бәхтиярның таш идәндә яланаяк, юеш ыштан белән йөргән чагына тап булдык. Бу кадәр ваемсызлыкны күреп, ак халатлы туташ-ханымнарның пошмаслыгына йөрәгебез әрнеде, сыкрады. Бер безнең балабызга карата гына шундый салкын мөнәсәбәт булса бер хәл иде. Юк, бөтен сабый-нарасыйга – шундый уртак, җан тетрәткеч игътибарсызлык! Кеше җитмәгәнлектән, әлеге хастаханәгә балалар йортларыннан «пачка-пачка» сабыйны «дәваларга» китерәләр икән, дип тә ишеттек.

Ул балаларга җикеренеп дәшүчеләрнең усал тавышларын, сабыйларның исә өзгәләнеп, үкереп елаганнарын ишеткән чакта безнең нинди хисләр кичергәнне аңлыйсыңдыр, укучым.

Без әлеге хастаханәгә бүтән аяк басмаска булдык. Тьфү-тьфү, басарга язмасын берүк!

Шулай итеп, чит илгә барып, Бәхтиярны терелтеп кайтырбыз, дигән зур хыял-өметебез чәлпәрәмә килде, тәмам җимерелде.

* * *

Фидания сөйли:

– Без барыбыз да Бәхтияр тирәсендә бөтереләбез. Безнең бөтен тормышыбыз шулай корылган. Беркөнне Бәхтиярне курчак театрына алып барырга җыенабыз. Ләйлә каядыр китәргә әзерләнә. Әтисе, аптырап, Ләйләгә:

– Син кая барасың, ә бала белән кем кала? – ди. Өйдә кемдер булырга тиеш дигән уй шулкадәр сеңгән аңга.

Авырткан җир турында күбрәк сөйләшәсең бит инде. Безнең Бәхтиярыбыз да – гел үзәктә. Барыбыз да бик яратабыз аны. Айсылу белән Ләйләне әйткән дә юк. Күңелләрендә – гел энекәшләре. Матуррак төш күрсәләр дә, сөенеп уяналар: «Бәхтияр тегеләй итте, Бәхтияр болай итте. Бәхтияр сөйләште», – дип төшләрен юрыйлар. Бәхтияр үзе дә бик назлы, иркә бала. Балалар бакчасына йөргәндә дә йөгереп барып, тәрбиячеләрен кочаклап ала торган иде.

* * *

Дөрес, Бәхтиярны чит илгә алып бармадык түгел, алып бардык, анысы. Ләкин дәвалау максатыннан түгел. Ял итеп, дөнья күреп кайту нияте белән...

Безнең белән бергә Төркиянең Анталья аэропортын, Мәхмүтләр бистәсен, Динизли, Памуккале шәһәрләрен, мәшһүр Эфис каласын күрде Бәхтияр. Анда юл йөргәндә әллә ни борчу китермәде, дисәм...

Кайчандыр Мәрьям ана сөекле улы Йосыф белән яшәгән таш өйгә керергә теләмичә, Бәхтияр бик

яман көйсезләнеп алды. Аяк атларга киреләнеп, бармыйча, бик озак җирдә ятты. Чыгырдан чыгар чиккә җитә яздык, ярый әле Аллаһы Тәгалә сабырлык бирде. Автобус шофёрларының, күпсанлы туристларның кызганулы-уңайсызланулы карашлары астында көч-хәл белән торгыза алдык үз киресенә каткан Бәхтиярны. Шөкер, мондый җәфаланып алулар башка булмады шикелле.

Чит җирдә йөргәндә бер нәрсәгә игътибар иттек. Анда Бәхтияр шикелле балаларга мөнәсәбәт бездәгедән гаять үзгә: андагыларның күз карашыннан ук теләктәшлекне, ярдәм итәргә теләү, шуңа омтылу хисен «укырга», тоярга, сизмләргә була. Безнең илдә исә үткән-сүткәннең карашында әрсезләнеп, кызыксынып карап тору, салкын битарафлык ярылып ята...

* * *

Теш сызлауның коточкыч нәрсә икәнен андый хәлгә дучар булмаган кеше генә белмидер, аңламыйдыр, мөгаен. Ул җәфа белән күп интектем үзем дә. Авыртуга чыдый алмыйча, идәндә тәгәрәп ятар чиккә җиткән чаклар аз булмады. Әмма Бәхтиярыбызның теше сызлавын күргәч, шул хәлнең шаһиты да булгач... Анныкы белән чагыштырганда минем теш сызлавым пүчтәк кенә икәнен аңладым.

Авызына дүрт бармагын кабып, күзләреннән яшьләрен агызып, сиңа карап торсын әле балаң! Ул бит, ул бит, сөйләшмәгәч, кайсы тешенең авыртканын да әйтә алмый! Бик тиз генә җыенып, балаңны җитәкләп, стоматологиягә чыгып чабар идең дә тиз генә явыз тештән котылып кайтып та җитәр идең... Ха-ха! Чәчәкләр һәм чәкчәкләр белән сине кочак җәеп көтеп тордылар, ди, менә! Тот... Кайсы илдә яшәгәнеңне онытма, туганым!

Өченче баруында, ниһаять, күпме нервылы, йокысыз төннәреңнең нәтиҗәсен күрәсең: табибә исән, эш урынында, наркоз бирүче дә янында. Фидания белән икебезнең, Бәхтиярны җилтерәтеп, алдан әзерләнгән ятакка күтәреп диярлек кертеп салганыбызны унлап практикант читтән күзәтеп тора. Беребез улыбызның аякларыннан, икенчебез кулларыннан, башыннан тотып, табибның наркоз биргәнен – укол кадаганын көтәбез...

Ярты сәгать узгач, Динә исемле табибә кыз:

– Өч тешен ямадым, икесен алып ташладым! – ди...

Без исә, тәмам тешсез калса, Бәхтияр ничек ашар, дип борчылып алабыз, әмма Бәхтиярның күпмедер вакытка кадәр тешләре сызламаячагына сөенеп, үзебез дә сизмәстән, җиңел сулап куябыз...

* * *

Акылы белән 3-4 яшьлек баланы хәтерләтсә дә, Бәхтиярның олыгаюын, җегет булуын искәртә торган яклары вакыт-вакыт күзгә чалынып алгалый. Мәсәлән, өйгә ят кыз бала килсә, аны күргә, Бәхтияр оялудан башын ия, ике кулы белән ике колагын тотып, читтән шул кызыйны күзәтеп тора, янына килергә кыймый...

* * *

Бәхтиярның иң курыкканы – бал корты. Хатыным ягында – Октябрь районда да, үземне якты дөньяга иңдергән Түрештә дә аны корт чаккан булды. Шуңа күрә, җәй көннәрендә, аеруча бал кортлары ыгызыгы килеп очкан вакытларда, Бәхтияр өйдә генә утыра. Кичке эңгер-меңгер төшкәч кенә ишегалдына, урамга чыгарга батырчылык итә...

* * *

2009 ел. 13 февраль. Җомга көн.

Бу көнне хатыным Фидания Чуйков урамындагы 7 нче хастаханәгә кереп ятты.

Бу көнне мин Пучыга, хастаханәдә яткан әниемнең хәлен белергә кайта алмадым...

Бу көнне мин, 17 яшьлек Бәхтиярны җитәкләп (туры мәгънәсендә), военкоматка юл тоттым...

* * *

Туп-туры хәрби комиссар бүлмәсенә барып кердек. Исем-фамилиясе «мин – татар» дип кычкырып торуына карамастан, бүлмә хуҗасы минем белән бары тик урысча сөйләшүне генә кулай күрде. Әйтәсемнең барысын да әлеге хәрби иптәшкә җиткердем. Яшермим, ачуым яман иде – кызып-кызып татарча аңлатырга керештем:

– Авыру баланы армиягә алыр көнгә калдыгызмыни инде? – дип ярсыдым. – Сугышыр кешегез юк икән, алыгыз аны, тик безгә исән-сау кайтарып бирегез! – дип дуладым...

Чебен, дулап, тәрәзәне ватамы инде, җә?

Авыру бала белән дә төшенкелеккә бирелмичә яшәргә өйрәндек без.

Ыкы-мыкы килде комиссар, нидер әйткән булды. Мин, тузынып, коридорга чыктым. Хәрбиләрне учётка алып, теркәп утыручы ханымнар янына кердем. Комиссарга әйткән сүзләремне болар да тыңларга мәҗбүр булды. Шулчак бер ханым биш минуттан миңа шундый сорау бирде:

– Бахтияр сейчас в какой школе учится?

– Что?! Он даже не разговаривает! Как он может учиться? У него ум как у трёхлетнего ребёнка! – дим...

Акылы зәгыйфь илдә сәламәт яшәүләре, сөенеп көн итүләре, ай-һай, кыен ла...

* * *

...Военкоматка барып кайткан көннән нәкъ биш ел вакыт узгач, олы кызыбыз Айсылуның икенче баласы – безнең яраткан оныгыбыз Нурихан туды.

2014 елның 13 феврале иде бу.



Язманың тулы варианты – сайтның «Язмыш» сәхифәсендә.

PRESSA.RU



Гүзәл
ӘДҺӘМ

БЕЗНЕҢ ҖЫР!

Нииһаять, мин – Казан дәүләт университеты студенты!

1976 ел, 1 сентябрь. Үзебезнең төркемнең егет-кызлары белән танышып торган бер мәлдә, аудиториягә искиткеч хәрәкәтчән бер кеше керде.

– Татар халык хоры җитәкчесе Ирнис Рәхимуллин булам! – ди ул, үзе белән таныштырып. Рояль клавишлары буйлап бармаклары йөгереп кенә узды да, үзебезне җырлата да башлады, арабыздан биш-алтыбызны сайлап та алды.

Менә шулай, көтмәгәндә-уйламаганда, «хор кызы»на әйләндем дә куйдым. Ә хорда җырлау – шактый кызыклы сәнгать булып чыкты! Янәшәңдәге җырчыларны тыңлый һәм ишетә белү, шул ук вакытта үз партияңне дә төгәл башкару – бик җиңел генә бирелми икән бит.

Ә хор инде шактый танылып өлгергән, консерватория залында, опера-балет театрындагы концертларда да катнашу хокукына ия! Флера Низамова, Ринат Шакиров, Мөнир Нигъмәтуллов кебек оста солистлары да бар.

Май аенда хор белән Литвага «гастроль»гә чыгып киттек. Күңел ышанмый! Вильнюс шәһәрендәге институтларда концерт куябыз, Балтыйк буе шәһәрләрендә экскурсиядә йөрибез. Искиткеч бит!

«Гастроль» тәмамланып, Казанга таба юл алдык. Вагон тулысы белән безнең карамакта: уйныйбыз, көләбез, җырлыйбыз. Сара Садыйкова язган «Мин сине ничек яраттым» җырының яңарак кына радиодан яңгырый башлаган чагы. Ялгышмасам, халыкка ул Разия Гайнуллина башкаруында танылды. Соңрак исә «Саз» ансамбле кызлары үзләренә генә хас мелизмнар белән бизәкләп башкарды бу җырны.

...Бөтен вагон көй, моң белән тула бара.

Мин сине ничек яраттым! –
Мәктәп юллары белә.
Син йөргән эзне аера идем
Башка эзләрдән, бер карау белән...

Башкалар кебек мин дә дәртләнеп җырлыйм. Кинәт сизәм: «хорчы»лар берәм-берәм тына бара.

Мин сине ничек яраттым!

Мин сине ничек яраттым! –
Мәктәп юллары белә.
Син йөргән эзне аера идем
Башка эзләрдән,
бер карау белән.

Мин сине ничек яраттым!
Искә алу да татлы.
Орыну түгел сиңа,
күз атсам да,
Рәнҗетер сыман идем
ул чакны...

«Мин сине ничек яраттым!
Киттең читкә. Көтмәдең.
Мин дә яратам, диеп ул чакта
Ник, иркәм, миңа
хәбәр итмәдең?»

Нигә? Аңламыйм. Ә Ирнис абый миңа: «Дәвам ит!» – дип ымлый. Бер ялгызым җырлыйм түгелме соң? Үзем җырлыйм, үземнең битем ут яна. Мин бит солист түгел. Ялгыз җыр белән сәхнәгә дә бик сирәк чыгам. Ирнис абый, ымлап кына, тагын берәүне җырга кушты. Икенче тавыш партиясе белән Ринат Шакиров кушыла...

– Сездән шәп дуэт чыгачак! – ди Ирнис абый.

Кызаруымны үзем дә сизәм. (Әллә Ринат белән озатышып йөрүебезне сизде микән!)

...Баш күтәрми сессиягә әзерләнеп ятканда, «чыбыксыз телефон» Ирнис абыйдан хәбәр китерде:

– Профсоюз урамындагы «Укытучылар йорты»нда бүген концерт булачак. Ринат белән Гүзәл шунда барсын. Гүзәл «Мин сине ничек яраттым»ны җырлый!

Ирнис абый сүзе – закон!

Ә мин җырның ике куплетын гына беләм икән бит. Кулым китап киштәсенә үрелә. Менә ул! Равил Фәйзуллинның өр-яңа китабын актарам... «Шигырьләр һәм поэмалар»... 1976 ел...

Ачтым, таптым! «Мин сине ничек яраттым»...

Шигырьнең соңгы куплетын тиз генә күчереп алам.

...Каян белим ди мин ул чак,
Кавышу-кушылулар барын.
Сине яраттым, яраттым,
Яраттым... Менә шул бары...

Булды! Йөгердек кенә! Трамвайда да гел шул куплетны көйлим. Истә калдырырга кирәк бит!

...Җитәкләшеп, «Укытучылар йорты»на барып керсәк... шаккаттык. Халык – шыгрым. Яшь сайлаучылар хөрмәтенә концерт оештырганнар икән. Сара Садыйкова үзе шунда! Ә аның янәшәсендәге ханым кем соң? Үзе бик таныш та кебек... Шунда исемә төште бит! «Галия Кайбицкая!» – дим Ринатка.

Әллә кайчангы «Азат хатын» тышлыгында алтын толымлы матур бер йөзгә сокланганым хәтеремдә. Әтием аңлатты: «Бу – Галия Кайбицкая, «Алтынчәч» ролендә»...

Кайбицкаяның Алтынчәче әле дә авылдагы өебездә стенага беркеткән килеш тора. Аны ничек танымыйсың, ди. Шул Кайбицкая! Нәкъ теге сурәттәге кебек. Шундый чибәр!

Хәзер дә аптырыйм: ул чакта Галия Кайбицкаяга 70 яшьләр тирәсе булгандыр. Ә үзе нинди яшь, сылу күренә. Искиткеч нәзакәтле! Затлы ханымнарда гына була торган салмак тыйнаклык катыш горур караш!

Концертны танылган шагыйрь Мәхмүт Хөсәен үзе алып бара! Шаян шигырьләрен, мәзәкләрен сиптерә генә. Түм-түгәрәк корсагын киереп, сәхнә буйлап тып-тып атлый:

– Чебиләр... Чеп-чеп-чеп... Чебиләр...

Башта танылган артисткаларга сүз бирелде. Композиторның үзе каршында җырларга тиешлегем мине шундый каушаткан иде, ханымнарның нинди җыр башкарулары да хәтердә калмаган. Ә менә аларга бүләк ителгән гаҗәеп чәчәк бәйләме – исемдә. Ап-ак купшы чәчәкләр! Безнең илнеке түгел, ерактан кайтартылганга охшаган, чөнки Казан кибетләрендә кызыл канәфер чәчкәсеннән башканы күргән юк ул чакта.

Менә чират миңа да җитте. Нинди җаваплылык! Сара Садыйкованың үзе каршында җырла әле.

...Җырымны ошаттылар! Тамашачы гөр килеп кул чапты. Баш ияргә кабат чыгам. Карасам, Сара Садыйкова җил-җил атлап килде дә очып кына сәхнәгә менде. Кулында – теге безне шаккаттырган ак чәчәкләр! Чәчәкләрне миңа биреп, үземне кочаклап ук алды.

– Шәп җырладың, сеңлем!

Мине җитәкләп, сәхнә артына алып чыкты, утырыштык.

Сара апа шундый гади, нәкъ менә дус кызы белән сөйләшәмени! Минем кайда укуым белән кызыксынды, киңәшләрен дә бирде.

– Бу җырны җырлаганда, соңгы куплетны үзгәртерсең, яме, – ди.

– Ничек инде?

– Менә шулай! Шигырьнең соңгы куплеты миңа ошамый.

Сара апа дәвам итә:

– Мин Равил Фәйзуллинның үзенә дә бу турыда әйттем. Ул да килеште. Без аны үзгәртергә булдык. Менә болай итеп:

Мин сине ничек яраттым!
Киттең читкә. Көтмәдең.
Мин дә яратам, диеп ул чакта
Ник, иркәм, миңа хәбәр итмәдең?

Шәп бит! Шулай итеп җырларсың, яме!

...Чынлап та, шәп бит! Сара апабыз нинди сизгер, шигъри җанлы композитор булган икән лә!

Бу җыр концертларда Ринат белән минем дуэтка әверелде. Ә өч ел узгач, без аны үзебезнең туйда да кат-кат башкардык.

Соңрак радио-телевизордан «Мин сине ничек яраттым» җыры ишетелсә, «Әнә – безнең җыр!» – дип әйтү гадәткә керде.

...Бу вакыйгага кырык еллап вакыт үтеп тә киткән. Ә җыр һаман да – безнеке!

Балаларыбыз да еш кына телефоннан шалтыратып:

– Әти! Әни! Телевизорны ачыгыз! Сезнең җырны җырлыйлар! – диләр.

Без, яшьлегебезгә кире кайткандай, җырга кушылабыз:

...Мин сине ничек яраттым! –
Мәктәп юллары белә...

PRESSA.RU



БИШЕНЧЕ КЫЙТГАДА

КАРШЫМДА АЯНЫЧЛЫ ЯЗМЫШЛЫ, ӘБИ-БАБАЛАРЫ ТУМЫШЛАРЫ БЕЛӘН ТАТАРСТАН, БАШКОРТСТАН ЯКЛАРЫННАН БУЛЫП, ЯЗМЫШ ҖИЛЛӘРЕ АЛАРНЫ КЫТАЙ, ХАРБИН, ТӨРКИЯ ЯКЛАРЫНА ТАШЛАГАН МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕМ...



Рәзинә ИСМӘГЫЙЛЕВА

Австралиянең Аделаида шәһәрендә яшәүче татарлар – «Татар-Башкорт җәмгыяте» әгъзалары, бигрәк тә күптәнге дустым Сафия: «Чакыру җибәрәбез, әйдә, кил», – дигәч, уйга калдым. Чыннан да, моңарчы йә вакыты, йә акчасы юк иде, балалар кечкенә... мәшәкатьләр чыгып тора... Ә хәзер... хәзер нәрсә комачаулый соң миңа?! Күңелемне ымсындырып, иксез-чиксез зәңгәр дәрья – океан, гомеремдә күрмәгән көнгерәләр күз алдыма килә... «Барырга кирәк!» – дигән ныклы бер карарга килеп, юлга җыена башладым – виза ясату эшенә керештем, визам булмаган килеш билетлар сатып алдым...

Ниһаять, Аллага тапшырып, юлга кузгалдым. Казаннан – Мәскәүгә, Мәскәүдән – Дубайга, Дубайдан Австралиянең Аделаида шәһәренә ике көн дигәндә очып килеп тә җиттем. Казанымның язгы иртәсендә чыгып киткән булсам, көзге Аделаида төне каршы алды. Сагынып көтеп торучылар булганда күзгә төн карасы күренәмени! Әнә алар, якын дусларым – биредә яшәүче милләттәшләр – Гайшә һәм Зыя Маскилар, Сафия Вәлиефф...

■ Аделаида шәһәре океан өслегеннән 50 метр югарылыкта, Сент-Винсент култыгы белән Маунт-Лофти тау итәге арасында урнашкан. Иң элек бирегә инглиз капитаны Гиндмарш диннәрен яклаган өчен сөрелгән 200 ләп британлы белән килеп урнаша. 1836 елның 28 декабрендә шәһәргә нигез салына, һәм аңа 1830–1836 елларда патшалык иткән Англия короле Вильгельм IV хатыны Аделаида хөрмәтенә исем бирелә. Полковник Уильям Лайт та шәһәргә нигез салучыларның берсе була: Торренс елгасы буенда урынын сайлый, шәһәрнең планын төзи. Лайт урамнарны рәшәткә формасында ясый, шуңа да шәһәр киң бульварлардан, иркен мәйданнардан тора. Британлылар килеп урнашканчы биредә җирле Каурн кабиләләре яшәгән. Әлеге кабиләләр тирә-як урманнарны янгыннан саклаучы уникаль йолалар башкарган. Әмма европалылар килеп урнашкач, аборигеннарны бу җирләрдән кысрыклап чыгарганнар. 1852 елда инде аларның саны нибары 650 кеше генә калган. Бүгенге көндә Аделаида – Көньяк Австралиянең иң зур шәһәрләренең берсе. Биредә 1 миллион 200 дән артык кеше яши.



■ Әл-Хәлил мәчете.

...Колакка ят та, шул ук вакытта рәхәт тә итеп сайраучы кошлар тавышына уянып киттем. Аделаидадагы беренче иртәм. Тәрәзәдән күкне күзәтәм – аяз, кояшлы көн. Җылы булырга охшап тора... Ә өйдә салкынча. «Бераз суытты шул, 24 кә төште, киенеп йөр», – дип, Сафия миңа җылы кофта суза. Өй эчендә салкынча булса да, Австралия календаре көзгә кереп барса да, урамда әле җәй икән бит!.. Кояш кыздыра. Кошлар сайрый, клумбалар аллы-гөлле чәчәктә утыра, анар, инжир, зәйтүн, лимон, кактус агачлары җимешкә күмелгән. Күк ап-аяз... Ап-ак юл калдырып әле бер, әле икенче самолет очып үтә. «Әһә-һәәәй! Мин монда! Мин Казаннан килдем!» – дип кулларымны болгыйм. Күрә димени инде ул?.. Ишетми дә... Көзге кояш нурлары астында иркәләнеп, җылынып өйгә кердем. Салкынча... Ничек кышлый икән болар монда?

– Кондиционер кабызабыз, бүлмәдән бүлмәгә электр белән җылытыла торган батареялар йөртәбез. Кышның иң салкынында да температура 14-15 градус җылылыктан төшми. Ел әйләнәсендә җәй бездә – үсемлекләр, агачлар чәчәк ата, җимеш бирә. Агачлар да яфракларын коймый, гел яшел тора, – ди Сафия.

Уйгыр икмәге – нанга Аделаида каймагы ягып, сыр белән тәмләп сөтле чәебезне эчтек тә, Аделаида белән танышыр өчен шәһәр үзәгендәге зур паркка кузгалдык. Сафия рульдә. Тәҗрибәсе зур, «Тойота-Королла»сы хуҗасына буйсынып, җилдәй җитез «йөгерә». Андасанда маршрут автобуслары үтә. Әмма тукталышларда автобус көтүчеләр дә, автобусларның туктап кеше утыртканы да күренми.

– Автобуслар бар, алар 15 минут саен йөреп тора, әмма шәһәр халкы үз машинасында йөрергә тырыша, югыйсә эшкә җитешмәскә, барасы җиренә баралмаска мөмкин... – ди Сафия.

Шәһәр дигәч, күп катлы йортлар, сәүдә үзәкләре күз алдына килә. Ә монда кызык икән, инде бер 15-20 минутлап барабыздыр, ни кибете күренми, ни күп катлы йортлары... Шәхси йортлардан торган зууу-ур шәһәр икән бит бу ләбаса! Йортларның күбесе бер катлы... Ике катлылары яңарак кына салына башлаган. Күп катлы биналар шәһәрнең үзәгендә генә икән. Аларда – отельләр, банклар, офислар, сәүдә үзәкләре урнашкан. Шәһәр үзәген без барасы парк һәм Торренс елгасы әйләндереп алган.

Татар мәктәбе төрле рәсми чараларда катнашып, милләтебез данын бөтен Австралиягә тарата.

Акрын гына үз көенә Торренс елгасы ага... Үрдәкләр, аккошлар, башка кошлар су коена. Әле бер, әле икенче якка су трамвайлары йөреп тора... Яшьләрнең бер ишесе чирәмгә утырып чөкердәшсә, икенчеләре сәламәт яшәү рәвешен сайлаган – парк буйлап велосипедта җилдерә... Менә кайда ул җәннәт! Мин дә тәэсирләнеп тирә-якны күзәтәм. Колониаль стильдә салынган уникаль биналар, заманча биналар белән бергә үрелеп, гаҗәеп бер гүзәл гармония тудыралар. Хөкүмәт йорты, Парламент, Аделаида фестиваль үзәге (спектакльләр, концертлар куела), өч Университет (Аделаида университеты, Көньяк Австралия университеты һәм Флиндерс университеты), консерватория, Австралиянең иммигра-

PRESSA.RU



■ Наил абыйның нәсел тамырлары Казанга барып тоташа. Бабасы Көнбатыш Кытайга сәүдә юлын ачкан татарларның берсе була. Колҗада беренче татар мәктәбен салдыручы да, Казан якларыннан башка татарларны Кытайга алдыручы да ул була.
– Казанда бабамнарның ике катлы йорты әле дә исән. Ситдыйк бабам станция саен атларын алыштыра-алыштыра, ямчылар белән өч тапкыр туган ягына, туганнары белән күрешергә дип Казанга кайтып килә. Соңгы күрешүе 1900 елда була.

ция музее (1986 елда ачылган), эчендә 35000 нән артык картина саклананган Көньяк Австралия сәнгать галереясы да елга буенда, парк әйләнәсендә урнашкан.

...Шактый арып, әмма канәгатьләнү хисе белән өйгә кайтып кергәндә инде күптән караңгы төшкән, кошлар да сайравыннан туктаган, Сафиянең кояш нурларыннан энергия җыйган фонарьлары гына берсеннән-берсе яктырак балкып, безне көтәләр иде...

Улларын, кызларын үзебезнең милләт – мөселман баласына ярәштерү дә бик мөһим монда.

Татарларым

Аделаида шәһәрендә яшәүче татарлар белән танышу «Тарым» («комлы дала» мәгънәсендә) уйгыр ресторанында башланды. Аш табыны нәкъ үзебездәгечә, Коръән сүзе белән башланып китте. Аннары өстәлгә бер-бер артлы минем күзгә ят булган ризыклар чыгара башладылар. Уйгыр ризыклары – кавап, тофу салаты, куырдак, лагман... Бераз борычлырак тоелса да, үзгә тәмле, туклыклы иде алар. Пылау, пилмән, ит белән бәрәңге шулпасы, манты – аеруча якын, үзебезнең ризыкларны хәтерләтте. Чәй янына да үзебездәгечә, һәр кешегә өлешләп, чәкчәген, катлы-катлы тортын, баллы прәнкәсен, абрикос кайнатмасыннан ясалган бәлешен бүлеп чыгардылар.

Табындагы ризыклар тәмле-татлы булса да, аралашу кыйммәтрәк: янәшәмдә утырган татарларым белән кызыксынам... Рәйсә апа Шәрипова Казакъстан якларыннан, Алматы шәһәреннән күчеп килгән. Илхан, Рөстәм, Раиф, Наилә Садрилар, Кинҗә һәм Наил Габитовлар, Сания Вәлиефф – Шәркый Төркестаннан, Голҗа шәһәреннән, Зыя Маски – Төркиядән, Сафия, Гайшә, Мөшәррәф, Фирдәвес, Сөенгөл, Зәкия, Садыйк, Әхмәт, Риза Вәлиеффләр – шулай ук Шәркый Төркестанның башкаласы Өремче шәһәреннән...

Наил абый Габитовның язмышы мине аеруча тетрәндерде. 1962 ел. Наил Габитовның тәрҗемәче булып, Голҗадагы СССР консуллыгында эшләп йөргән еллары. Кытай белән СССР арасында дуслык җепләре өзелгәч, аны совет шпионы дип, 18 елга ирегеннән мәхрүм итәләр. 15 ел – Голҗа шәһәрендә, 3 ел Өремчедә утыра.

– Бер кешелек камерада яттым. Елына 5-6 мәртәбә генә, уннан дүрткә кадәр һавага алып чыга иделәр. Һава торышы начар булса, анысы да эләкми... Ачка үлмәслек кенә ашаталар – кукуруз онынннан парда пешерелгән кытай икмәге бирәләр. Ничек түздемме? Дингә биреллдем. Намазга бастым. Төрмәнең таш диварларына гыйбадәт кылдым... Шашмаудан, сынмаудан Аллаһы Тәгалә коткарды, – ди Наил абый.

Тешен кысып түзә ул. Түзмичә, төрмә сакчыларына: «Ни өчен судсыз, нахакка төрмәдә тотасыз, фашистлар?» – дип ачыргаланып кычкырган чаклары да була. Шуның өчен ике ел битен юарга да сусыз тилмерә. Тиф авыруыннан ай дәвамында авырып, чак исән кала... Кытай төрмәсе Наил абыйны тома ятим итә – туганнары белән аралар өзелә. Чөнки «совет шпионы» белән хәбәрләшергә, хатлар язышырга, янына килеп йөрергә рөхсәт булмый. 1963 елда әниләре Шәкүрә, төрмәгә утыртуларыннан куркып, барлык балалары белән, 20 бүлмәле өен калдырып, Бишкәккә күченә.

– Әниемне, туганнарымны төрмәдән чыккач та озак күрә алмадым әле. Торырга урын юк, эш таба алмый интектем, ниһаять, өч көлчә алырлык хезмәт хакына цемент заводына эшкә урнаша алдым. Мин яши торган йорттан ерак түгел бер өйдә Харбиннан күчеп килгән татарлар тора башлады. Көн дә алар өе яныннан үтеп эшкә йөрим. Күрәм, яшь кенә, чибәр генә Кинҗә исемле кызлары да бар. Шулай бер көнне аның белән танышып киттек. Дуслаштык. 1985 елда алар гаиләләре белән Австралиягә күченделәр. 1987 елда Кинҗә мине дә чакырып алды. Шулай итеп гаилә корып яши башладык. Бер-бер артлы балаларыбыз – Илгизәр белән Гөлгенә туды. Төрмәдән чыкканга да 12 ел тулып китте. Газиз әниемне 30 ел күрмәдем. Хатынымны, балаларымны алып, газиз әнием янына – Бишкәккә киттем... «Әнием, әнием...» дип елый-елый, тезләнеп кердем янына, кердем дә башымны тезләренә салдым... – дип искә төшерә Наил абый ул елларны.

Якшәмбе мәктәбе

Аделаидада яшәүче дусларым аша биредә Якшәмбе мәктәбе барлыгын беләм. Мәктәп турында сүз чыкканда алар олы рәхмәтләр белән мәрхүм Газраил Габитовны һәм Сөенгөл Чанышеваны искә төшерәләр. Сөенгөл апа Чанышева биредә яшәүче татар, уйгыр, үзбәк балалары телләрен, диннәрен онытмасын, милләтләрен югалтмасын өчен 1982 елда үз өендә Якшәмбе мәктәбе ача. Шәркый Төркестанның Голҗа шәһәреннән өч кызы белән беренчеләрдән булып

Австралиягә күченгән ачык, җор күңелле, биюгә, җырга, шахмат уйнарга маһир Газраил Габитов исә этник мәктәпләр барлыгын белешә. Аның тырышлыгы белән 1986 елда Татар мәктәбе дә Көньяк Австралия хөкүмәтенең «Этник мәктәпләр ассоциациясе»ндә теркәлүгә, хөкүмәттән ярдәм алуга ирешә.

Татар мәктәбен 34 ел дәвамында Мөшәррәф Вәлиефф җитәкли. Аделаидада яшәүче татар балаларына чирек гасырдан артык Гайшә Маски белем бирә. Җәмәгать эшләрендә актив катнашкан, татар-башкорт этник мәктәбендә хезмәт күрсәткән укытучы Көньяк Австралия хөкүмәте бүләгенә дә лаек булган. (Шәркый Төркестанның башкаласы Өремче шәһәрендә, Фатыйма һәм Салих Вәлиеффләрнең зур гаиләсендә үскән ханымнар болар. Тугыз баланың һәрберсе кебек милли җанлы, зыялы затлар. Әби-бабалары Апас, Кукмара төбәкләреннән булып, заманында Кытайга күчеп китеп урнашкан. Тормышның ачысын-төчесен татыган, Кытай сәясәтләре, «Мәдәният инкыйлабы» аша үткән гыйбрәтле язмышлы Вәлиеффләр гаиләсе 1981 елда Австралиянең Аделаида шәһәренә килеп төпләнә.) Сания, Гүзәл, Гөлфия, Диләрә Вәлиеффләр дә башка милләтләр арасында татар балалары югалып калмасын, телләрен, диннәрен онытмасын дип тырышалар. Бүгенге көндә Аделаидада туган яңа буын татар балалары – Кәрим, Латыйфа, Фәдилә, Дилназ, Фирүзә, Тәнзилә, Фирдәвес, Фатих, Шакирә, Хафиз, Җәннәтләр үсеп килә.

– Мәктәбебездә 30-40 ар бала укыган еллар булды. Аннан 20 гә, хәзер 10 га калды. Мәктәптә татар җырлары, биюләре өйрәнәбез, Туган тел, Тукай көннәре уздырабыз, татар әлифбасы буенча кириллицада язарга, укырга өйрәтәбез. Атнасына өч сәгать укытабыз, дәресләрдә балалар белән бергә әти-әниләр дә катнаша, – ди Гайшә ханым.

Килен-кияүләрне күбрәк Татарстаннан алырга тырышалар. Килен булып киткән Казан кызлары Гүзәл, Диләрә, Айсылулар – шундыйлардан.

Татар-башкорт җәмгыяте

Әлбәттә, Якшәмбе мәктәбе ачкандай, татар милләтен берләштереп торучы бер оешма булдырмасаң, күп милләтле Австралия җирлегендә 300-400 татар югалып та калган булыр иде. Әмма 1991 елда Аделаида каласында «Татар-башкорт җәмгыяте» төзелеп, Австралия хөкүмәте аңа рәсми таныклык сертификаты да бирә. Унбиш еллап аның башында Зыя Маски тора, соңгы ун елда җәмгыятьне Шөһрәт Вәлиефф җитәкли. Әлеге җәмгыять Австралиядә яшәүче татарлар арасында күп эшләр алып бара, изге гамәлләр кыла, аларны бөтен дөньяга таныта.

1997 елдан бирле Аделаида шәһәрендә милли бәйрәмебез – Сабан туе да уздырыла. Бәйрәмгә кунак булып, елның-елында Көньяк Австралия хөкүмәте вәкилләре генә түгел, Татарстанның, Башкортстанның хөкүмәт вәкилләре, артистлары да чакырыла. Быелгы Сабантуйга композитор Фәнир Галимов, җырчы Марат Шәрипов, «Зөләйлә» төркеме кызлары да килде.



■ Австралиядә туган балалар, яшьләр әти-әниләренә «әннә», «әттә», «сез» дип эндәшүләрен, саф татар телендәге җыр-биюләрен, чит-ят җирдә тырышып-тырмашып яшәүләрен, Австралия халкы арасында татарларны бары тик яхшы яктан танытуларын күрү – минем өчен бер горурлык булды.



Гаҗәп! Милли киемле хатын-кызлар, ир-егетләр уйный-көлә, бии-җырлый, өстәлләр милли ашлардан сыгылып тора!

Уеннарын күзәтәм – нәкъ бездәгечә... Әнә әле балалар, әле ханымнар көянтә-чиләк белән су ташыйлар. Кашык белән күкәй кабып, капчык киеп йөгерәләр. Капчык бәреш, аркан тартыш уеннары да бездәгечә... Әһә, ике баһадир уены безнекенә охшамаган лабаса... Мәйдан уртасында ике егет, өрдерелгән киемнәр киеп, бер-берсен, татар көрәшендәгечә, күтәреп салырга маташа... Алай тиз генә бирешә димени инде Алып батырлар?! Юк, әлбәттә, бер-берсенә якынаюга кабырчыгына яшеренгән ташбака сыман, башларын киемнәре эченә яшерәләр дә тәгәрәп китәләр...

Тәрбияне балаларга гаиләдә бирергә тырышалар.

Күпме көткән Сабан туе да узып китте. Без дә София белән өйгә җыенабыз. Арытты, әмма күңелебездә – канәгатьләнү хисе. Күрәм, килгән кунаклар – татарлар, уйгырлар, үзбәкләр, руслар, украиннар да теләр-теләмәс кенә өйләренә таралыша. Милләтләре, диннәре төрле булса да, язмышлары бер шул аларның. Шуңадыр, күрешкәч, сөйләшер сүзләре, фикерләре бетми.

Көнгерәләр иле

– Көннәр җылы, кояшлы торганда океанга барыйк, – ди София.

– Бүген эссе, – дим. – Коенып та булмасмы икән?!

– Карарбыз, кояшлы булса да, җиле булыр анда...

Чыннан да, чыдап булмаслык эссе көн океан буенда түзеп булмаслык җилле көнгә алмашынды да куйды.

– Гаҗәпләнмә, океан буенда җәйге кызу көндә дә шулай. Агым көчле булганга, суы да салкын. Җәен дә суның җылылыгы 18-20 градус кына була, ә кышын 15 градустан артмый, – ди София.

PRESSA.RU







■ Йөз еллык фикус агачы.

■ Коалалар ботакка аякларын салындырып утырганнар да, агач кәүсәсен кочаклап, сабый баладай рәхәтләнеп изрәп йокыга талганнар...

Коенып булмады, әмма тозлы суында аякларны чылата-чылата ап-ак комлы океан ярында рәхәтләнеп йөреп, күңел булганчы фотосурәтләр ясап, кайтыр юлга кузгалдык. Дөресрәге, көннең яртысын әрәм итмичә, ботаник бакчага да сугылырга булдык. Әлеге бакчага 1857 елда ук нигез салынган икән. Мәйданы да шактый – 34 гектар. Биредә бөтен җир шарында үсә торган үсемлекләр бар, хәтта кайберләренә 200 әр ел икән. 100 еллык фикус агачының тамырлары минем буйлык.

Тәэсирләнеп йөри торгач, төрле-төрле агачлар, куаклар әйләндереп алган күлгә килеп чыктык. Менә кайда икән оҗмах! Кошлар сайрый, күл өсте көмешсу төскә кереп уйнаклый, суында үрдәге, ташбакасы, балыгы йөзә, кошлары коена... Гаҗәп! Кечкенә генә күлгә барысы да сыеша.

Менә кайда икән чып-чын татар Сабан туе!

Санаулы көннәр тиз уза. Әмма Австралиягә килеп, кәнгерәләр күрми китеп булмас... Иртәгәсен кәнгерәләр белән дуслашасы, вомбатлар, эму тәвәләрен, динго этләрен күрәсе, коалаларны кочаклап карыйсы килү теләге белән шәһәрнең иң биек ноктасы булган Лофти тавына (727 метр!) – Клеланд кыргый табигать тыюлыгына кузгалдык. «Гид»ыбыз булып йөрергә Сафияләрнең кияүләре Рамил Садри алынды. Куе эвкалипт урманын урталай ярып салынган юлдан өскә үрмәлибез. Шактый ерак. Өскә күтәрелгәнгәме колак тона. Әмма һавасы шәп! Бер яктан – тау һавасы, икенче яктан эвкалипт агачының исе...

Тыюлыкта безне күселәр каршы алды. Әйе, әйе нәкъ менә күселәр. Кәнгерәләрнең бер төре икән. Табигатьтә кәнгерәләрнең 69 төре очрый. Без күргәне – иң кечкенәсе валлаби дип атала икән. Авырлыклары да төрлечә – 500 граммнан 90 килограммга җитә. Тыюлык буйлап йөри торгач, төрлесен очраттык. Кешеләргә карата дустанә мөнәсәбәттә тагын үзләре – сыйпаттыралар, килеп кулдан ашап та китәләр, безнең белән рәхәтләнеп фоторәсемгә төшәләр...

– Әнә, тегеләре кызыл кәнгерәләр. Аларына якын бармасак та була... Иң зурлары безнең буйлык, авырлыклары да 90 шар килограммга җитә, – дип кисәтә безне Рамил.

– Ярый, – дибез, – коалаларны да күрсәк...

– Карап үтик, әмма алар эвкалипт яфракларын ашыйлар да «кәефләнеп» көндезен йоклыйлар, – ди «гид»ыбыз.

Кайтыр юлга кузгалдык, әмма хәлем эвкалипт ашап кәефләнеп йоклап яткан коаладан бер дә ким түгел. Түзеп булмый, йокы баса... Йокламаска тырышып, үземне ирексезләп, Сафия белән сөйләнгәләп кайтам. Без ярар, менә машина йөртүче Рамил ничек түзә икән?

– Йокыгыз килмиме? – дим, аның өчен борчылып.

– Юк, – ди Рамил, – без күнеккән инде. Эвкалипт исе исерткән үзегезне, ә...

Сау бул, Австралия!

Австралиядәге соңгы кичемне фикерләремне туплап, алган тәэсирләремне тәртипкә китереп, океан белән күзгә-күз карашып уздырырга уйладым. Әңгер-меңгер. Кояшның болытлар арасына кереп барышы, шәфәкъ батышы. Сүнәм-сүнәм дип утырган күк учагы океан астыннан килеп чыкмасынмы... Океанга ут капты.

Уйларыма чумып, табигатьнең искитмәле манзарасын күзәтәм. Җирнең нәкъ капма-каршы ягында (7 сәгать аерма!) минем туган илем, балаларым, туганнарым. Сагындым барысын да! Әмма шуны беләм: өйгә кайтуга мондагы дусларым, милләттәшләрем дә сагындырачак. Килерменме тагын бу якларга, җыяр ризыкларым биредә калгандырмы, белмим? Туган илләрен югалтсалар да, телләрен, диннәрен, гореф-гадәтләрен саклап яшәүче милләттәшләрем белән горурланып, үз тирәлегемдәге татарларыма бу хакта кат-кат сөйләрмен әле.



ӘХМӘДУЛЛИНА Нигина

Ташкент дәүләт милли бию һәм хореография югары мәктәбе; Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты.

Кияүдә түгел.

Карьера: «Казан» бию ансамбленең хореография студиясе; Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназия укытучысы.

Тормыш шигаре: «Мин татарча сөйләшәм – киләчәкне үзгәртәм».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Җәйнең яме – җиләк икән!

Мин Ташкентта, җиләк-җимеш арасында үстем. Әмма үземнең, Казанга күчеп кайтканыма биш ел булса да, җир җиләге җыеп караганым юк иде. Вакыт табарга, урынын белергә кирәк бит. Уфадан күчтәнәчкә гел җир җиләге кайнатмасы җибәрүче апам: «Болында бер урынга утырасың да, чиләгең тулмыйча кузгалмыйсың» – дип сөйли иде. Быел минем бу хыялым чынга ашты! Ошады җиләк җыю! Башың, күңелең, җаның өчен ял икән ул. Тирә-юньдә тынлык, һавада җәй исе, учыңда мөлдерәп пешкән җиләк...


Дөньяга танылуның бер юлы бу!


Киләсе елдан Россия банкы 200 һәм 2000 мең сумлык яңа акчалар чыгара башларга җыена. Яңа купюраларның дизайны әле тәгаенләнмәгән.
Әлегә тавыш бирү бара. Акчаларда Казан шәһәре сурәте дә була ала.
Бу хакта белүгә тиз генә тавыш бирдем, дусларыма да хәбәр иттем. Казан турында тагын да күбрәк белдерәсе килә! Әлегә бәйгедә Сочи, Түбән Новгородны артта калдырып, Волгоград алда бара. Августка кадәр вакыт бар әле!

Иксез-чиксез Галәм бит ул!


Мине нигәдер гел космос белән бәйле яңалыклар кызыксындыра. Галимнәр астрономиядә яңа эра башланды дип игълан иттеләр менә. Ерак бер галактикада кислород барын ачыклады инде алар. Ниһаять, Плутонга «барып җиттеләр»... Иксез-чиксез Галәмдә үзебез генә булуга күңел ышанмый: берәр цивилизация белән барыбер очрашырбыз кебек. Кешеләр җирдә гел нидер бүлешә алмый, ә алар безгә үрнәк күрсәтер кебек...

сөендерде






көендерде




сөендерде







көендерде




сөендерде





көендерде



Закон бозмыйм дисәң...

Балалар белән Мәскәүгә бию фестиваленә бардык: 8 яшьлек 12 кыз һәм 12 малай. Һәммәбез – балалар, әтиәниләр бер вагонда булу өчен, «Роспотребнадзор» кагыйдәләренә туры китереп, өстәп акча түләдек. Билетларны кулга алгач, шаккаттым: балалар 7 нче вагонда, без, өлкәннәр, 10 нчы вагонда кайтачакбыз! Төнге 12 дә, платформа буенча чабып, поезд начальнигын таптым, урыннарны алыштырырга көчкә ризалаттым. Иҗат бәйгесендә җиңеп була, ә менә мәгънәсез гамәлләрне җиңү шундый авыр...

Булганны юкка чыгаруы тиз ул...

Рамазан ае узып китте. Ифтарлары белән истә калды ул. Яшьләр өчен Горький паркында – ачык һавада аерым ифтар оештырдык. Интернет челтәрләре аша гына хәбәр салдык – йөз егермеләп кеше җыелды. Һәркемгә ланч-бокс, пылау, кайнар чәй тараттык. Соңгы айда шушы ифтарларда әллә никадәр дустымны күреп өлгердем, рәхәтләнеп аралаштык. Үзебезне зур бер гаилә кебек тойдык. Федерация Шурасы кабул иткән «Яровая кануннары» барысына да киртә салыр да, киләсе елга болар инде берсе дә булмасмы?


Язган булмасын...

Үзең белгән кешеләргә килеп кагылганда, хәсрәтне бөтенләй башкача кабул итәсең... Истанбул аэропортында булган терактан соң, «анда Татарстан балалары да калган» дигән хәбәр чыккач, бөтен дөньяга таралып яшәгән туганнарым шалтырата башлады. «Син кайда, хәлең ничек?» – диләр. Балалар белән еш кына юлда йөрүемне беләләр. Чаллының «Бисеринка» бию коллективы өчен үзем дә бик борчылдым шул.

PRESSA.RU

16+

ГАИЛӘ СУГЫШ КЫРЫ ТҮГЕЛ


Фото: Николай Галкин

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

Шамил ИДИЯТУЛЛИН, журналист һәм язучы, «Коммерсантъ» газетасының (Мәскәү) региональ редакция бүлеге җитәкчесе;
өйләнгән;
гаилә стажы – 23 ел;
улы Нурисламга – 22;
кызы Динәгә 15 яшь.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Кешеләрне беркайчан да киеменә карап кына кабул иткәнем булмады. Һәр ир-атны – көндәш, һәр хатын-кызны булачак тормыш юлдашы итеп күз алдына китергән яшьтән дә сизелми генә үтеп кителгән... Миңа хәзер кешедә (ир-ат булсынмы ул, хатын-кызмы) башка нәрсәләр мөһим: аның ничек фикер йөртүе, эшләве, сөйләшүе, башкаларга мөнәсәбәте... Мине күбрәк шулар сөендерә. Ә хатын-кыз әле күзеңне дә иркәли икән – монысы инде чынлап та бәхет.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Чамадан чыкмаганда – барысын да... Хәер, бик якын кешеңне нинди очракта да гафу итеп буладыр. Шуның өчен дә якын кеше бит ул.

Хатынымның бер гадәте бар: кулына китап эләксә, соңгы битен япмыйча куймый ул аны. Ә күңеленә хуш килгән фильмны көнгә өчәр тапкыр ай буе да карый ала! Юк, минем дә, балаларның да ачуын китерми бу гадәте, күптән ияләштек. Калын-калын, кызык-кызык китапларны кичтән әниебездән яшерергә дә өйрәндек инде: югыйсә ул төне буе утырачак – йә укып бетереп туктаячак, йә, будильник шалтыравын ишеткәч, китабын, авыр сулап, читкә куячак та, иртәнге аш әзерләргә чыгачак. Бер үк фильмны берөзлексез әйләндерүе белән исә килешми чарабыз юк: бу очракта икенче юлы аның күңеленә алты өлештән торган сериал түгел, ә нинди дә булса кыскарак фильм хуш килүен теләргә генә кала.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм аңа өйдә комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Боларны бер-берсеннән аерып карап булмый: үлчәү тәлинкәсе бер якка авыша төшсә, икенче як «ярлылана». Аш-су әзерләп гаиләсен сыйлый алмаган алиһәне ялгызлык көтә. Үз матурлыгы, күркәм төс-кыяфәтенә караганда өйдәгеләрнең тамак туклыгы мөһимрәк дип санаган хатын-кыз да күпне югалта – үзен алиһәдән хуҗабикә дәрәҗәсенә төшерә дә куя.

Бу яктан минем үземнең бәхетем булды: инде менә чирек гасырга якын чибәр, акыллы һәм бик уңган хатын-кыз белән яшим – ул пешерсә, хәтта бөтенләй яратмаган шул кәбестәне дә ашыйм.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә, була ала. Ниндидер бер уртак кызыксынуларны берләштергән «түгәрәк»тә генә очрашу түгел бит бу, гомерлеккә дип төзелгән гаиләдә яшәү.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Барысы да бик гади, үзеннән-үзе килеп чыкты безнең. Казан дәүләт университетының журналистика факультетында, бер группада укыдык, бер үк тулай торакта тордык. Берсендә аның бүлмәсе булган катка кемгәдер кунакка кердем. Кызлар бәрәңге кыздыралар иде – табынга мине дә чакырдылар. Чит шәһәрдән килеп укучы студент егет мондый сыйдан баш тартамы?! Өстәл янында без аның белән сөйләшеп киттек. Беренче тапкыр! Шуннан соң алар бүлмәсенә керүләрем ешайды инде. Шулай башланды... Бер елдан соң без бергә яши башладык, университетны тәмамладык, улыбыз туды. «Без бит әле язылышмаган!» – диган уй башка кергәнче тагын берничә ел узып китте. Никахны теркәгәндә шаһитлар булырга ризалашкан дусларыбызны алып, Загска киттек. «Тизрәк, тизрәк, өйдә балалар көтә!» – дип, гел шулай ашыктыруыбыз Загс хезмәткәрләрен шактый гаҗәпләндерде бугай.

Без туйлар ясап тормадык. Тормышымдагы иң зур гөнаһым, ялгышым шушы бугай... Мин моны әле күптән түгел генә аңладым. Аңарчы гел: «Ярый ул ыгы-зыгыларны урап уздык!» – дип куана идем. Рәисәнең ялгыш та бу фикеремнең дөрес түгеллеген сиздергәне булмады.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый...

– Бу күренеш, әлбәттә, киң таралган. Әмма, беренчедән, кеше – машина түгел, аерым бер образ аңа программа итеп салынмаган. Икенчедән, белгәнебезчә, никахлар күктә укыла: берәүнең үзенә тиң булган ярын, бердәнберен ничекләр итеп эзләп табуы бары Ходайга гына мәгълүм.

7 Гашыйк булуын хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Мин монда бернинди дә криминал күрмим. Әмма, минемчә, акыллы хатын-кыз бу хакта ир-ат үзе әйтсен һәм, алай гына түгел, бу аның үз фикере дип ышансын өчен мең дә бер ысулын табачак.

8 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

Монысы – аның яшенә бәйләнгән. Яшүсмер чакта – матурлык һәм көч булса, буй җиткәч – көч һәм акыл җәлеп итә, ә тормыш күргән хатын-кыз иң элек ир-атка ышанычлымы-түгелме, дип карый. Бу минем күзаллавым гына, бу хакта ул – хатын-кыз үзе генә белә. Белсә әле?!

9 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Мин инде яшь кеше түгел, башлы-күзле булганыма да байтак, шуңа күрә якыннарымны кайсы ягым соклandыруын азмы-күпме чамалыйм. Дөрес, кайвакыт ир-атның сәеррәк мавыгуларына, шатлыкларына игътибарлырак булуларын телисе килә килүен... Әмма ир-атка да, хатын-кызга да бер үк нәрсәләр охшаган очракта безнең дөнья бертөслегә әйләнер иде шул. Ә бу күңелсез!

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Ярый, менә бер мисал. Мәскәүдә терактлар булу куркынычы турындагы чираттагы игъланнан соң хатыным: «Башка беркайчан да метрода йөрмәячәкмен!» – диде. Аннан, әлбәттә, метрода барырга ризалашты инде, әмма: «Танырга җиңелрәк булыр», – дип, әфлисун төсендәге ачык кием киде. Эштә бу хакта сөйләгәч, хезмәттәшләремнең берсе – хатын-кыз – «Самолетта ничә ел очам, очкыч җирдән күтәрелер алдыннан һәрвакыт документымны джинсы чалбарның арткы кесәсенә тыгам», – дип шаккаттырды. Имеш, ул-бу килеп чыкса, урындыкка орынып торган җир азрак яначак һәм, әлеге дә баягы: «Танырга җиңелрәк булачак». Без, ир-атлар, мондый идеяне тормышка ашыру түгел, уйлап та чыгара алмыйбыз.

Тагын бер тарих. Хатыным – ЦСКА баскетбол клубының җанатары. Аның туган көне 6 майда. Бер елны без аңа Парижга юллама бүләк иттек: ЦСКА анда чыгыш ясарга тиеш иде (беренче уеннары – 7 май көнне кичен, өченче урын өчен финал һәм матч – 9 майда). Рәисә башта: «Без Франциягә гаилә белән барырга тиеш!» – дип белдерде. Артык акча юк чак иде, аннан улым белән бер-бер артлы Парижда без яңа булган идек. Ә кызыбызның кулы сынган чак: гипслы килеш аның Елисей кырларында йөрисе дә, Диснейлендка барасы да килеп тормый. Хатыныма, сыкрап булса да, билетны үзенә генә алмый чара калмады. «Син нәрсә! Парижга өч көнгә? Алай булмый! Виза биргәннәр икән, бер атнага бар!» – дип кем генә әйтмәде. Берәүне дә тыңламады: кайтырга билетны 10 майга алды.

9 май көнне ишектә кыңгырау шалтырый. Әниебез кайткан! 7 май көнне ЦСКА җиңелгән икән. Рәисәнең моңа кәефе кырылган, билгеле. Икенче көнне Лувр һәм Монмартрдан Эйфель манарасына кадәр Парижның туристлар өчен иң кызык урыннарын карап чыккан да, кунакханәгә кайтып утырган. Кичен бүлмәсеннән генә такси чакыртып, аэропортка киткән. Билетын алыштырган. Өч минутка гына «дьюти-фри»га кереп шоколадлар алган. Инде очып китәргә әзерләнгән самолетка көчкә өлгергән... «Нигә кайттың?» – дибез. «Салют карарга телидем», – ди. Яраткан командасы җиңелгәнгә үпкәләгән. Чынлыкта – сагынган! Менә шундый инде ул минем...

Тагын хатын-кызларның чәй ясау, йомырка тәбәсе кыздыру, шашлык әзерләү кебек эшләргә бармак аша каравын, өнәп бетермәвен аңламыйм. Әмма бу темага артык керәсем килми, аш-су белән бәйле нинди дер киңәш бирүне кичерми алар.

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Бәхәстә – хакыйкать туа, диләр дә... Белмим шул, күбрәк дошманлык туа бугай. Нинди максат куясың бит: бәхәсләшеп, әңгәмәдәшеңне юкка чыгарырга телисеңме, уртак фикергә килергәме, әллә үз сүзеңне сүз итәргәме. Беренчесе икән, бу инде гаилә түгел, сугыш кыры. Мин берәүгә дә үз фикеремне көчләп тагарга омтылмыйм, бигрәк тә – якыннарыма. Һәркемнең һәрнәрсәгә үз карашы булырга тиеш. Мин исә үз дәлилемне генә җиткерәм.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Безнең гаиләдәме?! Кая ул мине яки балаларны ач тоту, киресенчә, кыстый-кыстый ашатып, маемлатырга мөмкин Рәисә. Әгәр инде кинәт шундый хәл була икән, димәк, хәлләр чыннан да начар – аңа ярдәм итәргә кирәк. Эшебез сигез сәгать белән генә чикләнми безнең, кайчак төн уртасында гына кайтып керәбез. Шуңа күрә хәләл пилмән, «сосиска» запасы суыткычта һәрвакыт бар. Ә ял көннәрендә бик рәхәтләнеп лагман да пешерәм.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Гаилә коргач, кеше иң элек көтәргә һәм түзәргә өйрәнә. Алайга китсә, хатыннар күбрәк көтә һәм күбрәк түзә дә әле.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



Җәй рәхәте дигәннән, күпләребез кояшта кызынуны да, җиләк җыю, печән чабу, су коену кебек, җәйгә генә хас шөгыльләр итеп саный. Күзгә кергәч мактану өчен кайберәүләр тәмам ком гарәбе кебек каралып бетә. Кызыну дигәндә өлкән кешеләр дә яшьләрдән калышмаска тырыша. Бакчасына барып җитүгә өстеннән салып ташлап, рәхәтләнеп кызынып алу җаен карый.

Кояшта яну гына бер хәл. Кояшта пешкән урын да вакыт узуга төзәлер. Ә менә шул зарарсыз кебек тоелган мавыгу сәбәпле, дәвалап булмас чиргә уралсаң, менә монысы инде бәла. Бәланең дә зурысы – меланома дигәне килеп чыкса, сезгә табиблар да ярдәм итә алмаска мөмкин.

Ул бәладән сакланып буламы соң? Онкодерматолог киңәшләрен ОНКОПРОФИ клиникасы белгечләре бирә.

МЕЛАНОМА

Нәрсә соң ул меланома?

Меланома ул меланин матдәсе эшләп чыгара торган күзәнәкләрнең азып китүе. Соңгы берничә дистә елда меланома зәхмәте чамадан ашып китте. Меланома очракларының 70 проценты электән булган миң зарарланганнан азып китә. Калган 30 ы – беренче карашка үзгәрмәгән дә тән тиресендә барлыкка килә. Миңнең азып китүенә берничә сәбәп булып, беренче урында механик зарарлану тора. Әйтик, кырынганда киселү яки һаман кырып торучы кием кию.

Икенче җитди сәбәп – ультрамиләүшә нурларның чамадан тыш тәэсир итүе. Без сүзебезне шуннан башлаган идек тә бит инде. Шуңа күрә башта ук кисәтеп куябыз: тәнегездә миңнәр күп икән, кызынырга ашыкмагыз. Гомумән, кояшта артыгын булырга киңәш ителми. Тән тиресендә, бигрәк тә миңнәрдә берәр төрле үзгәреш күреп алуга, табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Тигезле-тигезсез яки төсен үзгәрткән миңнәр хәтәр.

Шикле миңне озакка сузмыйча алдырырга кирәк. Һәм бу эшне махсус медицина учреждениесендә – онкология өлкәсендә белеме булган хирурглар башкарырга тиеш! Миңне тулаем – янындагы тукымасы белән үк алалар, аннары ул лаборатор тикшерүгә җибәрелә.

Кемгә аеруча сакланырга?

■ Ак тәнле, сары чәчле, зәңгәр күзлеләргә һәм нәселләрендә шундый чир белән авыручылар булганнарга – зыянлы факторларга нәсел факторы да кушылса, куркыныч күпкә арта!

■ Тәнендә миңнәр саны йөздән артып киткәннәргә – бу очракта аларның берәрсенең меланомага әйләнү ихтималы 50 процентка арта.

■ 20 яшькә җиткәнче бер-ике мәртәбә тән тиресе кабарып чыкканчы кояшта яну очраклары булганнарга.

■ Төньяк төбәкләрдә яшәп яки озак еллар шунда эшләп, җылы якка ялга еш бара торган кешеләргә.

■ Солярийларга йөрү белән мавыгучылар шулай ук меланома куркынычын истә тотарга тиешләр.

Бу төркемнәргә кергәннәргә, гомумән, елына бер тапкыр булса да онкодерматологка күренеп алу артык булмас.

Кремнар сөрту саклыймы?

Бик күпләр кызыныр алдыннан кояш нурларыннан саклый торган махсус майлар белән сөртенсәң, шул җитә дип уйлыйлар. Бу хакта табиблар да, фән дә кистереп кенә әйтә алмый. Чөнки тире рагы белән авыручылар саны арта бара. Май сөртенгән кешеләрнең, чарасын күрдек, сакландык дип уйлап, кояш астында озак ятулары сәбәпледер, бәлки. Дөньяда ел саен меланома белән авырып китүче 130 мең кеше теркәлә. Шуның 66 меңе бу чирдән үлеп китә. Узган гасыр уртасындагы белән чагыштырганда, XXI гасыр башына меланома белән авыручылар саны алты тапкырга арткан. Халкы башлыча ак тәнле булган Австралиядә, Яңа Зеландиядә, Төньяк Америкада, Төньяк Европада авыручылар бигрәк тә күп.

Табиблар уйлавынча, кызынганда сөртә торган майлар составына кергән кайбер матдәләр үзләре үк канцероген дип санала. Дөрес, ул майлар кояшта пешүдән саклыйлар, әмма нәтиҗәсе генә ачыкланмаган.

Баланы ничек сакларга?

Табиблар, бала чакта ультрафиолет нурлар күп кабул итү өлкән яшьтә меланома китереп чыгарырга мөмкин, диләр. Бала тиресе бигрәк тә нәфис, а меланин өчен җаваплы күзәнәкләр 2-3 яшьтән соң гына эшли башлый. Кызынганда балаларга махсус крем сөртергә кирәкме соң? Бу киңәшне бирүдән элек, баланы 3 яшькә кадәр кояшта тотмагыз, диясе килә. Фәкать көн сүрелгәч кенә алып чыгыгыз. 3 яшьтән соң кояшта 15 минуттан артык булса, шул җитәр. Кояш нурларыннан саклаучы чаралар кулланган очракта да (аларның бер төре кояш нурларын таратучы һәм этәрүче матдәләрдән, икенчесе нурланышның күзәнәкләргә зыянын киметүче химик фильтрлардан тора) беренче төр – физик фильтрлардан торган – майлы эмульсияләр, ә составында оксибензон һәм октокрилен булмаганнарын сайларга тырышыгыз.

Бу әле диңгезгә бармагыз, комлыкта ятмагыз, дигән сүз түгел. Фәкать чама хисен югалтмагыз.

ОНКОПРОФИ
МЕДИЦИНСКАЯ КЛИНИКА
РЕКЛАМА
ПРОФИЛАКТИКА ОНКОЛОГИЧЕСКИХ ЗАБОЛЕВАНИЙ
● Высококвалифицированная консультация онкодерматолога.
● Удаление родинок, папиллом, бородавок.
● **Ведущие профильные специалисты:**
● Маммолог ● Уролог-онколог, уролог
● Гинеколог, гинеколог-онколог
● Проктолог ● Эндокринолог-онколог
● Хирург-онколог
● ЛОР-онколог, ЛОР ● Невролог
● Терапевт ● Пластический хирург.
● **Кабинет УЗИ экспертного класса.**
● **Лаборатория.**
Казань, Сибирский тракт, 23;
тел.: 8(843) 273-95-03
Часы приема:
пн.-пт. с 8.00 до 20.00;
суббота: с 9.00 до 18.00,
воскресенье – выходной.
www.onkoprofi.ru
Лицензия № ЛО-16-01-003675 от 16.09.2014
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

ЧИСТА ҺӘМ ФАЙДАЛЫ

AqueenaPro
Aqua pura, vita longa
AqueenaPro
Zepter
Только чистая вода –
здоровая вода
Zepter
LIVE BETTER · LIVE LONGER
www.zepter.ru

Сусыз бер генә тереклек иясе дә яши алмый дисәм, яңалык булмас. Баш мие һәм йөрәкнең 73 проценты, үпкәнең – 83, тиренең – 64, мускулларның һәм бөернең 79 проценты судан тора. Хәтта сөякләребезнең дә 31 процентка якын өлеше судан гыйбарәт. Суның күп кенә матдәләрне эретә, юкка чыгара торган уникаль сәләте бар. Күзәнәкләргә кислород ташучы да, гәүдә температурасын көйләп торучы да, матдәләр алмашын көчәйтүче дә шул – су! Өлкән кешенең организмында исә су 60 процентка якын. Балаларда ул күбрәк тә әле. Акыл эшчәнлеген яхшырту, җитди чирләрне булдырмау, үзеңне яхшы хис итү, һәрвакыт яхшы формада тоту өчен организмга су кирәк.

Бөтен эшчәнлеген сәламәт яшәү рәвеше өчен продукция җитештерүгә юнәлдергән, дөнья базарында иң күренекле урыннарның берсен алып торган Zepter International халыкара компаниясе тәкъдим итә: һәр көнне 2-3 литр су эчегез! Тикшеренүләр күрсәткәнчә, 2 стакан су эчкәннән соң, 30 минут үтүгә, организмдагы калорияләр 30 процентка тизрәк яндырыла.

Теләсә нинди су эчәргә ярамый! Чөнки суда организмга зур зыян салучы мышьяк, фторид, гөмбәчек ише зарарлы матдәләр һәм вируслар, меңләгән бактерияләр яши. Хәтта аны төрле эретмәләр, хлорид яисә башка шуның ише химик матдәләр белән чистартканнан соң да ул тутыкланган сүүткәргеч аша безнең краннарга килеп җиткәнче, төрле үзгәрешләр кичерә. Аны инде кайнатмыйча авызга алырга ярамый. Кибетләрдә сатыла торган суның сыйфаты да шикле, аның краннан гына тутырылган булмавына иманыгыз камилме?!

Бүгенге көндә су чистарткыч фильтрлар тулып ята. Фильтрланган су, чистарту системасын дөрес сайлаганда, иң чистасы, файдалысы. Безнең компания җитештерә торган AqueenaPro, Edel Wasser ише су чистарткыч системалар иң ышанычлысы. Чөнки су чистарту барышында биш баскычлы фильтрлау үтә. Биредә инде суга зарарлы катнашмалар һич эләгә алмый: суда күгәрек тә, ком һәм төрле вак кисәкчекләр дә, вируслар, авыр металлар, пестицид та, начар ис тә калмый.

Сезгә су чистарткыч системасының шундыен тәкъдим итәбез.

Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 85 нче «б» йорт, 309 нчы офис.
Тел.: 8(917)9205874, 8(960)0323350. Zepter бренд Home care (экология дома).
Сайтыбыз: www.Zepter.ru

РЕКЛАМА

PRESSA.RU

ГӨЛСИРИННӘН ТӘМЛЕ СЫЙ

«Аш-су» рубрикасының чираттагы кунагы – Гөлсирин АБДУЛЛИНА. Җыр-моң сөючеләргә «Кашыңның каралары», «Кошлар кебек» җырлары белән яхшы таныш җырчы кызыбыз Мамадыш районының Урта Кирмән авылыннан. Әтисе дә, әнисе дә мәдәният хезмәткәрләре булган Гөлсирин сәхнәгә беренче тапкыр 5 яшендә чыккан. Казан тамашачысына аны тәүге тапкыр Рәшит Ваһапов фестивале танытты. Челтер тавышлы, кыңгыр калфаклы бу җырчыны белмәгән кеше хәзер инде сирәктер. Сәхнәне сайламаган булса, ул мөгаен, аш-су остасы булыр иде. Пешеренергә мәктәптә укыганда ук яраткан. Үзе төрле рецептлар уйлап чыгарырга да маһир. Бүген ул безгә тавык итеннән кебаблар пешерергә тәкъдим итә.



Кирәк:

- 1 кг тавык түше;
- 2 баш суган;
- 1 зәһәр борыч;
- 3-4 яшь бәрәңге;
- 2 баллы кызыл борыч;
- 1 данә помидор;
- 50 г петрушка;
- 2 бал кашыгы куркума;
- 2 тырнак сарымсак;
- 2 йомырка (мәҗбүри түгел);
- кашык очында гына укроп орлыгы,
- 1-2 канәфер, 1-2 данә хуш исле борыч,
- 1 аш кашыгы шикәр комы;
- 100 мл үсемлек мае;
- тәменчә тоз;
- агач таякчыклар.





Эш барышы:

■ тавык түшен суган белән бергә ике тапкыр иттарткычтан чыгарабыз. Шунда ук орлыгыннан чистартылган зәһәр борычны да кушып җибәрәбез.

■ Ит фаршына мул итеп куркума салабыз, тәменчә тоз сибәбез дә барысын бергә бик яхшылап болгатабыз.

■ Ит дәмләнгән арада, аның янына бирергә соус әзерлик. Моның өчен: помидор белән бер баллы борычны эрерәк кисәкләргә турап, блендер савытына салабыз. Шунда ук сарымсак, тәменчә тоз, шикәр комы, хуш исле борыч, укроп орлыгы, канәфер өстибез. Петрушканы кул белән генә өзгәләп, аны да помидорлар янына кушабыз. Иң ахырдан 1-2 аш кашыгы үсемлек мае салабыз да барысын бергә блендер белән ваклыйбыз.

■ Иттән озынча котлетлар әвәлибез. Озаклап әвәләргә кирәк, таралып китәрлек булмасын.

■ Һәр котлетны берәр таякчыкка кидерәбез. Таба төбенә пергамент кәгазе җәеп, котлетларны тезәбез дә, 230–250 градус кызулыктагы газ мичендә кызарганчы пешерәбез (10-15 минут).

■ Кабыгы әрчелмичә генә саламлап туралган яшь бәрәңгене майлы табада кыздырабыз.

■ Бәрәңге яртылаш әзер булгач, саламлап туралган баллы борычны өстибез. Тозны исә яшелчәләр тәмам әзер булганнан соң гына сибәбез.

■ Сыебыз әзер. Инде аны матур итеп табынга бирик. Зур сай тәлинкәнең яртысына урталай бөкләнгән күзикмәк салабыз. Аның өстенә матур итеп кебабларны тезәбез.

Тәлинкәнең икенче яртысына кыздырылган яшелчәләрне өеп салабыз. Йомырканың сарысын, агыннан аерып, яхшылап туглыйбыз һәм яшелчәләр суынып өлгергәнче, алар өстенә агызабыз. (Йомыркасыз гына да мөмкин.) Соусны кечкенә генә аерым савытта бирәбез.

Төрләндерим дисәгез, соусның икенче төрлесен дә ясарга була.

Кирәк:

• 250 г кибет каймагы (майонез да кушарга мөмкин);
• 1 данә тозлы кыяр;
• 2 аш кашыгы соя соусы (яки тоз);
• укроп белән петрушка.

Вак угычтан уылган яки бик вак итеп туралган тозлы кыярга ваклап туралган укроп белән петрушканы кушабыз. Соя соусы белән каймакны салып, барысын бергә болгатабыз. Табынга биргәнче суыткычка куеп, суытып алабыз.

PRESSA.RU




Таныш булыйк – бу мастер-классның авторы Асия МӨХӘММӘТШИНА. Асиянең әбисе Хәлимә апа – Фатиха Аитованың беренче укучысы. Шул чор хатын-кызларының күбесе кебек, ул да бәйләргә оста булган. Сугыш елларында гаиләсен шушы һөнәре белән туендырган. Асия дә әбисенә охшаган. Кулларына күз иярми. Гадәттә, осталар үз серләре белән уртаклашырга бик ашыкмый, ә Асия – киресенчә. «Үзем уйлап тапкан әйберләрне башкаларның да бәйләвен күрсәм, шат кына булачакмын», – ди ул. Әйдәгез, шатландырыйк без аны.



НӘКЪ БЕЗНЕҢЧӘ, МИЛЛИ

Кирәк:

- түбәндәге төсләрдән берәр йомгак ирис җебе – сирень, чия төсе, көрән төснең ачык шоколад һәм куе кызгылт төсмерләре, шәмәхә һәм куе шәмәхә төсләре, баклажан төсе, кирпеч төсе, ачык шәмәхә һәм алсу шәмәхә төсләр;
- ике төрле кер бавы – берсенең диаметры 6-7 мм, озынлыгы 1 м;
- икенчесенең диаметры 5 мм, озынлыгы 1,5 м;
- 65-70 см сирень төсендәге нечкә каты бау (балавызланган);
- диаметры 1,5 см булган ике сәдәф (төсләре мөһим түгел);
- синтепон;
- 0,9 мм санлы ыргак;
- зур күзле тупыйк энә (бәләкәй булавка да ярый);
- калынрак тегү энәсе.



Эш барышы:

■ ачык сирень төсле җептән ике шнур бәйлибез. Аларның озынлыгы 45 см. Бәйләү тәртибе ике шнур өчен дә бердәй. Башта 3 күзле чылбыр үреп, боҗрага тоташтырабыз. Шушы боҗрага чалусыз багана белән 10 күз бәйлибез. Барлык рәтләр дә чалусыз 10 багана белән бәйләнә. 45 см булгач, күзләрне япмый гына бәйләмне читкә куеп торабыз.

■ Диаметры 6-7 мм булган кер бавыннан 45 см озынлыктагы ике бау кисеп алабыз. Калын энәгә шнур төсендәге җеп саплап, бауның ике башына да җепләрне нык итеп типчеп куябыз. Тупыйк башлы энәгә бауның бер очындагы җепне саплап, әле генә бәйләгән шнурлар эченнән бау уздырабыз. Энәне шнурның ачык башыннан тыгып җибәрәбез, ябык башының кыл уртасыннан тартып алабыз. Бау очына беркетелгән җепләрне әлегә өзмибез.

■ Балавызланган нечкә бауны урталай бөкләп, шнурның ябык башына нык итеп тегеп куябыз (бау очына тагылган теге җеп шуның өчен кирәк). Бау төбен төенлибез. Бу төеннән соң сәдәф сыярлык ара калдырып, тагын бер төен ясыйбыз. Аннары тагын берне, тагын берне... Муенсаны төрле озынлыкта итеп тагын йөрерлек булсын өчен эшләнә бу төеннәр.

■ Бәйләгән шнурларның икенче башы ачык бит әле. Аны ыргак белән, күзләрне киметә барып, бәйләп ябабыз (бау очына типчелгән җепне тышка чыгарып калдырырга онытмыйбыз). Бәйләмдә бер генә күз калгач, ике җепне бергә бәйләп куябыз. Шнурны бәйләгән җеп очын энә ярдәмендә бәйләм эченә яшерәбез. Ә менә бау очына тегелгән җеп әлегә шулай торып торсын, бизәк теккәндә кирәк булачак ул.

■ Муенсаның бизәкләрен ясау өчен башка төстәге җепләрдән дә шнурлар бәйлибез. Алар беренче бәйләгәненнән нечкәрәк итеп – барысы да 9 күздән чалусыз багана белән бәйләнә. Озынлыгы төрлесенеке төрлечә.

Димәк, түбәндәге төсләрдән бәйләнгән шнурларның озынлыгы:
кирпеч төсле җептән – 30 см;
шәмәхә төстән – 26 см;
чия төсеннән – 23 см;
шоколад төсендәге көрән җептән (икешәр шнур бәйләнә) – 18 см;
куе шәмәхәнең зәңгәррәк төсмерлесеннән (шулай ук икешәр шнур) – 13 см.
Һәрбер шнурга 5 мм калынлыктагы бау кидерелә. Бау очларына шнур төсендәге җеп тегелә.

■ Шнурлардан тыш, безгә әле төрле зурлыктагы ике катлы түгәрәкләр һәм шарчыклар бәйләргә кирәк. Баклажан төсендәге түгәрәкнең диаметры – 3 см;
кызгылт көрән төслесенең диаметры – 2,2–2,4 см;
Тагын биш шарчык – 1,3 см диаметрлы. Аларның өчесе – алсу шәмәхә төсле. Берсе – ачык шәмәхә, берсе – куе шәмәхә төстән бәйләнгән.

PRESSA.RU



Бизәкләрне җыю:

■ чия төсле шнурны кыл урталай бөкләп, ике очын эчке якка таба «әкәм-төкәм» рәвешенә кертеп бөгәрлибез. «Әкәм-төкәмнәрнең» икесе дә нәкъ бертөсле булырга тиеш. Бизәк таралып китмәсен өчен чукмарбашлы энәләр белән чәнчибез. Сирень төсле шнурларның да бер очыннан «әкәм-төкәмнәр» ясыйбыз. Шнурларны иләккә салып, 3-4 минут кайнар пар өстендә тотабыз.

■ Энәләрне алып, шнурларны рәсемдәгечә итеп бер-берсенә беркетәбез. Калынрак энәгә шнур башыннан күренеп торган җепне саплап, бизәкне нык итеп тегеп куябыз. Энә эчтәге бау аша да узсын. Аны бау аша тартып чыгару шактый кыен эш, шуңа күрә карга борынсыз булмас.

■ Кызгылт-көрән төстән бәйләнгән ике катлы түгәрәк эченә юка гына итеп синтепон тыгабыз, аннары бәйләм җебен тартып, түгәрәкне тәмам ябабыз. Аның уртасына шәмәхә төсле шарчык тегәбез. Шарчык эченә дә синтепон тыгып калдырыла. Теләгән кеше бу шарчыкны матур таш яки сәдәф белән алыштыра ала. «Йөрәк» уртасын бизисе деталебез әзер. Аны да үз урынына тегеп куйыйк. Теккәндә пөхтә эшләргә тырышыгыз – җөйләр күренеп калырлык булмасын!

■ Инде уртадагы бизәкне ясыйк: кирпеч һәм шәмәхә төсле җепләрдән бәйләнгән шнурларны кыл урталай бөгеп, рәсемдәгечә итеп төрәбез. «Мыекларның» кая таба карап торуына игътибарлы булыгыз. Көрән төстәге шнурныкы – эчкә таба, шәмәхәнеке тышка таба төрелә! Бөкләмнәр ачылып китмәсен өчен энә белән кадап, боларын да иләктә парлап алабыз.

■ Бизәкне җыйганда, иң элек «мыекларны» бер-берсенә тегәбез. Әйткәнемчә, шнур башындагы җепләр нәкъ менә шуның өчен кирәк тә. Бизәк уртасына баклажан төсендәге ике катлы түгәрәк, аның уртасына ачык шәмәхә шарчык тегелә. Аларның эчендә дә – синтепон. Шәмәхә «чәчәк» өстенә алсу шәмәхә төсле бәләкәй түгәрәк беркетәбез. Әзер бизәкнең кайда урнашасы рәсемдә ачык күренә. Бизәкне беркеткәч, сирень төсле шнурларны бер-берсенә терәп, энә белән чәнчеп куябыз.

■ Шоколад һәм куе шәмәхә төсендәге җепләрдән бәйләнгән шнурлардан икешәр «лалә чәчәге» ясыйбыз. Аларны ясау тәртибе дә калган бизәкләрнеке кебек. Урталарын алсу шәмәхә төсендәге түгәрәкләр белән бизибез. Игътибар: бу түгәрәкләр эченә синтепон тыгылмый, алар шулай ялпак килеш кала. Әзер «лаләләр» сирень төсендәге шнурның ике ягына беркетелә.

■ Диаметрлары 1,5 см булган ике сәдәфне куе шәмәхә төстәге җеп белән бәйләп тышлыйбыз. Әзер булгач, аларны сирень төсендәге шнурларның очына тегеп куябыз. Боларның берсе каптырма ролен үтәсә, икенчесе симметриялелек өчен кирәк.


Кучкар. Моңарчы җыелып килгән эшләрне җәһәт кенә башкарырлык көчегез пәйда булыр. Күп өлкәләрдә уңыш сезнең якта булса да, зур акчалар белән бәйле эшләргә тотынмый торыгыз.


Үгезбозау. Күңелегез романтикага тартылыр. Төзелеш, сәүдә өлкәсендә эшләүчеләр уңышка ирешәчәк. Иҗат белән шөгыльләнүчеләргә дә илһам елмаячак. Яхшы гына акча эшләп алу җае чыгар.


Игезәкләр. Тормышыгызның сез уйлаганча гына бармавы куйган максатларыгыздан ераклаштырырга мөмкин. Күп нәрсәгә ачуыгыз килер, үзегезне кулда тотар өчен көч туплагыз. Яңа эшләр башлар өчен яхшы вакыт түгел.


Кысла. Эчке сизгерлегегез искиткеч, үз-үзегезне тыңласагыз, ялгышмассыз. Хыялларыгызны тормышка ашыру өчен менә дигән мөмкинлек булырга тора. Хәзер башлаган эшләрегез уңыш китерәчәк.


Арыслан. Бөтен җирдә тәртип урнаштыру, иске-москыдан котылу теләге туар. Зур әйберләрне шушы айда сатып алырга тырышыгыз. Көчегезне сынап карарга менә дигән мөмкинлек булыр, әмма конкурентларга каршы көрәшергә дә туры килер.


Сөмбелә. Киләчәк тормышыгызга йогынты ясардай карарлар кабул итәргә туры килер. Югарырак эшкә, хәтта бүтән шәһәргә күчәргә тәкъдим итәрләр. Ашыгып кабул ителгән карарның ялгыш булуы бар.


Бизмән. Рәхәтләнеп ял итү, тынычлану өчен шәп форсат туар. Ял итү мөмкинлеге булмаса да, кайгырмагыз. Бу айда зур мәшәкатьләр, авырлыклар көтелми. Финанс ягы куандырачак. Тормышыгызга үзгәрешләр кертергә теләсәгез, уңышлы булыр.


Чаян. Алдыгызда менә дигән перспектива ачыла һәм камиллекнең чиге булмауга хәзер генә ышана башларсыз. Теләсә кайсы мәшәкать җиңел генә хәл ителер. Идеяләрегезне тормышка ашыру җае килеп чыгар.


Укчы. Эшләрегезне төгәлли алмауга бимазаланырсыз. Сезне йомшак дип уйлап йөрүчеләргә сүзегезне кистереп әйтергә туры килер, моның уңай нәтиҗәсен дә күрми калмассыз. Дәрәҗәгез үсәр, керемегез артыр.


Кәҗәмөгез. Җан тынычлыгы, күңел көрлегенә ирешерсез. Уйламаган җирдән сәфәр чыгуыгыз ихтимал. Финанс ягыгыз җайланыр. Сәламәтлекне кайгырту өчен шәп вакыт. Авантюралардан сакланыгыз, ышанучанлыгыгыз аркасында авыр хәлдә калмагаегыз.


Сукояр. Дусларыгыз алдында бер башка үсеп китәрсез. Моңарчы уйлап та карамаган сәләтегез ачылыр, ә бу исә эшегездә уңыш китерәчәк. Бу айда акча белән бәйле эшләрне калдырып торыгыз һәм бурычка беркемгә дә акча бирмәгез.


Балык. Идеяләрегезгә ирек бирегез. Иң кыю фикерләрегез көтелмәгән уңыш китерәчәк. Көнкүреш техникасы сатып алу өчен яхшы вакыт. Сәламәтлегегезгә игътибарлы булыгыз. Көтелмәгән җирдән керем алуыгыз ихтимал.

Чит илләр *Россия* *Татарстан* **ИЮЛЬ** *дә кабынган йолдызлар*



Диләрә Тумашева (19.07.1926–22.07.2006) – **тел белгече, профессор, Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Ленин ордены кавалеры.**

Түбәндә туа, мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Мәскәү дәүләт университетының төрки телләр бүлегенә укырга керә. Француз, төрек, алман телләрен камил белә. 50 ел гомерен Казан дәүләт университетына багышлый. 1965–1989 елларда – көнчыгыш телләре кафедрасы мөдире, 1971–1980 елларда тарих-филология факультеты деканы була. Озак еллар экспедицияләргә йөреп, татар теленең себер диалектын өйрәнә, бу өлкәгә кагылышлы фәнни хезмәтләр яза. Татар теле грамматикасы буенча язган эшләре дә бихисап. Ире режиссер Равил Тумашев белән бер ул, бер кыз үстерәләр.



Валентина Толкунова (12.07.1946–22.03.2010) – **танылган җырчы**, **Россиянең халык артисты**.

Краснодар өлкәсендә туа. Әтиләре хәрби булган гаилә 1950 елда Мәскәүдә төпләнә. Җырга гашыйк кешеләр була алар. Шуңа да Валентина мәктәпне тәмамлап, Мәскәү культура институтының дирижерлык-хор бүлегенә укырга керә. 1966 елда Ю. С. Саульский җитәкчелегендәге вокаль-инструменталь оркестрга кабул ителә. 1971 елда Гнесиннар исемендәге музыка училищесын тәмамлый. 1972 елда Союзлар сараенда «Ах, Наташа» җырын җырлап, бөтен илгә таныла. 1973 елдан «Москонцерт» берләшмәсендә эшли. «Тыныч йокы, нәниләр!» тапшыруында ул җырлаган бишек җырын тыңлап, менә инде ничә буын бала үсә.



Мирей Матье (22.07.1946) – **дөньякүләм билгеле җырчы.**

Франциянең Авиньон шәһәрендә, ундүрт балалы гаиләдә туа. 13 яшеннән фабрикага эшкә урнаша. Шәһәрдә узган җыр конкурсында беренче урынны алган 19 яшьлек Мирейны Авиньон хакимияте Парижга – «Теле-Диманш» телеканалындагы «Игра фортуны» тапшыруында катнашырга җибәрә. 1965 елның 21 ноябрендә беренче тапкыр телеэкраннарга чыгып, фурор тудыра. Ә тагын бер көннән танылган продюсер Джонни Старк аның белән контракт төзи. Күпләр аны Эдит Пиафка ошата. Беренче яздырган дискы ук Франциядә миллион тираж белән сатыла. Мирей Матьены таныткан тагын бер нәрсә – гомере буена үзгәрмәс сәхнә образы.

PRESSA.RU





ИЛЧЕЛӘР БЕЗНЕ КӨТӘ...

Аны сюрреалистик рәсемнәр остасы буларак кабул итү гадәткә кергән. Гәрчә танылган урам рәссамы, Казаныбызның горурлыгы Рөстәм СӘЛИМГӘРӘЕВ өчен кысалар юк шикелле: граффити, киндердәге сурәтләр, иллюстрация, дизайн – аның кулыннан барысы да килә.

Рөстәмнең киндердә, ә бигрәк тә йорт диварларында тудырган дөньясы шулкадәр чын ки, «сюрреализм» төшенчәсе урынсыз булып тоела башлый. Рене Магриттның чаршауда силуэты калып, аның аша болытлар агылып, күк йөзе күренеп торган абзыйны гәүдәләндергән полотносы безнең чынбарлыкка ничек тәңгәл булса, монда да шулай.

Аның дөньясында һәм Шәрык, һәм Гареб суфи-дәрвишләрен хәтерләткән затлар яши. Изяләр, дәрвишләр, илчеләр. Кинәт араларыннан берсе Шәмс Тәбризи булып чыгар кебек тоела, йә булмаса, францискан монахларының озын ябынчасына төренгән яланаяклы Франциск Ассизийский. Хәер, бу дәрвишләрнең күбесенең аягында – кеды, ә аркаларында – рюкзаклар. «Дхарма дәрвишләре»н дә хәтерләтә алар.

Рөстәмнең дәрвишләре аерым бер тәгълиматлардан, фәлсәфи агымнардан, һәм, аннан да битәр, дини юнәлешләрдән азат. Шуңа да аларның капюшон астындагы йөзләре дә – галәмнәр кучеп йөри торган порталлар. «Кечке әкият» дип аталган график рәсемне генә алыйк: өч дәрвиш утыра, алларында ачылган китаплар. Ул китаплар диңгез булып шаулый, бу диңгездә кечерәк масштаблы яңа бер дәрвиш көймәдә йөзеп бара, башкасының китап-диңгезендә дулкыннар маякка бәрелә-бәрелә дулый, өченчесенекендә – уйга талган берәү дөнья белән хозурлана. Кемгә укыйлар бу төнге әкиятне? Әлбәттә, миңа!

Һәм мин сурәтнең эченә кереп китәм дә, алгы пландагы ике дәрвишнең йөзләре булырга тиешле порталлардан агып-йөзеп йөри башлыйм.

Менә Норвегиянең Осло шәһәрендәге бинаны бизәп торучы «Тереклек чыганагы» дип аталган мурал. Аркасына җирән рюкзагын аскан дәрвиш, кабырчыкка чумырып, су эчә. Ул чүмәшкән түмәр – Мезоамерика джунглиларының фәкыйрь бер калдыгы бугай. Конкистадорлар Яшәү агачын һәм үлемсезлек бүләк итүче Тереклек чишмәсен шуннан эзләгәннәр бит...

Рөстәм сурәтләгән дөньяларда проблемалар спектры гаять киң, шул ук вакытта алар барыбер бер төенгә кайтып төйнәлә: без һәм безнең асылыбыз. Менә аның киндергә майлы буяу белән ясалган «Лабиринт»ы. Шәһәр манзарасы өстенә табигатьнең бер символы булган такта утыргычынмы, намазлыгынмы җәеп салган ялантәпиле дәрвиш, бер кулы белән таягына таянып, икенчесенә компас тотып, юнәлеш эзли. Бәлки, Кыйбланы барлыйдыр? Дәрвиш үзе дә – бер лабиринт, аның теткәләнеп беткән киемнәргә уралган гәүдәсендә – ишекләр, баскычлар. Тукта, безнең аңыбызны заман информацион шаукымы чынчынлап Минотавр тозагына әйләндермәдеме соң әле? Шуны хәбәр итүедер, бәлки, бу илченең?!

Ә без нәрсәгә дә булса төшенергә әзерме? Илчеләр безне көтә. Алар илткән хәбәр, бәлки, ошамас та безгә. Әмма үзеңә юл беркайчан да җиңел булмаган...


Луиза ЯНСУАР

Тулысынча сайтыбызда «Галерея» сәхифәсендә укыгыз.









«Могҗиза». Истанбулдагы йортка төшерелгән рәсем.
«Үзгәрешләр».
«Иртәнге төш».
«Чәчәк ату». Фрагмент.
«Тереклек чыганагы».

рәстәм сәлимгәрәев

PRESSA.RU

ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204



Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча язылa алалар: 73002

1 ИЮЛЬДӘН 2017 ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ. БҮГЕНГЕ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫП ӨЛГЕРЕГЕЗ!

Журналыбызга онлайн режимда :
http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә
язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була.
iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (www.syuyumbike.ru).

16+